Общественная организация
«ФЕДЕРАЛЬНАЯ
НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНАЯ
АВТОНОМИЯ ТАТАР»

«ТАТАР ФЕДЕРАЛЬ
МИЛЛИ-МӘДӘНИ
АВТОНОМИЯСЕ»
иҗтимагый оешмасы

ҺӘВӘСКӘР ТЕАТРЛАР ӨЧЕН
ПЬЕСАЛАР КОНКУРСЫНДА ЖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ

# Пьесалар җыентыгы

СБОРНИК ПЬЕС ДЛЯ ЛЮБИТЕЛЬСКИХ ТЕАТРОВ
ПОБЕДИТЕЛЕЙ КОНКУРСА

## «Яшь талантлар • Молодые таланты»

В РАМКАХ ПРОЕКТА ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ «ФЕДЕРАЛЬНАЯ НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ ТАТАР» «ЯШЬ ТАЛАНТЛАР» («МОЛОДЫЕ ТАЛАНТЫ») ЗА СЧЕТ СУБСИДИИ, ПРЕДОСТАВЛЕННОЙ ИЗ БЮДЖЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, 2019Г.

# Эчтәлек / Содержание

**«14 ЯШЬКӘ ЧАКЛЫ АВТОРЛАР (ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯЗЫЛГАН ПЬЕСАЛАР)» НОМИНАЦИЯСЕ**


Сәлимова Д. Д. «Заманча шалкан әкияте!» ................................ 3

Хәбирова Р. Ш. «Киләчәккә юл яргանда». ................................ 7

Зәкиева Д. Ф. «Әлли-бәлли, бишегем...» ................................ 14

Закирова З. Р. «Туган телем — үз телем» ................................ 19


**«БАЛАЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ПЬЕСА» НОМИНАЦИЯСЕ**


Газимҗанова Г. Ф. «Юри-мари чын катыш...» ................................ 21

Шакирҗанова А. А. «Кыш бабайга хат» ................................ 36

Гыйззәтуллин И. И. «Тапталмас, югалмас безнең эз» ............ 47


**«ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ПЬЕСА» НОМИНАЦИЯСЕ**


Мансуров А. И. «Изгелек» ................................ 51


**«РУС ТЕЛЕНДӘ ПЬЕСА» НОМИНАЦИЯСЕ**


Палачёв К. С. «Типичный случай» ................................ 65

Исмаилова М. Р. «Как подсказывет сердце!» ................................ 76


**МАХСУС ПРИЗГА ЛАЕКЛЫ ПЬЕСАЛАР**


Бәширова Н. И. «Кәрәзле-баллы тормыш» ................................ 79

Әхтәмҗанова А. Н. «Казан кызы Гөлия» ................................ 85

Гарипова Л. Н. «Тормыш дәвам итә» ................................ 91

Хәбибуллина И. И. «Авылымда каз өмәсе» ................................ 99

*Сәлимова Динә Динар кызы*

# ЗАМАНЧА ШАЛКАН ӘКИЯТЕ!

(7-13 яшьлек балалар катнашындагы курчак театры өчен төзелгән сценарий)

БЕРЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Әкият иле – сихри бер могҗиза ул. Кызыклы ул, шаян ул, күңелле ул! Шул дөньяга сәяхәткә бүген җыелдык бит, шулай түгелме?

ИКЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Исәнмесез, балалар! Бүген без сезнен белән «Заманча шалкан» әкияте карап үтәрбез.

*Уфылдап, ахылдап арып беткән БАБАЙ сәхнәгә чыга.*

БАБАЙ. Язлар үтте, җәй дә килеп җитте. Бу бакчага чыгып караган кеше дә юк. Бәрәңге утыртылмаган, кишер чәчелмәгән. Әби дә заманчаланып бетте, машинасына утыра да, чыгып китә. Ни эшләргә? Ни эшләргә? Тукта, шалкан булса да чәчеп куйыым әле.

*БАБАЙ шалкан чәчә, су сибә.*

БЕРЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Әйдәгез әле, балалар, бабайга су сибешик әле! Кап-кап-кап!

БАБАЙ. Шифалы чишмә сулары, шалканны бигрәк яхшы үстергән. Сөбханалла...

*БАБАЙ шалканны тарта башлый.*

ИКЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Әйдәгез әле, балалар, бабайга шалкан тартышыйк әле! Бер, ике, өч!

ШАЛКАН. Тартма бабай, тартма, авырттырасын! Барыбер чыкмыйм.

БАБАЙ. Менә сиңа замана, шалканым сөйләшә түгелме? *(Шалканны карап килә.)* Тукта, әбигә шалтыратыйм әле. *(Телефонын алып әбигә шалтырата. Гудок бара, әби алмый.)* Никләргә икән аңа телефон?! Алмый да.

*Яхшы машинага утырган ӘБИ кайтып төшә.*

БАБАЙ. Карчык, кара әле, нинди шалкан үстердем син кайтышка. Тик тартып чыгыра гына алмыйм.

ӘБИ. Абау, нинди матур, модный шалкан! Бабай, мин шәһәрдән кайтып кына төштем, киемнәрем дә чиста, сиңа булыша алмыйм, гафу.

Б А Б А Й. Могжизалы шалкан ул, сөйләшә торган. Мин күндерә алмадым. Син, карчык, сөйләшеп кара әле, үзе чыкмасмы икән? Мин киттем кызны чакырам, бәлки, заманча шалканны заманча кыз күндерер?

*Б А Б А Й өйгә кереп китә, әби шалкан янына килә.*

Ә Б И. Алла да матур, илә дә тәмле шалкан бит син! Шундый модный, стильный! Әйдә чык үскәнем! Мин сине иң яхшы универсамнарга алып барырмын, шунда гына сатармын!

Ш А Л К А Н. Юк, низачто чыкмыйм!

*Ә Б И ачуланып, шалканны тартып карый.*

Б Е Р Е Н Ч Е А Л Ы П Б А Р У Ч Ы. Әйдәгез әле, балалар, әбигә булышыйк! Бер, ике, өч!

Ш А Л К А Н. Тартма әле, әби, колакны авырттырасын!

Кыз күренә. Телефонын тоткан. Җырлый-җырлый чыга.

К Ы З. Ну что әби, получаетсямы? Кая әле, син бар, кереп чәй куй. Я сама сөйләшеп карыйм.

*Ә Б И кереп китә.*

К Ы З. Әй, шалканчик! Син что монда киреләнеп утырасын? Әйдә, без синең белән поладим. Хәзер менә фото ясыйбыз, селфи. Әйдә әле, әйдә, чык! Дружить будем, тусить будем!

*К Ы З фотога төшерә башлый.*

И К Е Н Ч Е А Л Ы П Б А Р У Ч Ы. Балалар, ә сез фотога төшерә беләсезме? Әйдәгез әле кызга булышыйк. Келт! Келт! Келт!

К Ы З. Хәзер, мин сине... Тузик Шариковичка шалтыратыйк әле. Тузик Шарикович, исәнмесез. Мөмкин булса, безгә килеп китегезче?

*Дипломат тоткан эт килә.*

Э Т. Исәнмесез. Вакытым тар. Әйдәгез тиз генә, ни кыласы бар?

К Ы З. Тузик Шарикович, сездән башка булмый, бабай шалкан үстергән, һич чыгарып булмый

Э Т. Монда аерым сөйләшү кирәк. Тәк, сез китеп торыгыз. Хәзер барын да җайлыйбыз.

*К Ы З чыгып китә.*

Э Т. Тәк, Шалкан афәнде! Сез димәк, бу урыннан кузгалыйрга уйламыйсыз?

ШАЛКАН. Юк.

ЭТ. Тә-әк. Әгәр мин сезгә бу урынны бушаткан өчен акча түләсәм? Ни диярсез?

ШАЛКАН. Намусым чиста, урыным яхшы. Чыкмыйм дигәч чыкмыйм!

ЭТ. Аһ, син шулаймы әле?! Хәзер мин, Мырауҗан ханымга дәшәм! Хәзер чакырам мин аны!

ИКЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Балалар, ә сез Мырауҗан ханымнын кем икәнен беләсезме? Әйдәгез, бергәләп чакырыйк әле! Мия-Мия Мырауҗан ханым! Килегез!

*ПЕСИ керә.*

ПЕСИ. Исәнмесез, саумы сез! Нәрсә булды, Тузик Шарикович? Сезне ни борчый?

Эт шалканга төртеп күрсәтә дә, кулын селтәп чыгып китә.

ПЕСИ. Исәнмесез, хөрмәтле шалкан әфәнде! Сез тынычланыгыз, тирән сулагыз, бар фикерләрегезне башыгыздан алып атыгыз. Тә-ә-әк!

Әйдәгез әле, дусларым, шалкан шушы халәттә торганда, тиз генә тартып чыгарыйк үзен! Бер, ике, өч..

ШАЛКАН. А-а-а-а-ай! Бетерәләр! Бар яфрагымны йолкыйлар! А-а-а-ай!

*Тавышкка өйдәгеләр йөгереп чыга. ТЫЧКАН пәйдә була.*

ТЫЧКАН. Нинди тавыш? Ни булды? Өйдә утырырлык түгел бу тавышка!

ШАЛКАН. Тияләр! Йолкыйлар! *(Елый.)*

*ТЫЧКАН Шалканны тынычландыра.*

БАБАЙ. Мин шалкан утырттым, ул шундый зу-ур булып үсте, тик чыгарга теләми.

ТЫЧКАН. Ә-ә-ә, менә нидә хикмәт! Шалкан чыксын өчен сезниләр эшләп карадыгыз?

БЕРЕНЧЕ АЛЫП БАРУЧЫ. Балалар, әйдәгез, тычканга булышыйк әле. Бабай тартып карады. Әби яхшы супермаркетта сатырга вәгъдә бирде. Кыз дружить, тусить итәргә тәкъдим итте. Эт акча бирәм, диде. Песи алдамакчы булды.

ТЫЧКАН. Сез бит шалканнан сорамагансыз, аның үзенә ни кирәк соң? Шалкан дустым, син бик уңгансын, зу-ур булып үскәнсең! Әйт әле, үз сүзеңне!

ШАЛКАН.

Миңа бит, күп кирәкми.
Хыялым тик бер генә.

Минем яңа ел табынында
Өстәл бизисем килә!

*Яңа ел җыры яңгырый.*

Т Ы Ч К А Н. Күрдегезме, менә бит! Уңган шалканыбыз яңа ел табынын бизәргә тели! Әлбәттә, дустым, безнең өстәлебезнең иң матур, иң түр урыны синеке булачак! Мин, яңа 2020 ел хуҗасы буларак, моны сиңа вәгъдә итәм!

Б Е Р Е Н Ч Е А Л Ы П Б А Р У Ч Ы. Кадерле дуслар, шуның белән безнен әкиятебез ахырына якынлашты. Уңган-булган тычкан шалканны күндерә алды. Кулга -кул тотынышып яңа елга аяк басабыз. Якынлашып килуче бәйрәм белән сезне!

*Хәбирова Ралина Шамил кызы*

# КИЛӘЧӘККӘ ЮЛ ЯРГАНДА

*Катнашалар:*

ИЛГИЗӘР СӘЕТОВ, 16–17 яшьләрдәге укучы егет.

ИРЕК НИЗАМОВ, илгизәрнең якын дусты, сыйныфташы.

ШӘҺӘР КЕШЕЛӘРЕ, шәкертләр, сәүдәгәрләр, байлар, муллалар, картлар.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Казан мәктәпләренең берсе. Коридор буйлап ике егет бара.*

ИЛГИЗӘР. Ниһаять, кайтабыз. И-и-и, бигрәк озакка сузылды бит бүгенге дәресләр. Ашыйсы да килә инде. Онытмагансыңдыр бит инде бүген җыелуыбызны?

ИРЕК. Юк инде. Тик бу — вакытны юкка уздыру, минемчә. Кемнең шулай чорлар буйлап күченеп йөргәне бар? Тузга язмаган эш бит бу! Теге юлы да бернәрсә дә килеп чыкмаган иде. Әле инша да язасы бар…

ИЛГИЗӘР *(ачуы килеп)*. Юк инде. Кечкенә бер детальдә генә җитешсезлек булган дип әйттем бит инде. Кичә робототехника түгәрәгендә хатаның кайда булуын аңладым. Мин монда ачышлар ясарга йөрим, ә аның уенда инша булыр! Әбиеңнән сорарсың әле аулак өйләр, сабантуйлар турында. Сорамасаң да, чәй эчкәндә, яшьлекләрен, элеккеге вакытларны сагынып искә алып сөйлиләр бит алар.

ИРЕК. Ярый инде, ярый. Барыбер үзеңчә эшләячәксең бит.

ИЛГИЗӘР. Әйдә тизрәк булыйк. Автобуска җитешергә кирәк.

*Ашыга-ашыга чыгып китәләр.*

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Казан читендә шәхси йортларның берсе. Илгизәрләрнең ишегалды. Илгизәр белән Ирек ниндидер машина-җайланма янында кайнашалар.*

ИЛГИЗӘР *(игътибар белән алдындагы схеманы карый-карый, механизмны өйрәнә)*. Әйе, менә шулай дөрес. Аһа, бу чыбыклар көлтәсе уңай корылмалы, димәк, монда урнаштырам.

ИРЕК. Буламы әле? Әйткән идем бит инде бу эшнең файдасыз булуын! Дәресләрне дә эшлисе бар.

ИЛГИЗӘР. Дәрес качмый ул. Хәзер инде, түз, комачаулама.

ИРЕК. Кая? Нәрсәсе килеп чыкмый? Бир әле, үзем карыйм. *(Кулын сузып, Илгизәрдән тартып ала.)*

ИЛГИЗӘР *(ачуланып)*. Нишлисең син, кая ашыгасың, ялгыш басуың мөмкин бит.

ИРЕК. Һи, нәрсә булсын инде. Шартлаткыч ясамыйсың бит син. Көтеп торалар, ди, безне анда — киләчәктә.

*Кинәт ниндидер сәер тавышлар килә башлый, төрле төстәге утлар җемелди, тирә-юнь күз чагылдырырлык булып яктыра.*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*1906 ел. Казан шәһәре. Печән базары. Сәүдә рәтләре. Базар гөрли.*

ИРЕК *(гаҗәпләнеп, коты очып)*. Менә сиңа мә! Нәрсә булды?! Без кайда?

ИЛГИЗӘР *(исе китkән, курыккан)*. Ваааау! Ә мин ышанган идем. Без... Ммм... Казандадыр...

ИРЕК. Бу — данлыклы Печән базары түгелме соң?! Тукай нәрсә дигән әле?

Иртә белән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.
Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

ИЛГИЗӘР *(хыялланып)*. Шә-ә-ә-әп! И-их, Тукайны күрсәң иде ул! Печән базары икән! Печән базары! Әйдә, нәрсәләр саталар икән, карап килик әле. Әнә, күн читекләр, чигүле кәләпүшләр, калфаклар. Нәкъ әбинекенә охшаган. Берәр мәҗлестә катнашасы иде... Кызык, хәзер каз өмәләре тәмамдыр инде, аулак өйләр үткәрелә микән?

ИРЕК. Син гел барысы белән дә кызыксынырсың инде. Тик безгә нәрсә алу, кайсы җирләрне күрү түгел, ә өйгә, үзебезнең заманга ничек әйләнеп кайтасыбызны уйларга кирәк...

ИЛГИЗӘР *(үпкәләгәндәй)*. Ә син һәрвакыт барысын да бозасың. *(Ризалашып)*. Дөресен сөйлисең инде дә. Нишлибез алайса?

ИРЕК *(уйга баткан)*. Безгә ничәнче елга эләккәнебезне ачыкларга кирәк. Аннары киемнәр табарга кирәк. Ниндидер элеккеге чорда джинсы чалбар һәм кроссовкаларда йөреп булмас бит инде.

ИЛГИЗӘР. Дөрес әйтәсең, ләкин безгә киемне каян алырга? Минем үзем белән карта гына бар. Әллә махсус безнең өчен яңа төрле акчалар, карталар белән түләү керттеләр микән? *(Көлеп куя.)* Урлашырга ярамас. Шушы кием белән йөрергә туры килер. Якынча унтугызынчы гасыр ахыры — егерменче гасырлар башы булырга тиеш.

*Ниндидер тавыш ишетелә. Еракта кешеләр җыелганы күренә. Алар кызып бәхәсләшәләр.*

ИЛГИЗӘР. Кара әле тегендә, нәрсәдер булганмы соң? Ник кычкырышалар микән? Әйдә, барып карыйк.

*Гауга, җәнҗал купкан.*

БЕРЕНЧЕ БАЙ. Юк, нәрсә сөйлисез сез! Мөселман балаларына һич килешми бу. Ризалыгым юк!

ИКЕНЧЕ БАЙ. Дөрес сөйлисең, Әхмәт бай! Бик хуп! Нинди ата-бабалар рухын мәсхәрәләү инде ул. Театр дигән булып шунда. Тфү!

БЕРӘҮ. Театр куела дип әйттеләр бит. Әнә, гаребтә, русларда күптәннән кәмит уйныйлар. Халык кәмит карарга тели!

ӘХМӘТ БАЙ *(җикеренеп)*. Халык әллә ниләр теләр ул. Аларга эшләмәскә генә булсын. Йөзе каралар! Акылдан шашкан нәрсәләр!

ХАЛЫК ТӨРКЕМЕ *(шаулаша)*. Татар җәмгыятенә театр кирәк! Сез замանадан артка калгансыз. Бик дөрес! Бик дөрес! Театр куелачак! Бүген кич халык жыела. Театрга барабыз!

*ИЛГИЗӘР белән ИРЕК бу тамашаны күзәтеп торалар.*

ИРЕК *(игътибар белән тыңлый, аңларга тырыша)*. Кара, теге карт байлар, муллалар театр куелуга каршы чыга. Беренче театр кайчан куела әле ул? 1906 нчы елда бит?

ИЛГИЗӘР. Әйе, шулай. Без егерменче йөз башында. Казанда. *(Шаулашкан төркем янына баралар, халыкның игътибары аларга юнәлә)*. Җәмәгать! Зинһар, безне тыңлагыз. Без — киләчәк буын. Театр бик кирәк! Уйлап карагыз, ул татарларны югарыга күтәрәчәк, танытачак! Татарның үз театры булса, анда татар телендә кәмит куелачак!

МУЛЛА *(коты оча, догалар укый башлый)*. Китегез! Китегез мөселманнар яныннан. Нинди котсызлар, жен-шайтаннардыр бу?! Ахырзаман дигәннәре шул булыр микәнни? Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Йә, Раббым, кичер гөнаһларыбызны. Әгүүзү билләһи-минәшшәйтанир-раҗииим!

ӘХМӘТ БАЙ. Җәмәгать, менә күрәсезме, шайтаннар яныбызда күзебезгә күренеп йөри башладылар. Барысы да шул бозыклык галәмәте. Театр дигән

булып, шайтан туе уздыралар. Җәмәгать, котылырга кирәк бу җанварлардан. Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим!

ИЛГИЗӘР, ИРЕК *(гаҗәпләнеп, югалып калалар)*. Туктагыз, туктагыз! Без — киләчәк буын вәкилләре. Бездәге кебек киемнәр бик уңайлы. Без егерме беренче гасырдан килдек. Ул чор — фәнни ачышлар, роботлар, акыллы машиналар заманы. Безнең чорда сәнгать, сәнәгать алга киткән, күп илләрдә демократия, ягъни һәр кешенең фикере зур әһәмияткә ия. Һәр кеше тигез хокуклы. Театр, кино һәм музыка кешеләрнең мәдәни тормышында зур урын алып тора. Татар театры бар дөньяга танылган. Театр халыкны мәгърифәтлерәк итә, күңелен агарта. Безгә театр кирәк!

*Купчелек, бигрәк тә иске карашлы кешеләр котырына башлый.*

КАРТЛАР. Карагыз, тыңлагыз! Нәрсә сөйлиләр бит! Имеш, ниндидер машиналар, роботлар. Аллаһ сакласын мондый киләчәктән. Нинди чорларда күченеп йөрү ди ул! Тузга язмаганны сөйлиләр. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла.

ЯШЬЛӘР, ШӘКЕРТЛӘР. Карагыз, фикерләре кызыклы бит боларның. Әгәр дә алар дөресне сөйләсә? Ходай үзе дә бит Корьәндә кешеләргә бик аз күләмдә генә гыйлем бирүен әйткән. *(Егетләргә.)* Тагын нәрсәләр житкерә аласыз?

КАРТЛАР. Әстәгъфирулла. Кирәкми безгә мондый киләчәк! Аллаһка каршы баралар, динне хурлыйлар бит! Милли киемнәр юкка чыккан, кәләпүшләр дә юк. Әллә нинди сәер киемнәр кигәннәр, гореф-гадәтләрне онытып бетерәләр бит. Житмәсә, яшьләрне үз якларына аудармакчылар. Кыямәт алдыннан әллә нинди куркыныч хәлләр булачак, кешеләр Аллаһтан читләшәчәк дип әйтүләре хак икән. Котылырга алардан, котылырга! Җәмәгать, бирешмәгез, Аллаһка сыеныгыз! Тотыгыз аларны, берүк качмасыннар! *(Тагын шау-шу куба. Егетләрне тотып алалар. Кулларын бәйлиләр. Картлар китеп бара.)*

ИРЕК. Эх, кирәкми иде безгә вакыт машинасы төзибез дип юләрләнергә. Менә хәзер җәзасын алдык. Соңгы көннәребез шулдыр инде. Әти-әниләр дә безнең кайда икәнне белми, вакыт машинабыз да ватык. Бәхил бул, дустым. Синең аркада бу хәлгә төшсәк тә, син яхшы дус булдың.

ИЛГИЗӘР *(үзе дә төшенкелеккә бирелгән, ләкин дустын юатмакчы)*. Йә инде, дустым, вакытыннан алда күңелеңне төшермә. Берәр ничек чыгу юлын табарбыз. Әбиең өйрәткән догаларны укы.

ШӘКЕРТЛӘРНЕҢ БЕРСЕ *(пышылдап)*. Егетләр, борчылмагыз. Без сезгә ярдәм итәрбез. Чыгу юлын табарбыз. *(Кулларын чишәләр.)* Әйдәгез, әкрен

генә безнең арттан барыгыз. Муллалар күргәнче, картлар килгәнче юк булырга кирәк. *(Китәләр)*

*Бераздан картлар, муллалар әйләнеп кайта, карасалар, тегеләрдән жилләр искән.*

ӘХМӘТ БАЙ. Кайда алар? Ничек жибәрдегез? Ничек качтылар?

МУЛЛА. Әйткән идем аны, алар гади кешеләр генә түгел, шайтаннар дип. Әнә, ничек юкка чыкканнар. Кара көчләр бу! Йә Раббым, сакла безне, кичер безне!

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Шул ук вакытта Күл буе мәдрәсәсендә.*

БЕРЕНЧЕ ШӘКЕРТ. Менә килеп тә життек. Бу безнең Күл буе мәдрәсәсе. Я, сөйләгез инде, кем буласыз, ничек монда килеп эләктегез? Тегендә вакытта сорашып өлгермәдек.

ИКЕНЧЕ ШӘКЕРТ. Егетләр, сез чынлап та киләчәктәнме? Әллә шундый оста итеп шаяртасызмы? Кайсы мәдрәсәдән буласыз?

ӨЧЕНЧЕ ШӘКЕРТ *(киемнәрен тотып карап)*. Каян таптыгыз бу киемнәрне? Ул чабатагыз бигрәк кызык.

ИРЕК, ИЛГИЗӘР. Рәхмәт сезгә! Безне коткаруыгыз өчен Аллаһның мең рәхмәте булсын.

ИРЕК. Әйткән идек инде, без чыннан да, егерме беренче гасырдан килдек. Безнең киемнәр — XXI гасыр яшьләренең көндәлек киемнәре. Ә аякта чабата түгел, кроссовки дип атала. Бик җиңел, уңайлы аяк киеме.

ИЛГИЗӘР. Дөрес. Мин күптәннән вакыт машинасы ясарга хыялланып йөри идем. Ә бүген ясалган машинаның кайсыдыр өлешенә ялгыш басылды. Шуның нәтиҗәсендә без егерменче гасыр башына эләктек.

ШӘКЕРТЛӘР. Кит аннан!? Ә нинди соң ул егерме беренче гасыр? Кешеләр мәгърифәтледер инде...

ИРЕК. Бик дөрес әйтәсез. Әйе, хәзер һәр баланың да мәктәпләрдә түләүсез белем алу хокукы бар. Бик күп фәнни ачышлар ясалган. Компьютер, телефон, Интернет һәр кешедә дә бар диярлек. Алар мәгълүмат эзләү, аралашу өчен киң кулланыла. Кеше хәтта галәмгә дә очкан. Ә татарлар бар дөньяга танылган, дөньяның бөтен почмакларында яшиләр. Татар ул-кызлары арасында бар дөнья белгән галимнәр, спортчылар, җырчы-биючеләр, уйлап табучылар күп.

ШӘКЕРТЛӘР *(кызыксынып тыңлыйлар)*. Алай икән... Ә Тукай дигән шагыйрьне беләсезме соң? Без аның шигырьләрен куен дәфтәренә күчереп алабыз. Их, күрсәң иде үзен!

ИЛГИЗӘР. Габдулла Тукай. Тукай — татар халкының бөек улы, әдәбиятыбыз йолдызы. Аның иҗатын мәктәпләрдә генә түгел, галимнәребез дә өйрәнә. "Туган теле"н халкыбыз үзенең гимны итеп җырлый.

ИРЕК. Кайгырмагыз, Тукайны күрәсегез алда әле. Ул Җаектан Казанга киләчәк. Көтегез генә.

ШӘКЕРТЛӘР. Чынлапмы? Менә монысы өчен рәхмәт. Ә тагын, тагын нәрсәләр сөйли аласыз?

ИЛГИЗӘР. Вакытлы матбугат эшли, нәшрият йортларында меңәрләгән берсеннән-берсе матур гәҗит-журналлар, китаплар бастырыла.

ШӘКЕРТЛӘР *(гаҗәпләнеп, сөенеп)*. Ә Казан һаман да шулай ук матурмы?

ИРЕК. Әлбәттә. Казаныбыз көннән-көн киңәя, үсә, төзекләнә һәм матурая бара. Мәркәзебездә әһәмиятле халыкара бәйгеләр дә үткәрелә әле.

ИЛГИЗӘР. Татар телен, милләтебезне кысрыкларга тырышсалар да, халкыбыз бирешми, көрәшүен дәвам итә. Казан бөтен дөньяга сибелеп яшәүче татарларны берләштерә. Шушы максатларда Бөтендөнья Татар конгрессы эшли. Исеменнән аңлашылганча, бу — бөтен Җир шарындагы татарларны берләштерүче иҗтимагый оешма.

ИРЕК. Ә театрга килгәндә, ул татар халкына бик кирәк. Театр халкыбызның милли горурлыгы булачак. Киләчәк турында уйлагыз, милләтне кайгыртыгыз.

ШӘКЕРТЛӘР *(куанып)*. Шулай булгач, горурланмаслыкмыни безнең милләтебез?!

БЕРГӘ. Әйе, шулай. Карагыз әле, бик дөрес фикерләр әйтәләр бит. Без үзебезнең, балаларыбызның һәм киләчәк буыннарның, халкыбызның киләчәге якты булуын телибез. Безгә театр кирәк булуын яхшы аңладык.

БЕРЕНЧЕ ШӘКЕРТ. Сезгә өйләрегезгә әйләнеп кайтырга кирәктер инде. Әйдәгез, вакыт машинагызны төзәтергә тырышыйк.

ИЛГИЗӘР, ИРЕК. Рәхмәт сезгә!

*Шәкертләр Илгизәр белән Ирекка машиналарын төзәтергә ярдәм итә.* Тырыша торгач, нәрсәдер хәрәкәткә килә.

ИЛГИЗӘР. Рәхмәт сезгә, дусларым. Киләчәккә кыю атлагыз. Курыкмагыз. Мә, дустым, истәлегем булсын. *(Башындагы бейсболкасын салып, беренче шәкерткә кидерә. Тегесе үзенең түбәтәен бирә.)*

ШӘКЕРТЛӘР. Хәерле юл сезгә.

*Көчле яктылык һәм шартлаган тавыш.*

## Дүртенче күренеш

*Илгизәрләрнең ишегалды. Егетләр чирәмдә яталар. Яннарында ватык металл кисәкләре.*

ИРЕК *(әкрен генә торып утыра, башын уа-уа)*. Өнме соң бу, төшме? Менә мажара булды.

ИЛГИЗӘР. Әйтәсе дә юк. Ярый әле әйләнеп кайта алдык. Чыннан да үткәннәрдә булдыкмы соң?

ИРЕК. Башыңда... башыңда... башыңда...

ИЛГИЗӘР. Нәрсә? Телсез калдыңмы әллә? Аңлатып сөйлә? Башыңда? Нәрсә булган?

ИРЕК. Тү-бә-тәй! Башыңда түбәтәй! *(ИЛГИЗӘР башыннан түбәтәен ала. Икесе дә шаккатып басып калалар.)*

ИРЕК *(телен көчкә әйләндереп)*. Башка мондый экспериментларыңда катнашмыйм.

ИЛГИЗӘР *(көлеп)*. Нигә алай дисең? Халкыбызның, илебезнең киләчәге кызык түгелме әллә сиңа? Берәр вакыт киләчәккә дә барып кайтырга кирәк булыр әле. Түбәтәйне киләчәккә илтергә кирәк бит.

ИРЕК. Әйе шул. Илтербез дә без аны.

*Егетләр, елмаешып, кочаклашалар.*

*Зәкиева Диләрә Фирдәвес кызы*

# ӘЛЛИ-БӘЛЛИ БИШЕГЕМ…

*Катнашалар:*

ГАЛИЯ, авыл хатыны. 48–50 яшьләрдә.
ТИМЕРГАЛИ, галиянең ире. 52–54 яшьләрдә.
НИЯЗ, аларның уллары. 24–26 яшьләрдә. Заманча, ләкин әдәпле киенгән.
АЛИНӘ, киленнәре. 20–22 яшьләрдә. Шәһәр кызы.
АЙСЫЛУ, кодагыйлары. 48–50 яшьләрдә.
МАРАТ, кодалары. 50–52 яшьләрдә.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*ГАЛИЯ белән ТИМЕРГАЛИЛӘРНЕҢ өй эче. Аш бүлмәсе һәм йокы бүлмәсе күренә. Аш бүлмәсендә уртада түгәрәк өстәл, шкаф, суыткыч тора. Өстәл өстендә җыеп куелган чәй йомрылары, чәйнек. Чигүле сөлге белән капланып куелган ипи, печенье һәм башкалар. ГАЛИЯ аш бүлмәсендә токмач кисә.*
*Әкрен генә көйли.*

ГАЛИЯ.

Баламның баласы,
Күземнең карасы,
Балдан шикәрләрдән татлы
Мәхәббәт алмасы.

Картәниләр, картәтиләр булуы,
Бәхет икән онык тууы.
Яшәвемнең бездән соң да каласы,
Әй, баламның баласы.

Баламның баласы,
Күземнең карасы,
Балдан шикәрләрдән татлы
Мәхәббәт алмасы.

Менә, Аллага шөкер, мин дә әби булдым! Хезмәттәшләрем оныкларын сөйләгәндә, әй көнләшә идем, көнләшә идем! Менә хәзер мин дә: “Безнеке алай итә, безнеке болай итә…” дигән булып сүзгә кушылырмын, Ходай кушса. Иртән

киләләр дә оныкларын сөйли башлыйлар, киләләр дә оныкларын сөйли башлыйлар! Әйтерсең, башка сөйләр сүзләре юк! Менә минем дә онык туды! Онык! Кызым туды! И-и-и-их, тизрәк күрәсем килә, кулларыма алып сөясем килә инде үзен. Онычым... Кызым... Менә ашым өлгерсә, тәрәзәдән генә булса да барып күрербез инде, Алла теләсә.

*ТИМЕРГАЛИ керә. Кулларын юа.*

ГАЛИЯ. Кердеңме, бабасы?

ТИМЕРГАЛИ. Менә сиңа! Иске авыздан яңа сүз! Нишләп «әтисе» ннән «бабасы» на күчтем соң әле? Картаеп киттемме, әллә?

ГАЛИЯ. Соң, бабай булгач, бабасы инде. Оныгың тугач, бабайга әйләнәсең инде шулай... Әйдә, чәй генә эч тә, авыл тавыгы белән үзем кискән токмачлы ашны бала табу йортына илтеп кайтыйк. Киленнең хәлен белеп, оныгыбызны күреп кайтыйк. Кодагыйлар аш илткәндер инде илтүен, авыл тавыгына җитәме соң инде? Киленгә хәзер шулпа кирәк. Тизрәк савыгып, өйгә кайтсыннар. Оныгымны тизрәк сөясем килә!

ТИМЕРГАЛИ. Мин өй түбәсеннән үзебезнең балалар үскән бишекне алып төшеп куйыйм дип йөри идем...

ГАЛИЯ. Җитешерсең әле, бүген үк өйгә кайтмыйлар ләбаса.

ТИМЕРГАЛИ. Соң, шулай дисәң генә... Калган эшкә кар яумаса ярый инде... Җыен, алай булгач. Юл кешесенең юлда булуы хәерле...

## Икенче күренеш

*Бала табу йорты бинасы. Тәрәзәләргә палаталарның номерлары куелган. ГАЛИЯ белән ТИМЕРГАЛИ, сумкаларын тотып, тәрәзәләрне карап, эзләп йөриләр.*

ГАЛИЯ. Җиденче палата дигән иде. Җиде кая? Күрәсенме? Ә-ә-ә-әнә, тегесе бугай. *(Кычкыра.)* А-ли-нә! Алинә ди-и-им! Ишетте! Күрде! Әйе, әйе! Килдек! Менә икебез дә килдек! Әтиең дә килде! Ничек хәлең? Хәлләрегез ничек ди-и-им? Кыз ничек? Елыймы? Кемгә охшаган? Миңа? *(Тимергалигә карап, сөенеп.)* Миңа охшаган, ди бит! И-и-и, рәхмәт яугыры! Үземнең оныгым, үземә охшаган! Ярый, озак басып торма! Бар, ят! Өзлегә күрмә! Хәзер тавык ашын менгерерләр. Нығытып аша! Ашыйсы килми, димә. Сиңа ашарга кирәк! Китәбез, китәбез! Нияз эштә әле, эштә. Кайткач килер. Ярар, ярар. Әйе. Кайтабыз, кайтабыз. Бәбәйне елатма! Киттек! Сау бул!!!

ТИМЕРГАЛИ. Бар, балам, бар! Саклanганны саклармын, дигән...

*ТИМЕРГАЛИ кул болгап саубуллаша. ГАЛИЯ сөйләнә-сөйләнә кайту ягына китәләр.*

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*ГАЛИЯЛӘРНЕҢ өе. Аш бүлмәсендә ГАЛИЯ, ТИМЕРГАЛИ, АЙСЫЛУ, МАРАТ. Табын артында чәй эчеп утыралар.*

АЙСЫЛУ. Кодагый, нинди исем куярга уйладылар балалар? Миленамы, Каринамы дигән иде шунда Алинә...

ГАЛИЯ. Соң, баласын үзләре тапкач, исемен дә үзләре тапканнардыр әле! Нинди исем кушыйк дип бездән сорамадылар. Мин үзем, Айзирәк дип кушсак дигән идем. Айзирәк! Зирәклегенә сокланырлык кыз бала дигәнне аңлата.

АЙСЫЛУ. Азалия — бик матур исем! Эре чәчәкле гөл исеме.

МАРАТ. Бергә укыган кызның исеме — Айназ. Ай кебек чибәр, нурлы, сөйкемле һәм назлы, якты йөзле, төз-зифа буйлы кыз иде. Мин Айназ кушу яклы.

АЙСЫЛУ. Әйе, бөтен яраткан кызларыңның исемнәрен оныкларыңа куша башласаң, оныклар гына җитмәс. Миңа Айназ исеме бөтенләй ошамый!

ТИМЕРГАЛИ. Балалар үзләре ни диләр соң? Мин Ләйсән дип йөрим инде оныгыма... Беренче язгы яңгыр вакытында туды бит...

ГАЛИЯ. Әйе, өч кызның икесе — Ләйсән! Әллә башка исем беткән инде дөньяда?!

МАРАТ. Луиза Ниязовна! Ничек матур яңгырый!

ГАЛИЯ. Юк-юк! Безнең авылдагы чатан Луизаны күз алдыма китерәм! Кушаммы соң! Бүтән исем бетмәгәндә... Наилә — теләгенә ирешүче кыз. Наилә Ниязовна! Бик матур бит!

*Шау-шу китә. Барысы да үзенең исемен матур дип саный. Берсе артыннан берсе яңа исемнәр ишетелеп тора. Ишектән НИЯЗ кайтып керә. Аны күрүче юк.*

НИЯЗ. Кемгә исем сайлыйсыз ул? Без исемне сайлап куйдык инде. Малай туса — Нариман, кыз туса — Назлыгөл! Нариманны икенче юлга калдырып торабыз. Кызым — Назлыгөлем! Йә, ничек?

*Өлкәннәр бер мәл тавыш-тынсыз торалар. Саналган исемне кушмаганга үпкәләгән кебек утыралар.*

ГАЛИЯ. Карале, мыштым гына, исем уйлап куйганнар ләбаса! Исемнең дә ниндие! Беркемдә юк мондый матур исем! Назлыгөл! Назлы Гөл! Назлыгөл Ниязовна! Бәхетле-тәүфикълы, тигез канатлы булсын!

ТИМЕРГАЛИ. Улы барның үзе бар, кызы барның эзе бар, ди татар халык мәкале. Менә инде эзегез булды. Җир йөзендәге иң бөек исем — әти белән әни исемнәренә лаек булдыгыз. Моны сезгә нәни мәхәббәт җимешегез бүләк итте. Назлыгөлебез тормышыбызның иң нәфис, иң кадерле чәчкәсе булып, тор-

мышыгызга ямь, мәхәббәтегезгә — көч, сафлык өстәп, сау-сәламәт, зирәк акыллы булып үссен!

АЙСЫЛУ. Назлыгөл кызыбыз сәламәт, акыллы максатчан, рәхимле, иманлы бала булып үсүен телибез.

МАРАТ. Кияү! Синең кулда ике кыз хәзер. Алар өчен син җаваплы. Ялгызятим, ач-ялангач итмә! Хәзер бәби кайтуга исем кушуга әзерлек эшләрен карыйк.

ТИМЕРГАЛИ. Әйе, дөрес, кода! Шайтан исем кушмасын, ди халык. Исемне тизрәк кушу ягында мин дә! Ә аңа кадәр өйне юу, өйне пакълау йоласын үтәп аласы бар.

### Дүртенче күренеш

*ГАЛИЯЛӘРНЕҢ өч эче Озын өстәлләргә аш табыны әзерләнгән. Өстәлдәге ризыклар сөлгеләр белән капланып куелган. Өстәлнең ике ягында кунаклар утыралар. Ир-егетләрдә түбәтәй, хатын-кызлар яулык бәйләгән. МУЛЛАНЫҢ каршына кыйблага каратып мендәр салынган. Мендәрдә яңа туган бала ята.*

*МУЛЛА баланың уң колагына азан, сул колагына камәт әйтә. «Синең исемең Назлыгөл НИЯЗ кызы» дип колагына пышылдап әйтә. Аннан соң, Коръәни Кәримнән бер сурә укып, дога кыла. Баланың иленә, милләт һәм диненә файдалы кеше булып җитешүе өчен дога кыла. Әти-әнисен тәбрик итә.*

МУЛЛА. Йә, Раббым! Ошбу балага хәерле гомер, хәерле сәламәтлек, хәерле гыйлем, хәерле һөнәр, хәерле кәсеп биреп, динебезгә, илебезгә, милләтебезгә файдалы, әти-әнисенә миһербанлы, шәфкатьле бала булып үсеп җитүен насыйп ит. Ошбу баланы Ислам динен куәтләүче һәм Пәйгамбәребезнең өммәте кыл. Әти-әнисенә бу баланы шатлык-сөенеч, тигезлек белән үстереп, шатлык-сөенечләрен генә күрергә насыйп кыл. Үсеп җиткәч, хәерле бәндәләреңне насыйп итеп, матур гаилә коруларын да насыйп кыл. Әмин.

ХӘЕР ТАРАЛА. Кабат дога кылына. Кунаклар балага дип, бүләкләрен тапшыра. Йола аш өстәле артында дәвам итә.

### Бишенче күренеш

*ГАЛИЯЛӘРНЕҢ өе. Йокы бүлмәсе. Бала елый. Бер-бер артлы чиратлашып баланы күтәреп йөриләр. Баланы арбада тирбәтеп карыйлар. Бала тынмый.*

ГАЛИЯ. Бер-бер ярамаган әйбер ашадыңмы әллә, Алинә? Балага сөт белән күчкәндер. Эче авыртадыр. Эченә җылы чүпрәк куйдыңмы? Су эчәсе килмиме? Кызу түгелме? Суык түгелме?

*Галия бер-бер артлы сорау яудыра. Алинә «Әйе», «Юк» дип башын гына селкеп җавап бирә. Әле берсе, әле икенчесе кулга ала баланы. Бала елаудан туктамый.*

ГАЛИЯ. Исем кушканга өч көн. Өч көн, өч төн елый бит инде. Врач чакыртыйк. Карар. Әйтер. Йә сөтең җитмидер, йә артып китәдер. Булмый болай, булмый, булмый...

*Барысы да бала белән мәшгуль. ТИМЕРГАЛИ чыгып, кулына бала бишеге күтәреп керә. Бишекне урынына элеп куя. Бала чүпрәкләре җәеп, урын әзерли.*
*Баланың мендәр астына изге Коръән китабын куя.*
*НИЯЗ кулыннан баланы ала. Әкрен генә сөйли-көйли баланы юата.*
*Бала тыныч, сабыр ир-ат тавышын ишетеп, тынычлана башлый.*

ТИМЕРГАЛИ. Сабыр иткән-морадына җиткән. Сабыр бул! Менә тиздән иртә җитәр. Кояш сине җылы нуры белән иркәләр, кошлар сиңа матур җырларын бүләк итәр, йомшак җил бишегеңне тирбәтер. Бу бишектә синең әтиең үсте. Еламыйча, зу-у-ур булып үсте! Йәле, син дә ятып карале! Мин сиңа “Бишек җыры” көйләрмен.

Әлли-бәлли көйләрмен,
Хикәяләр сөйләрмен.
Сиңа теләк теләрмен,
«Бәхетле бул», диярмен.

Йокла, кызым, йом күзең,
Йом-йом кузең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.

Әлли-бәлли ит, балам,
Йокыларга кит, балам.
Гүзәлемнең гүзәле,
Йөрәгемнең үзәге. Бә-ә-әлли-бәү!

*Бала бишектә тынычлап йоклап китә. Әкрен генә ут сүнә. Пәрдә төшә.*

*Закирова Зилә Рамил кызы*

# ТУГАН ТЕЛЕМ — ҮЗ ТЕЛЕМ

*Катнашалар:*

БАБАЙ.

ӘБИ.

АЛСУ, оныклары, авылда тора.

ДЕНИС *(соңыннан Илнур)*, оныклары, шәһәрдә тора.

ЭЛЬВИНА *(соңыннан Гүзәл)*, оныклары, шәһәрдә тора.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Авыл өе күренеше. Әби белән бабай өйдә утыралар. Әби оек бәйли, бабай газета укый.*

ӘБИ. Оныгым Алсу мәктәптән кайтыр инде. Чәй куйыйм әле.

БАБАЙ. Бүген бит шимбә көн. Казаннан да балалар кайтыр инде.

ӘБИ. И-и-и..Онытып та торам. Коймак куеп җибәрим әле.

*Алсу кайтып керә.*

АЛСУ. Татар теленнән диктант яздык. Әбием, бабаем мин “5”легә яздым. Киләчәктә татар теле укытучысы булачакмын.

БАБАЙ. Син булдырасың инде, кызым.

ӘБИ. Үз телеңне белү бик кирәк ул. Ул бит безнең туган телебез. Әби-бабайларыбыз сөйләшкән тел. Аны онытырга ярамый.

АЛСУ. Бүген Ильвина белән Денис та кайта бит.

БАБАЙ. Кызым, алар гел русча сөйләшә.

ӘБИ. Сүзләрен дә аңлап бетермибез.

АЛСУ. Мин аларны татарча сөйләшергә өйрәтәчәкмен.

ӘБИ, БАБАЙ. Рәхмәт, кызым.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Шәһәрдән Денис белән Ильвина кайта. Модный итеп киенгәннәр. Урысча музыка уйнаталар.*

ДЕНИС. Как красиво.

ИЛЬВИНА. Как хорошо пахнет.

ДЕНИС. Здравствуй, дедушка! Здравствуй, бабушка!

ИЛЬВИНА. Здравствуйте.

А Л С У. Поздоровайтесь по-татарски. Исәнмесез!

ДЕНИС, ИЛЬВИНА. Мы начали изучать татарский язык.

А Л С У. Хорошо. Это же наш родной язык. Мы должны любить свой язык, свои традиции.

И Л Ь В И Н А. Научи нас.

Д Е Н И С. Я тоже хочу разговаривать, читать по-татарски.

А Л С У. Ладно. Әбием, бабаем, алар татарча өйрәнергә телиләр.

Б А Б А Й. Рәхмәт, балакайларым. Үз телеңне белү, татар булуың белән горурлану бик мөһим.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Ике ел узган. Б А Б А Й телевизор карый, Ә Б И гөлләргә су сибә. Д Е Н И С белән И Л Ь В И Н А исемнәрен үзгәрткәннәр. И Л Н У Р белән Г Ү З Ә Л керәләр. Матур итеп киенгәннәр.*

И Л Н У Р. Әбием, исәнме.

Г Ү З Ә Л. Нихәл, бабай.

Ә Б И *(күз яшен сөртә)*. Минем оныкларым түгелме соң болар?

Б А Б А Й. Әйе шул. Кара син аларны. Туган телебездә ничек матур сөйләшәләр, күр син!

Г Ү З Ә Л. Туган телебезне яратыйк, кадерен белик!

И Л Н У Р. Саклыйк һәм яклыйк телебезне, илебезне, халкыбызны...

А Л С У. Кемнәр генә сиңа сокланмаган һәм мактау җырламаган?! Кемнәр генә синең ярдәмеңдә дөньяны танып белмәгән һәм үзенең уй-хисләрен башкаларга сөйләмәгән?!

И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.

Тик синең ярдәм белән мин,
Тик синең сүзләр белән
Уйларын йөрәккәемнең
Дөньяга әйтә беләм.

*Б А Б А Й, Ә Б И оныкларын кочаклыйлар. Сәхнә артында «Туган тел» җыры яңгырый. Катнашучылар җырга кушыла.*

*Газимҗанова Гөлинә Фәрһад кызы*

# ЮРИ-МАРИ ЧЫН КАТЫШ...

*Катнашалар:*

ӘБИ
БАБАЙ
КӘҖӘ
САРЫК
ШҮРӘЛЕ
СУ АНАСЫ
ШҮРКӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Авылда ишегалды күренеше. Җәй. Кояшлы көннәр. Төрле тавышлар ишетелә, әтәч кычкыра, тавыклар кыткылдый. Эскәмиядә ышыкта бик хозурланып КӘҖӘ белән САРЫК утыра. БАБАЙ керә.*

БАБАЙ. Кыздыра, малай, шәп. *(Кәләпүше белән тирләрен сөртеп ала, КӘҖӘ белән САРЫКНЫ күреп алар янына килә.)* Нәрсә, әрәмтамаклар, ятасызмы? Ичмасам, җәй челләсендә үз тамагыгызны үзегез кайгыртыр идегез? *(Аларны куып үзе утыра.)*

КӘҖӘ. Бабай, син җиббәрелмәле алай! Әле генә мәтрүшкәле чәеңә нинди сөт салып эчтең соң?

САРЫК. Э-э-э, сөйләмә-ә-ә дә.

БАБАЙ. Сиңа пртинзәм юк, Кәҗә. Тик менә Сарыкка ачуым килә, һич файдасы юк, ни сөте...

САРЫК. Җоным бар ич, елына ике мә-ә-ртәбә кыркып аласыз бит!!!

БАБАЙ. Әйтер идем йоныңны, базарда килосы ун сум тормый. Кәҗәнең сөтенең бәясе бар аның.

*ӘБИ керә. Кулына тавыклар өчен җим тотып сөйләнә-сөйләнә керә.*

ӘБИ. Шулай, җаныкайларым, шулай тәтикәләрем. Ашагыз, ашагыз да ышыкка ятыгыз.

БАБАЙ *(үчекләп)*. Ашагыз да ятыгыз. Бабагыз азык кайгыртыр...

ӘБИ. И карткаем, ник алай кирле-мырлы сөйләшәсең әле, ул мәхлүкләрнең ни гаебе бар?

БАБАЙ. Әй, сезнең белән тел арытып утырганчы балыкка барам мин.

ӘБИ. Йөрисең инде, кеше көлдереп. Ичмасам берәр кочак кына булса да печән чабыр идең. Әнә Кәҗәкәй белән Сарык мөлдерәп карап торалар. Алып кайтышырлар иде. Шулай бит, йомшаккаем? *(САРЫКНЫ иркәли.)*

САРЫК *(әбигә сырпаланып)*. Ә-ә-ә-әби, бабай миңа ә-ә-әрәм тамак ди!

ӘБИ. Әрәм тамак диме? Анысы нинди сүз инде? Син минем тәтием бит, йомшагым, син булмасаң минем бәрәңге кабыгын кем ашый? *(САРЫК бик канәгать булып иркәләнә.)*

БАБАЙ. Үләрсең кыланлышларына. Киттем мин балыкка. Печәнне үзләре кыркып ашасын. Кая, бераз кабарга әзерлисеңме? Җимгә дә кирәк әле.

ӘБИ. Син бер киреңә катсаң, үз дигәнеңне итмичә калмассың инде!!! Хәзер, әзерлим, сабыр ит. *(КӘҖӘ белән САРЫКНЫ иркәләп ала.)* Сез барыгыз, әнә тегендә болында чемченеп кайтыгыз, күбәләкләр куыгыз, бераздан үзем дә төшәрмен, кышкылыкка тал миннеге сындырырбыз, яме.

КӘҖӘ белән САРЫК. Я-я-ме-е-е. (ӘБИ авыз эченнән көйли-көли кереп китә.)

БАБАЙ. Карап-карап торам да, артык әбиегезгә аркалана башлагансыз икән, ә? Кем сезгә печән чаба, кем сезнең лапасны кора?

КӘҖӘ. Бабай, ни булды сиңа бүген? Гел ачуланасың да торасың?

САРЫК. Сул аягың белән тордыңмы әллә-ә-ә-ә-ә?

БАБАЙ *(ачуланып)*. Минем кай аягым белән торуымда синең ни эшең? Ачуланырсың да, тәки күз өстендә каш кебек булдыгыз! Сезне генә кара, сезгә генә матур сүз. Әнә яраткан эскәмиямә дә хуҗа булып кунаклагансыз! Кәҗәгә сүзем юк, тырыша, сөтен бирә, дәүләте дә әнә аны малга чутлап, субсидия бирә башлаган… *(КӘҖӘ бу вакытта горур атлап китә дә, койма аркылы күренеп торган чәчәкне өзеп ала.)* Әй, син аны мактаган буласың, ул алдында ук зыян итә. Чистый туйдырдыгыз!!!

КӘҖӘ. Туйдырсак, бабай, сат. *(Үзе чәйни, үзе сөйли.)*

САРЫК. Ә-ә-әмма да ләкин син безне сатмыйсың, чөнки син сөтсез чәй эчә алмыйсың. Ә Сыербикә астайга көчең җитми.

БАБАЙ. Син нәрсә, пичәт сугучы сикритар мәллә? Ат дагалаганда сарык ботын кыстырган ди. Быел корбанга чалам мин сине. Белеп тор!

КӘҖӘ. Сарык түгел, бабакай, бака ботын кыстырган.

БАБАЙ. Ну күп беләсең, ә?

САРЫК. Юк, бабай, чалалмыйсың!

БАБАЙ. Нишләп әле, кем миңа указ? Әллә синме? *(КӘҖӘГӘ карап.)* Әллә синме?

КӘҖӘ. Указың өйдә-ә-ә-ә!

САРЫК *(башын югары күтәреп, БАБАЙ каршына килеп колагын суза)*. Менә кара, югалмасын, адашмасын дип, кем минем уң колагымның яртысын, йон кырка торган кайчы белән шарт итеп кисеп алды?

БАБАЙ. Аны әйтәсең икән... Корбанга ярамагач, ниемә генә асрап ятам соң мин сине? Бар, үз көнеңне үзең күр, алай бик герой да булгач. *(Аякларын бөкләп эскәмиягә менеп утыра.)*

САРЫК *(аптырап кала)*. Бабай, син нәрсә? Чынлап сөйлисеңме?

КӘҖӘ. Шаярта инде! Әйтәм бит, ул сөтсез...

БАБАЙ *(аны бүлеп)*. Чәй эчә алмаганны белдек бит инде. Мин сине куммыйм, сарыкны гына куам. Бер файдасы юк, йоны әнә келәттә капчыклап ята, туктамыйча унбиш ел оекбаш бәйләсәң дә бетәсе юк. Китсен. Кирәге юк. Әбиеңнең тәмлеләре сиңа күбрәк эләгер.

САРЫК *(еларга җитешә)*. Бабай, син ник ала-а-а-ай?

БАБАЙ. Менә шулай. Ятма монда бушка икмәк ашап. Сезгә печән әзерлим дип җәйнең җәендә ял күрмим, кыш чыгарга өч капчык бәрәңге җитә үзебезгә. Юк. Әбиегез «Кәҗә белән Сарыкка нәрсә ашатырбыз?» — дип бөтен буш бакчаны чәчтерә. Җитте. Бер кәҗәгә аухатым җитә, ә син бар, үз көнеңне үзең күр.

*САРЫК бик юашланып кала. Акрын гына чыга башлый. Нидер өметләнеп борылып-борылып карый.*

КӘҖӘ *(тып итеп БАБАЙ каршына барып баса)*. Бабай, аны куасың икән, мин дә китәм. Һәм син чәеңне сөтсез эчәрсең!

БАБАЙ. Куркыттың. Һай куркыттың. Тез буыннарым калтырап тора менә. Бар китә бир. Әллә пинсәм ярты литр сөт алырга җитмәсме? Сезгә дигән курмыга сөт алсам, ваннасын ясап яталам мин!

КӘҖӘ. Ярый алайса, бабай, хәерлесе булсын! Сарык дус, көт мине!

*КӘҖӘ чыгып китә. БАБАЙ берүзе.*

БАБАЙ. Кара, ничек бу минем элегрәк башыма килмәгән соң? Шул икесе хакында, аларның тамагы дия-дия, бер көн үзем өчен яши алмадым бит, әй! Карчыкка гына ничек аңлатырга булыр? Кайтмагач, эзләгән булырмын, берәр атна эзләгәч, этләр ботарлаган икән дип сөякләр табыштырырга булыр...

*ӘБИ керә.*

ӘБИ. Кем белән сөйләшәсең, карткаем?

БАБАЙ. Шулай үзем белән шунда. Кәләпүшем белән серләшәм. Син, карчык, бүген үк силсәвиткә чыгып, Кәҗәнең субсидиясен алыпкайт әле. Дәүләтнекен белмәссең, закуннары бүген бар, иртәгә юк дигәндәй.

ӘБИ. Ярар, шулай итәрмен. Менә сиңа төенчек, озак юанма, малларны барлап ябарга кайтып җит. Ике күкәй, бер литр кәҗә катыгыннан әйрән куйдым, бу эсседә сусауны яхшы баса ул. Баруга ышыкка куй, җылынмасын.

БАБАЙ. Ату белмәсләр. Аннары акчаңны алгач, кибет аша кайт. Кирәкярагыңа тот ул субсидине диюем инде.

ӘБИ. Ник, без аңа Кәҗәкәй белән Сарыккайга курмы алмыйбызмени?

БАБАЙ. Әле вакыт бар, алырбыз әле.

ӘБИ. Әле соң матуркайларым кая китте?

БАБАЙ. Матуркайларың син кушкан җиргә китте.

ӘБИ. Исән-сау гына йөрсеннәр инде, бар карап торган куанычым шулар бит инде.

БАБАЙ. Ә мин?

ӘБИ. Син? Юләркәем, әллә көнләшәсеңме инде? Син таянычым минем. Җә, бар, күп сүз юк сүз.

БАБАЙ. Киттем.

ӘБИ. Исән йөр. Чуаркайларымның тамаклары туйгандыр, оялары күкәй белән тулгандыр... Карыйм әле. Чеби-чеби... *(Сөйләнеп чыгып китә.)*

### Икенче күренеш

*Су буе. Алгы планда басмада озын чәчләрен алтын тарак белән тарап, СУ АНАСЫ утыра. Кошлар сайраган тавыш. Арттан БАБАЙ керә. Аны күреп туктап кала. Талларга ышыкланып качып кына күзәтә.*

СУ АНАСЫ *(чәчләрен тарый, җырлый)*. Алтын таракларым белән чәчемне тарыйм әле... Их, бүген күңелем әллә нигә ашкына шунда! Менә шуннан, күкрәгемнән меңләгән күбәләк очып чыгарга тилмергән кебек бәргәләнә шунда. Нидер булыр төсле. Эчем дә пошып куя... Менә чәчләремне тарадым да. Ничек мин? Матур булдыммы? *(Нидер эзли.)* Әй, көзгемне онытканмын икән. *(Ашыгып кереп китә — суга чумган тавыш ишетелә, алтын тарак басмада кала.)*

*БАБАЙ әкрен генә килеп таракны ала. Өскә күтәреп карый. Тешләп карый. Күзлеген киеп бер ерак куеп, бер күз төбенә китереп карый.*

БАБАЙ. Алтын тарак!!! Алтын бит!!! Шул тарак!!! Нәкъ үзе. *(Кулы белән үлчәп авырлыгын белмәкче була.)* Килага ук тармаса да, бер җиде йөз граммнар гына бар! *(Яратып яңагына куя.)* Балачактан бирле төшләремә кереп йөдәткән алтын тарак...

*СУ АНАСЫ керә. БАБАЙНЫ күрә, соңгы җөмләләрне тыңлап тора. Нидер исенә төшермәкче булып кашларын җыера, уйлана.*

С У  А Н А С Ы. Әй, бабай! Нәрсә, сине кеше әйбереңә кагылмаска яшьлегеңдә өйрәтмә-деләрме әллә?

Б А Б А Й *(сискәнеп китә, тарагын артына яшерә)*. Кеше әйберенә? Син кешеме?

С У  А Н А С Ы. Кеше булмаганымны һәйбәт беләсең бит! Таракның минеке икәнлеген дә беләсең? Таныйм бит мин сине, Бабай! Малай килеш бер тапкыр алтын тарагымны урлаган идең. Күрәм, алтыдагы алтмышта диюләре хак икән!

Б А Б А Й. Юкны сөйләмә, бу тарак минеке!

С У  А Н А С Ы. Алтын күргәч, фәрештә дә азганмы әле? Килешми, бабай, олы кешегә шулай бала-чага сыман алдашып тору килешми. Мөгаен, балыкка дигән булып, гел шул тарakны өмет итеп йөргәнсеңдер әле. Мин сине гел күзәттем бит!

Б А Б А Й. Хак әйтәсең, малай чакта кулларыма эләккән бу тарак гомер буена да онытылмады. Балыкка йөрүем дә шул сәбәпле иде, дөрес сукалыйсың. Шулкадәр байлыкның су төбендә әрәм ятуына гел эчем пошты.

С У  А Н А С Ы. Су төбендә? Соң ул бит минеке. Минем үз өемдә. Ничек чит малга эчең пошты? Бир таракны!

Б А Б А Й. Бирмим! Менә син үзең чибәр генә. *(Аны карап әйләнә.)* Буйсының да килешле. Моннан алтмыш ел элек нинди булсаң, хәзер дә шул ук. Картаймыйсың да димәк. Әллә ни эш тә кырмыйсың, чәч тарап көязләнүдән бушамыйсың.

С У  А Н А С Ы. Анысы инде синең эш түгел! Бир таракны! Син аның нинди көчкә ия икәнлеген белмисең бит!

Б А Б А Й. Юк, дидем бит инде! Менә миңа шунысы кызык, озын кышларны ничек уздырасың син?

С У  А Н А С Ы. Су дөньясы киң бит ул. Бөтенесе дә боз белән капланмый. Бир дим тарагымны? *(Ыргылып куя.)*

Б А Б А Й. Чү, кызма, таракны бирмим. Син аның күпме торганын беләсеңме? Уйлап кына урнаштырсаң, бу тарак бәясенә шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән ике катлы йорт салып була. Бассейны, саунасы, мунчасы дигәндәй... Кунак ашы кара каршы: тарак миңа, ә мин сине үземә чакырам. Кышларын җылы сулар эзләп йөргәнче, бассейнда гына ятарсың, яңа йортка бичә булырсың! *(Су анасын кочакламакчы була, тегесе бу кадәр әрсезлектән аптырап кача, суга сикергән тавыш ишетелә.)* Качты, ялындырмакчы була, ну чибәр үзе! *(Су анасы киткән якка карап кычкыра)* Төнлә килеп әнисенә әйтермен дә, таракны алып китәрмен дип хыялланма! Кайтыйм тизрәк, белмәссең, бөтен су пәриләрен котыртып чыкса... Әтидән калган теге мылтыкны навсяки случи чормадан алып куярга кирәк! *(Чыгып китә.)*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Беренче күренештәге ишегалды. БАБАЙ эскәмиядә мылтык чистартып утыра. Як-ягына карана да, корсагына кыстырып куйган җирдән чүпрәккә төрелгән алтын таракны ала. Җиргә утырып аны сөртә, таракны тота, яңакларына тидереп яратып ала. ӘБИНЕҢ тавышы ишетелгәч, тиз-тиз генә кире җыеп кыстыра да, урынына утырып мылтыгын капшый башлый. ӘБИ керә.*

ӘБИ. Йөрмәгән тыкрыгым, карамаган тал төбем калмады. Икенче көн инде минем йомшаккаем белән сөтлекәем юк. Йөреп аякларым талды. Чакыра-чакыра тавышым бетте. Ниләр генә булды да, кайларда гына йөриләр икән минем тәтекәйләрем? *(Елый башлый.)*

БАБАЙ. Таптың елап утырырга сәбәп! Кайтырлар әле. Ашаган җиренә малның кайтмыйча калганы юк.

ӘБИ. Инде бит кайтырлар иде, беркайчан сүземнән чыкмыйлар иде бит. Күземә генә карап торалар иде.

БАБАЙ. Әллә, мәйтәм, карчык, теге ниме...

ӘБИ. Ниме? Туктале, син нәрсәдер яшермисеңме?

БАБАЙ. Нәрсә яшерим? Юк. Ниме диюем, урман ягына таба китеп, бүре авызына эләкмәделәрме икән дим?

ӘБИ. Шулай дисеңме? *(Кычкырып елап җибәрә.)* И-и-и, бәбекәчәйләрем!

БАБАЙ. Котны алып! Кара ничек кычкыра! *(Бераз икеләнеп торгач.)* Менә карчык, елама, кара әле! *(Алтын таракны ала, күрсәтә.)*

ӘБИ. Нәрсә бу? Әллә алтын инде?

БАБАЙ. Алтын!

ӘБИ *(елмаеп җибәрә)*. И картым, миңа инде картлык көнемдә мондыен ук алтын тараклар алып мәшәкатьләнмәсәң...

БАБАЙ. Сиңа? Юк, мин моны таптым, карчык. Моны алып булмый, моның бәясенә шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән ике ятажлы өй җитештереп була. Бассейн белән...

ӘБИ. Кит, сиңа нигә бассейн? Икенче ятажы ниемә тагын?

БАБАЙ. Соң син беренче ятажында торырсың, ә без...

ӘБИ. Әй хыялый хәчтерүш! Ярар китим әле мин!

БАБАЙ. Кая китәсең?

ӘБИ. Урманга. Бәбекәчәйләрем, мөгаен, шунда гына адашкан. Күңелем сизә, менә шулайлар итеп нидер сизә.

БАБАЙ *(үзалдына)*. Сизә пычагым! Алар әллә кайчан бүре авызына эләгеп...

ӘБИ. Нәрсә дисең? Бүре дисеңме?

БАБАЙ *(ӘБИГӘ куштанланып)*. Йөрмә дим, карчык, урманда ни булмас дисең? Бүре авызына эләксәләр, язмышлары шул булгандыр дим.

ӘБИ. Фәрештә кебек акыллы бәбекәчләремне ничек оялмыйча ашар икән бүре? Ашаган икән, күземә карап әйтсен. Мин болай билгесезлектә яшәргә җыенмыйм.

БАБАЙ. Һай, үзсүзле дивана карчык! Ничек бүре сиңа "Шулай шул, әби, ашадым шул!" — дип торыр инде?

ӘБИ. Ник тормасын? Ашамаган булса, нахак гөнаһ кирәгерме аңа? Мәрхүм әбием сөйли торган иде, Йосыф пәйгамбәр кыйссасында бүре үзенә яккан яладан телгә килгән, дөресен сөйләгән дип. Юк, менә поша эчем, менә әллә ничекләр иттереп поша. Туктале, теге ике ятажлы йортның икенче ятажы кемгә диден әле?

БАБАЙ. Ай, барсаң бар инде. Берсен башлап, икенчесен ташлап…

ӘБИ. Барам да. Ярый, көн кичкә авышканчы йөреп кайтыйм. *(Кузгала, нидер уйлап, басып тора, кире борыла.)* Карткаем, бу мылтыгыңны тәккә кузгатмагансыңдыр бит, әйдә икәү барабыз. Үзем генә шүрлим дә. Аннары төн буе җүләр кебек тәрәзә каршында утырып чыктың, үзең дә борчылырсың бит!

БАБАЙ. Кем? Минме борчыла? Йоклый алмадым, әнә баш бармак буе чикерткә төн буе җырлап йокыны качырды, шуны сакладым.

ӘБИ. Әллә нишләдең әле, картым, әллә нишләдең!!! *(Чыгып китә.)*

БАБАЙ *(үртәп)*. Әллә нишләдең, әллә нишләдең, имеш! Кулыңа ыжгырып нахаляву шул хәтле байлык керәм дип торсын да, син йокла имеш. Ну малай, теге су пәрие шәп! Сөякләрен шыгырдатып берне кочакласаң, мамент яшәрәсеңдер инде ул. Йокламадым, төне буе көттем, теге вакыттагы кебек: "Кая минем алтын тарак!" — дип килеп җитәр дип шикләндем. Килмәде. Димәк, минем тәкъдимне кабул иткән! *(Кабат алтын таракны ала, сыйпый, ярата, соклана.)* Хәзер аны һәйбәтләп тиешле бәягә урнаштырасы гына инде. Ә теге карчык миннән Кәҗә белән Сарык эзләтмәкче. Җүләр димә инде шуны!

## Дүртенче күренеш

*Урмандагы матур алан. Кошлар сайрый. Арттарак ШҮРӘЛЕ утырган. Ул чикләвек ватып ашый. Үзалдына моңланып җырлый.*

ШҮРӘЛЕ. Кара гына урман, караңгы төн, яхшы атлар кирәк үтәргә… Юк инде, кара урман да, яхшы атлар да юк. *(Чикләвек вата, кортлысы эләгә.)* Ай, мең кәррә гафу! Хөрмәтлем, һич кенә дә сезнең йортыгыз дип белмәдем. Әйдә мин сине куакка озатыйм, үзеңә яңа өй яса. *(Урыннан тора, кортны куакка җибәрә.)* Шулай, менә шулай, барыбыз да Аллаһы коллары, уртак йортыбызда урын һәмммәбезгә җитә дә бит соң?

*Ул шулай сөйләнеп торганда бик арыган КӘҖӘ белән САРЫК килеп керә. КӘҖӘ сөзәргә әзерләнә, САРЫК аның артына ышыклана. Тыңлыйлар.*

ШҮРӘЛЕ. Кара урман дип җырлыйсы гына калды... Бетте теге урманнар, калмады. Әле кичә төньяк урманнарны йөреп кайттым. И андагы хикмәт! Ярты урманны кискәннәр, нинди дер тимерләр бастырганнар, алар үзалдына бер менеп, бер төшеп торалар. Җир маен суыралар. Ә бит ул урында җиләклекләр иде... Йомык күз белән кырын ятып җыярлык. *(Кәҗә белән Сарыкны күреп ала.)* Кунаклар бар икән! Эндәшмичә кеше сүзен тыңлап йөрү егетлек түгел инде.

КӘҖӘ. Шикләнмә. Яман ният белән йөрмибез.

САРЫК *(бәтрәкләнә, тик һаман Кәҗә артына кача)*. Әмм-мә-ә дә ләкин үзебезне дә обидага бирмә-ә-әйбез!

ШҮРӘЛЕ. Хуш, танышыйк. Кемнәр соң сез? Бу урманда ни эшләп йөрисез? *(Карап әйләнә.)* Бер дә урман затларына охшамагансыз.

САРЫК. Без авылдан. Мин — Сарык, ә юлдашым минем...

КӘҖӘ. Сарыклыгыңны итмә инде и, Сарык, кем кара урман уртасында бөтен серне беренче күргән затка ача!

ШҮРӘЛЕ. Димәк, сез авылдан? Мин Шүрәле абзагыз булам! Ишеткәнегез бармы? Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым... *(Бармакларын селкеткәләп килә.)*

КӘҖӘ. Но, но! Син нәрсә, авылдан дигәч тә безне теге, ни дип белдеңме? Ну-ка, Сарык, чыгар әле капчыктан бүре башын, күчтәнәчне! *(Сарык ни эшләргә белми, сер дә бирәсе килми, капчыкта бүре башы да юк.)*

ШҮРӘЛЕ. Һа-һа-һа-һа! Үтерәсез көлдереп. Бүре башы дисезме? Бүре башы... Һа-һа-һа... Уф, күптәннән болай көлгән юк иде. Сез соң ул бүре башын үзегез ясадыгызмы? Безнең урмандагы соңгы бүреләрне моннан җиде-сигез кыш элек аулап бетерделәр бит. Исән калганнары төньяккарак китте. Урманда сыңар гына бүре калган булган очракта, Кәҗә белән Сарык парлашып урман буйлап подручком йөрер идеме?

КӘҖӘ. Анысы шулай инде шулаен да... Үзең бит, Шүрәле, котны алып, бармакларыңны селкеп киләсең.

САРЫК. Әллә ирекле баштан йөриләр дип беләсеңмее-е-е? Сезнең рәхәт ул, урман үз йортыгыз булгач та...

ШҮРӘЛЕ. Чү, әллә елыйсың инде? Үз йортыгыз имеш, үз йортыңа үзең хуҗа булмауның ни икәнен аңлыйсызмы сез? Әнә кара, кичә генә балигълык яшенә җиткән сылу каен кызын ничек мәсхәрә иттеләр: миннек ясарга дип егып салдылар да, ботакларын тападылар. Ә мин аны җиде кыш рәттән иркәләп үстергән идем!

КӘҖӘ. Син карап тордыңмы? Килеп чыгасың булган да сөзеп егасың булган!

ШҮРӘЛЕ. Егарсың, бар. Менә кара. *(Кулларын күрсәтә, бер кулының бармаклары кыскарак.)* Яшьлегемдә бер кат менә шушы аланда үз йортымны яклап караган идем мин. Нәкъ менә шушы аланда, менә шушы имәнне... *(Уртадагы төпчекне күрсәтә.)* Бу агач урманның йөрәге иде. Бөтен урман җыелышлары шул имән төбендә үтә иде... *(Төпчеккә утырып уйга бата.)*

САРЫК. Аннары ни булды? Сөйлә инде?

ШҮРӘЛЕ. Былтыр дигән адәми зат мәкерле булып чыкты. Мин югыйсә аны куркытып кайтарып кына җибәрмәкче идем. Ә ул минем беркатлы булуымнан файдаланып, мине гомерлек мәсхәрәгә калдырды. *(Елый.)* Кешеләр явыз, һай, бик явызлар!

САРЫК. Дөрес әйтәсең, Шүрәле.

КӘҖӘ. Менә без дә гомеребез буена тугры хезмәт күрсәттек, бер көн көтүдән кайтмыйча калып эзләтмәдек. Сөттән өзмәдем, өстебездәге җылы тунныбыз белән бүлештек, газиз балакайларыбызны корбанга дип егып чалганда да кайгыбызны эчкә йоттык, сиздермәдек. Инде менә гомеребезнең көзендә хуҗабызга акыл кергән, безнең белән изаланасы килми, куып чыгарды... *(Бик төшенке күңел белән Шүрәле янына төпчеккә килеп утыра, сарык алар янына елыша.)*

САРЫК. Авылда башка ишләребез күзенә күренергә оялып урманга килдек менә.

ШҮРӘЛЕ. Урман киң күңелле. Тырыш булсаң, монда да рәхәтләнеп яшәп була. Ләкин аны да төрле яклап кысрыклап киләләр. Монда төп куркыныч — кешеләр, алардан саклана аласың икән, яшәргә була.

КӘҖӘ. Сыендыр безне яныңа, Шүрәле агай? Син безгә, без сиңа иптәш дигәндәй?

*Шул чак аланга бик кызу гына СУ АНАСЫ килеп керә. Як-ягына карана, эзләнә.*

СУ АНАСЫ. Урыны шул. Килеп җиттем. Ләкин Меңяшәгән имән кайда? *(ШҮРӘЛЕНЕ күреп ала.)* Шүрәлетдин, синме соң бу? Болар кемнәр инде тагын?

ШҮРӘЛЕ. Сусылу! Синме соң бу? *(Бик куанышып күрешәләр.)* Сусылу сеңелкәшем!

СУ АНАСЫ. Күпме яз үткән! Имән! Ә имән кайда соң?

ШҮРӘЛЕ. Имән юк инде. Әнә тегендә яшь кенә оныгын үстереп ятам да... Булмас ләкин, бераз үсеп, буын ныгыта гына башлыйлар, кешеләр килеп кул суза...

СУ АНАСЫ. Кешеләр...

ШҮРӘЛЕ. Ә үзең соң нинди җилләр белән?

С У А Н А С Ы. Ярдәмең кирәк миңа, Шүрәлетдин! *(КӘҖӘ белән САРЫККА ымлап.)* Болар соң ниме, ышанычлымы?

Ш Ү Р Ә Л Е. Ышанычлы. Алар да мәкерле адәми зат корбаннары. Нәрсә булды, Сусылу, төсләреӊ дә качкан.

С У А Н А С Ы. Алтын тарагымны урлаттым мин, Шүрәлетдин. Әллә ничек бер мизгелдә кулларымнан куйдым да урлаттым менә. Күптән инде ул бәндә, бәләкәй малай чагында ук бер кат урлаган иде. Ул чагында әнисе тарагымны кире кайтарып биргән иде. Ярар, малай инде кызыккандыр, белешмичә урлагандыр. Ә бу бит инде бабай. Еллар буена сине сагаладым, ди, алтын тарагыңны төшләремдә күреп саташтым, ди. Кичә менә мин тараксыз калдым…

Ш Ү Р Ә Л Е. Алай икән… Илгә-көнгә бик зур бәла килгән икән… Нидирәк бәндә соң ул, төсе буе, кыяфәте дигәндәй.

С У А Н А С Ы. Буйга үзе шулай безнең чама. Түгәрәк кенә битле, башында кәләпүше, карт булса да, җитез атлап йөри үзе. Хәйләкәр һәм бик мут — “өйләнермен сиңа” дигән була, тарак акчасына йорт җиткереп керербез, ди. Уң кулым булган гөберле баканы артыннан җибәргән идем, шикләнүләрем дөрес булган, кырый урамнан өченче йорт дип кайтты. Теге карак малай карак бабай булып җитешкән икән…

С А Р Ы К. Кырый урамнан өченче йорт диме? Безнең йорт ич! Безнең бабай да балыкка җыенып калган иде бит?

К Ә Җ Ә. Әйтәм аны без белгәннән бирле, гомер-гомергә мөгез очы тиклем килкә дә тотып кайталмаса да, балыкка йөрде!

Ш Ү Р Ә Л Е. Алтын таракны сатарга ярамый! Ул бит тылсымлы! Сусылу аның белән чәчләрен тараган саен, җиргә шифалы яңгыр ява. Ә яңгыр барыбызга да кирәк.

К Ә Җ Ә. Бу безнең бабай эше!

С А Р Ы К. Ну гайрәтле дә карт инде. Беркемнән курыкмый, яшьрәк чакта төнлә урманга берүзе утынга йөргән!

Ш Ү Р Ә Л Е. Ни дисең? Тукта әле, буе безнең чама, түгәрәк йөз… Ә уң кашы янында борчак кадәр миңе дә юкмы?

К Ә Җ Ә. Бар. Иягендә сөйкем чокыры да бар.

С У А Н А С Ы. Әйе, әйе! Бар шул! Шүрәлетдин, син аны кайдан беләсең?

Ш Ү Р Ә Л Е *(кыска бармакларын сыйпап ала)*. Беләм шул. Кырый урамнан өченче йорт… Ничә кат үч кайтармакчы булып бардым мин анда… Белмим, Сусылу, ярдәм итә алырмынмы микән мин сиңа?

*Шул чак «Бабакай!» дип кычкырган тавыш ишетелә. Йөгереп кечкенә шүрәле малае керә.*

Ш Ү Р К Ә. Бабай! Бабакай! Урман эченә кеше керде. Кеше!

ШҮРӘЛЕ. Кеше дисеңме? Тимер ат беләнме?

ШҮРКӘ. Юк, безнең кебек тәпи-тәпи! Ул бу сукмак белән килә, бабай.

ШҮРӘЛЕ. Җәмәгать, качып торыйкмы әллә юкса?

СУ АНАСЫ. Бәладән баш-аяк, качыйк. Әллә минем урманга киткәнемне күреп калдымы икән?

*Барысы да тегендә-монда йөгерешә. Саескан кыркылдаган тавыш ишетелә. ШҮРӘЛЕ Шүркәне күтәреп ала, кайсы кая яшеренә. Тынлык. ӘБИ керә.*

ӘБИ. Яңа тапталган үлән булганга, минем бәбекәчәйләрем адашып йөрми микән дип, кая кадәр кердем бит. *(Барып төпкә утыра.)* Көн дә кичкә авышты, арыдым да. Кайларда гына харап булдылар микән минем малкайларым? Бүре дигән була да бабай, күңелем бер дә ышанмый шул. Бөтен күңел юангычым шулар иде-е-е.

*КӘҖӘ белән САРЫК яшеренгән җирләреннән чыгып, әби янына киләләр.)*

КӘҖӘ. Әби!

САРЫК. Әбекәем!

ӘБИ. Әстәгыфирулла, күземә күренәме әллә? Кәҗәкәем, сөт чишмәм! Сарыккаем, йомшаккаем! *(Кочаклап ала.)* И бер Аллам, рәхмәт ялваруларымны ишеткәнең өчен! Әйтәм бит, күңелемнең әллә кай җире урманга тартты. Бүре очрамадымы? Ачыктыгызмы, сусадыгызмы?

КӘҖӘ. Ачыксак печән кырыктык,

САРЫК. Сусасак су эчтек, әби.

ӘБИ. Соң нигә болай гомер булмаганны урманга киттегез соң? Сезне эзләп аякларым талды, тамакларым карлыкты.

КӘҖӘ. Әй, авылда калсак, барысы да бармак төртеп көлерләр дип уйладык.

ӘБИ. Нигә көлсеннәр ди сездән?

САРЫК. Син, әби, чынлап берни дә белмисеңме?

КӘҖӘ. Бабай сиңа берни дә әйтмәдеме?

ӘБИ. Юк, әйтмәде.

САРЫК. Ул бит безне куып чыгарды. *(Елап җибәрә.)* Бушка ашатып яткырмыйм, үз көнегезне үзегез күрегез диде-е-е-е.

КӘҖӘ. Сезгә курмы алган акчага сөт сатып алсам, ваннасын тутырып ятalam, диде.

ӘБИ. Ах, карт дурак, карт дурак! Аякларымны талдырып, әлсерәп йөргәндә дә әйтмәде бит. Әйтәм аны, алтын тарак белән юмаламакчы...

*Яшеренгән җирләреннән ШҮРӘЛЕ, СУ АНАСЫ чыга.*

ӘБИ. Әстәгыфирулла, болары кем тагын?

КӘҖӘ. Болар безнең дуслар, әбекәй!

САРЫК. Шүрәлетдин агай белән Сусылу.

ӘБИ. Бер дә күргән белгәннәрем түгел бит, күрше районнармы соң? *(Кыюсыз гына күрешә.)* Исәннәргенәме соң?

ШҮРӘЛЕ. Саумы, әби! Син курыкма, без һич тә карак, угры түгел.

СУ АНАСЫ. Үзебезгә зыян салмасалар, барлыгыбызны да белдермичә яшибез.

ӘБИ. Вәт тибе на! Әллә соң каты арылып, ял итәргә ятып йокланылып, төш күрәмме? *(Үзен чеметкәли.)* Ә, юк, авырта, өн бугай.

СУ АНАСЫ. Картың сине юмалаган алтын тарак минеке бит, әби!

ШҮРӘЛЕ. Шуның өстенә әле ул тылсымлы да! Сусылу аның белән шушы чәчләрен тарап, җыеп куйган саен җир өстенә шифалы яңгыр ява.

СУ АНАСЫ. Яңгырның вакытында явуы өчен аның һәрвакыт минем кулымда булуы кирәк!

ӘБИ. Соң, алайса ник син аны минем картыма бирдең?

КӘҖӘ. Әби, Бабай таракны аңардан урлаган!

ӘБИ. Урлаган? *(Хәле китә.)* Хур итте, рисвайлар гына итте. Үләм! Сезне куып чыгарган, тарак урлаган… Нәрсә, картлык көнендә котырганмы әллә ул?

СУ АНАСЫ. Бөкрене кабер генә төзәтә. Малай чакта бер урлаган иде инде ул таракны. Ул чагында әнисе хәлне аңлап төзәтте. Ә хәзер бөтенләй азган, мине бичәлеккә чакыра.

ӘБИ. Бичәлеккә? Ах, карт шайтан! Нәрсә яшьрәкләр кирәккәнме аңа?

ШҮРӘЛЕ. Белмим, кайсыгыз яшьрәктер әле!

СУ АНАСЫ. Анысы мөһим түгел, таракны кайтарасы иде.

ӘБИ. Бу карт шайтанны акылга утыртырга кирәк! Хәйлә кирәк!

БЕРГӘ: Хәйлә кирәк?

## Бишенче күренеш

*Беренче күренештәге ишегалды. ӘБИ җырлый-җырлый самовар кертә. Өстәл әзерли. Кәефе шәп. БАБАЙ керә.*

ӘБИ. Тордыңмы, карт? Малларыбыз булмагач, йокыны симертәсең син!

БАБАЙ *(Кәефсез)*. Симертерсең, бар. Төне буе йоклый алмадым. Кояш чыкканда гына йоклап киттем бугай. Кая, су сал әле.

ӘБИ. Кая әле, салыйм.

*Бабайның кулларына комган белән су салып тора. БАБАЙ ярты бөгелеп юына. Аңа каеш артына яшерелгән тарак комачаулый.*

ӘБИ. Китер монда, үзем тотып торам. Иркенләп юын. *(Бабай икеләнә.)* Шикләнмә, бир, нәрсә гомер иткән карчыгыңа ышанмыйсың әллә?

БАБАЙ. Ышанмыйм дип, ышанам да. Алтын бит ул. *(Таракны бирә.)*

ӘБИ *(таракны түшенә тыгып)*. Вәт, менә шунда, зерә дә ышанычлы урында торсын дим. Карале. Җаннарны җылытып җибәрде.

БАБАЙ. Шулай булмыйча. *(Юына.)*

*Юынып бетергәч? Сөлге белән сөртенә-сөртенә эскәмиягә утыра. ӘБИ дә аның янына килеп утыра.*

БАБАЙ. Йә, бир, яхшы нәрсә күп булмый ул.

ӘБИ. Бераз гына торсын инде.

БАБАЙ. Кичә ничек йөреп кайттың? Серле елмаеп йөрдең, әллә урман пәриләрен күрдеңме?

ӘБИ. И, ул урмандагы печәнне күрсәң! Икене селтәнсәң, бәбекәчләребезгә кыш чыгарлык була.

БАБАЙ. Булмаган малга ниемә печән? Үзең ашарга җыенасыңмы әллә?

ӘБИ. Шулай шул, югалганнарын онытып җибәрәм шул.

БАБАЙ. Син нәрсә, миңа чәй эчермисеңме әллә? Карап-карап торам да, хәтерең иләкләнгән, картайдың, карчык!

ӘБИ. Кунак көтә идем, бергә утырырбыз дип кенә. Ярар, син утыра тор, ә мин свежи кыяр белән помидор өзеп килим әле.

БАБАЙ. Әллә сөт юкмы? Әй, юк бит әле. Ну ничава, бу алтынны гына эшкә кушыйм, бар да булыр. Түлке шикләндерә, ике төн буена да Су анасы килмәде. Минем тәкъдимне уйлыйдыр. *(Чәй эчә, шөпереп куя. Тирләрен сөртә.)*

*ШҮРӘЛЕ керә. Ул матур костюм-чалбардан. Мөгезен күрсәтмәслек эшләпә кигән. Бик интеллигент кыяфәттә. Кулына бик матур букет тоткан.*

ШҮРӘЛЕ. Керергә ярыймы икән? Кырый урамнан өченче йорт...

БАБАЙ. Ярыймы дип тормадың, кердең бит инде! Дөрес кердеңме, анысын белмим. Мондый кияү егетенә бирерлек кызым юк минем.

*Әби керә. Табак белән яшелчәләрен өстәлгә куя.*

ӘБИ. Шүрәлетдин! Килдеңме?

ШҮРӘЛЕ. Бу чәчәкләр сиңа...

БАБАЙ. Сиңа диме? Син нәрсә минем карчыгыма печән ташыйсың? *(Кизәнеп килә.)*

ӘБИ. Карт, тынычлан. Беренчедән, бу печән түгел, урман чәчәкләре. Син миңа кайчан чәчәк бүләк иткәнең бар? Бусы икенчедән. Өченчедән, Шүрәлетдин

миңа кичә бәбекәчләремне — Кәҗә белән Сарыкны табып бирде, үземне кара урманнан озатып куйды. Кайда соң үзләре?

ШҮРӘЛЕ. Әнә тегендә, бабайдан керергә шикләнеп торалар. Бабай киткәч, керәбез диләр. *(Кырыйга гына Кәҗә белән Сарык кереп баса, әйе дигәндәй баш селкиләр.)*

БАБАЙ. Бабай киткәч? Кая китим мин?

ӘБИ. Бусы инде дүртенчедән. Менә без, Шүрәлетдин белән икәү, сөйләштек тә калган гомерләребезне бер түбә астында яшәргә булдык. Шүрәлетдин яшь, печән чабарга иренми. Алтын тарак акчасына ике ятажлы йорт салырбыз.

БАБАЙ. Тарак! Ул бит минеке!

*Шулвакыт Су анасы килеп керә, бабайны кочаклап ала.*

СУ АНАСЫ. Исәнме, карт. Мин килдем. Тарак та синеке, мин дә синеке. Уйладым-уйладым да, синең сүзләреңдә хаклык бар. Бигрәк тә бассейн дигәне кызыктырды. Сентябрь буена Кара диңгезгә йөз, май буена кире кайт...

БАБАЙ. Кит әле моннан. Син генә җитмәгән ди монда!

ӘБИ. Ә бабай, бабай. Гомер буе үзеңә тугрылыклы хезмәт белән яшәдем. Ә син алдакчы икән? Таракны тапмагансың бит, урлагансың! *(Су анасына таракны бирә.)*

СУ АНАСЫ. Рәхмәт, әби! Йомышың булса кил, дус яшик!

ӘБИ. Кәҗә белән Сарыкны да куып чыгаргансың! *(Тегеләр әби янына киләләр, сырпаланалар.)*

ШҮРӘЛЕ. Ә мине таныйсыңмы, Былтыр? *(Бармакларын күрсәтә.)* Мин бит югыйсә үз йортымны гына сакламакчы идем. Син анда килеп хуҗа булып, Меңьяшәр имәнебезне кискәнсең.

ӘБИ. Менә хәзер син үзең монда хуҗа бул, Шүрәлетдин! *(Аркасыннан кагып ала.)* Гөрләтеп яшәрбез бергә!

БАБАЙ. Сез нәрсә? Ә мин? Мин кая барыйм? Нишлим?

ӘБИ. Сиңа ике юл: берсе мәкерле яшәвеңне дәвам итеп моннан чыгып китү, икенчесе тәүбә кылып, һәр көнеңә канәгать булып, берәүгә дә зыян китермичә, алдамыйча, урламыйча шунда яшәү.

БАБАЙ. Сезнең беләнме?

ШҮРӘЛЕ. Юк инде, мин китәм. Минем үз йортым, үз гаиләм. Үз йортыңны югалту ачысының, мәсхәрәгә калу хурлыгының авырлыгын бер сиңа да татытасы иде дигән хыял белән яшәдем. Шөкер, хыялым тормышка ашты. Рәхмәт, әби! Дус яшик. Урмандагы иң шәп чикләвек, җиләк аланнарын өйрәтермен сиңа! Кунакка килегез.

ӘБИ. Үзеңә рәхмәт! Инде, бабай, ни диярсең?

БАБАЙ. Кичерегез, мин тырышырмын, үзгәрергә тырышырмын...

*Барысы да алга килә.*

КӘҖӘ. Табигать — туган йортыбыз,
САРЫК. Аның белән көрәшмик.
СУ АНАСЫ. Һәр туган көнгә кинәник,
ШҮРӘЛЕ. Рәхәтләнеп дус яшик!
БАБАЙ. Җиңел байлык җиңел китәр,
ӘБИ. Ә акыллы булганына шөкер итәр.

*Шакирҗанова Айзилә Айдар кызы*

# КЫШ БАБАЙГА ХАТ

*Катнашалар:*

КАМИЛ, өлкән сыйныф укучысы.

ЗӨБӘРҖӘТ, Камилнең әнисе.

КАМИЛӘ, Камилнең сеңлесе, 6 яшьтә;

САНИЯ МАНСУРОВНА, сыйныф җитәкчесе, татар теле укытучысы;

АЙГӨЛ, Камилнең якын дус кызы;

АЗАТ, БУЛАТ, ЭДУАРД, ЭЛЬВИРА, МӘРЬЯМ, КАРИНА, КАМИЛНЕҢ сыйныфташлары;

МАРСЕЛЬ, КАРИНАНЫҢ әтисе.

*Вакыйга бүгенге көндә район мәктәпләренең берсендә бара.*

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Мәктәптә киенү бүлмәсе. Укучылар, Яңа ел бәйрәме тамашасыннан чыгып, кызу-кызу киенәләр.*

АЙГӨЛ. Матур да булды соң бәйрәм! Миңа ошады, кызлар, сезгә?

ЭЛЬВИРА. Әйе, миңа да бик ошады.

МӘРЬЯМ. Безнең бию иң матуры булды бит.

КАРИНА. Барлык укучылар да шулай диде.

АЙГӨЛ. Әйе, алкышлардан да күренә инде!

МӘРЬЯМ. Нәрсә дисәң дә, татар биюе бик матур шул! Музыкасы ук нинди дәртле бит аның! Э-э-эх!.. *(Үзе көйли, үзе тыпырдый башлый).*

ЭЛЬВИРА. Әйе-е-е, мондый биюне кайда күрсәтсәң дә оят түгел! Кичке уеннарда да шулай биегәннәрдер инде, име, безнең әбиләр? *(Ул да Мәрьямгә кушылып тыпырдый.)*

АЙГӨЛ. Ә сез башта татар биюен биик дигәч, борын җыерган булдыгыз! Менә бит, үзегезгә дә ошады хәзер!

ЭЛЬВИРА. Әйе-е-е! Мин никтер татар биюе дигәч, искелек калдыгы шикеллерәк кабул иткән идем шул, ялгышканмын. Малайлар да молодцы! Шак-каттырдылар.

МӘРЬЯМ. Малайлар димә инде, Эльвира! Егетләр, диген!

ЭЛЬВИРА. Әйе, егетләр инде, егетләр. Мин бигрәк тә Камилгә аптырадым. Айгөл, ничек шулай итеп өйрәтә алдың син аны?

МӘРЬЯМ. Әйе, мин дә. Ул бит без калып өйрәнгәндә дә, дәресләрдән соң калмады.

АЙГӨЛ. Мин генә өйрәтмәдем инде аны. Үзе мине өйрәтте дисәң дә була әле.

ЭЛЬВИРА. Ниче-ек?

АЙГӨЛ. Ул бит Казанда яшәгәндә, сәнгать мәктәбендә укыган. Хореография классын тәмамлаган.

ЭЛЬВИРА. Чынмы? Карап торышка бер дә алай дип уйламассың!

КАРИНА. Әллә ниләр чыга бу йомыкый малайдан!

АЙГӨЛ. Нигә алай дисең, Карина, бер дә начар малай түгел бит ул.

КАРИНА. Шулайдыр инде. Тик нигәдер ул бер сиңа да, Сания Мансуровнага гына ошый. Калган бер кыз да яратмый аны. Малайлар да бик үз итеп бетермиләр.

АЙГӨЛ. Ярату-яратмау турында сөйләшергә иртәрәк әле безгә. Ул — минем чын дустым.

КАРИНА. Харап икән! Үзеңә бүтән малайлар карамагач, ярап тора инде диген.

*АЙГӨЛНЕҢ кинәт кенә йөзе үзгәрә. Ул аны башкаларга сиздерми, тиз генә киенеп, күз яшьләренә буылып чыгып чаба.*

МӘРЬЯМ. Нәрсә инде син, Карина, теләсә нәрсә сөйлисең! Бер дә юкка Айгөлне үпкәләттең. Эх, син! *(Мәрьям дә киенеп чыгып китә.)*

*Уңайсыз тынлык. Тынлыкны КАРИНА өзә.*

КАРИНА. Ярар, үпкәләсә, тынычланыр әле. На обиженных воду возят! Шул Камилне әйтә башласаң, тәмам җаны котыра башлый шуның! Теге вакытта да...

МӘРЬЯМ. Җитте, Карина. Үзе булмаганда кеше турында начар сүз сөйләсәң, гайбәт була ул, ди әтием. Сөйләмә. Әйдәгез, кызлар, кайтыйк.

*Бүлмәгә укытучы керә.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Кызлар, киенеп беттегезме инде?

КЫЗЛАР. Бетәбез, бетәбез, Сания Мансуровна!

САНИЯ МАНСУРОВНА. Бергәләшеп кайтыгыз, яме. Юлларда сак булыгыз! Яхшы итеп яллар итегез!

КЫЗЛАР. Рәхмәт, Сания Мансуровна! Үзегез дә!

САНИЯ МАНСУРОВНА. Яхшы, хушыгыз. *(Китә башлый, кире туктап)* Кызлар! Әйтергә онытып торам: безнең биюне “Йолдызлык” конкурсына сайладылар. Мәктәп данын безнең сыйныф яклаячак. Тик әле шомартасы җирләр бик күп, яхшылап әзерләнәсе була, ямегез!

КЫЗЛАР Ур-ра! *(Куанышып кочаклашалар.)*

ЭЛЬВИРА. Ярар, ярар, Сания Мансуровна! Әзерләнәбез болай булгач!

## Икенче күренеш

*Сыйныф бүлмәсе. Каникулдан соң укырга киләләр.*

БУЛАТ. Сәлам, егетләр! *(Кул бирешеп күрешәләр.)*

КАРИНА. Кызлар, привет!

ЭЛЬВИРА. О-о, сәлам, Карина!

БУЛАТ. Каникулда берәр кеше берәр җиргә бардымы?

АЗАТ. Без беркая да бармадык. Рәхәтләнеп өйдә ял иттек.

ЭДУАРД. Мин бер атнасын авылда уздырдым. Анда да дусларым күп, шундый рәхәт булды. Әбиемә үзебезнең бию турында сөйләдем, биеп тә күрсәттем. Әбием бик шатланды, безнең яшь чаклардагы хәрәкәтләр дә бар икән диде.

МӘРЬЯМ. Ә безнең үзебезгә кунаклар кайтты. Яңа елны каршылаганнан соң минем белән почти бер елдагы туганнан туган бездә калды, каникул буе торды. Безгә дә бик күңелле булды.

ЭЛЬВИРА. Без Яңа елны каршыларга Мәскәүдәге туганнарга бардык. Кызлар, андагы матурлыкны күрсәгез!

КАРИНА. Подумаешь! Ә без Грециягә бардык! Яңа елны да шунда каршыладык. Андагы рәхәтлек сезнең төшегезгә дә керми! Вот! *(Сумкасыннан затлы телефон чыгара.)*

ЭДУАРД. О-о, Карина, яңа телефон алдыгыз мәллә?

КАРИНА. Конечно! Тегесе белән бер елга якын йөрдем бит инде.

ЭДУАРД. Айфон! Да-а, бәясе дә бар моның!

КАРИНА. Һәрхәлдә син мондыйны ала алмыйсың инде!

ЭДУАРД. Ә миңа кирәк тә түгел! *(Китеп бара.)*

КАРИНА. Яхшы укысагыз, сезгә дә алырлар. Мин менә әтигә обещала, что мин отличница булам дип, и выполнила, шуңа әтием подарил!

МӘРЬЯМ. Карина! Син я татарча, я русча гына сөйләш әле. Сания Мансуровна да шулай ди бит телне бозмагыз, ди.

КАРИНА. Подумаешь! Ярар, постараюсь!

БУЛАТ. Постараюсь түгел, тырышырмын, дияргә кирәк, Солтанова!

Бел син, дустым, рус телен,

Тик онытма үз телең!

КАРИНА. Яхшы, яхшы, тырышам! Онытылып китә ул, тиз генә кирәк сүзне... ничек әле... эзләп булмый, то есть, табып булмый. Ну, әйтегез инде бүләкләрегезне!

АЙГӨЛ. Миңа әти-әниләр Яңа елга тимераяк бүләк иттеләр.

ЭДУАРД. Ә миңа чаңгы! *(Көлешәләр.)*

МӘРЬЯМ. Әйе, әти-әниләр чынлап та кирәкле булган, болай да алырга кирәк булган әйберләрне Кыш бабай бүләге дип чыршы астына куялар хәзер.

ЭЛЬВИРА. Сездә дә шулаймыни ул? Мин тагын шуның өчен әти-әниләргә үпкәләп тә куйган идем.

АЙГӨЛ. Нәрсә инде син, без бит инде кечкенә балалар түгел, шуңа күрә хәзер теләсә нинди сораган әйберне түгел, кирәк әйберне алып килә Кыш бабай. *(Көлешәләр.)*

АЗАТ. Шулай шул! Миңа шахмат алып килде быел Кыш бабай.

БУЛАТ. Миңа унышар килограммлы гер! Ничек күтәрә алган диген! *(Көлә)*.

МӘРЬЯМ. Берегезгә дә минеке кебек түгел икән! Миңа *(горур кыяфәттә)* — «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»! Ә нәрсә, бик кирәк әйбер бит! *(Көләләр.)*

ЭДУАРД. Хат язасы булган безгә, кечкенә вакыттагы кебек итеп!

ЭЛЬВИРА. Аһа, артына үзебезнең кул рәмесен төшереп! *(Кулын куеп күрсәтә.)*

МӘРЬЯМ. Әйтмә дә! Икенче елга язмый булмас!

КАРИНА. Камил, син нигә бер дә эндәшмисең? Сиңа Кыш бабай нәрсә алып килде? *(КАМИЛНЕҢ партасы янына килеп.)* Бәлки хат та язгансыңдыр әле! *(КАМИЛ бер сүз дә әйтми, кулындагы китабын укуын дәвам итә.)* Йә, әйт инде, ташла әле шул китабыңны. Укып туймадың инде! *(Китабын тартып ала, китап эченнән икегә бөкләнгән кәгазь бите төшә.)* Оп-па! *(КАРИНА тиз генә кәгазьне тартып ала.)*

КАМИЛ *(тыныч кына)*. Китер монда, шаярма.

КАРИНА. Юк инде! Нинди сәлам хаты икән бу? *(Тиз генә йөгереп китә, кәгазьне кычкырып укый башлый.)* Кыш бабай! Бу хатны сиңа Ками...

КАМИЛ *(артыннан йөгереп барып, хатны алмакчы була)*. Китер дим!

КАРИНА *(тиз генә урындык өстенә менмәкче була, Камил хатны тартып ала)*. Грубиян! Сабый! Бәбәй! Кыш бабайга хат язган! Һа-һа-һа! *(Көлә, иптәшләренә карый, алар көлмәгәнне күргәч, туктый да урынына барып утыра.)*

*Тынлык урнаша. САНИЯ МАНСУРОВНА килеп керә.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Исәнмесез, укучылар. Килдегезме? Яңа еллар белән сезне!

УКУЧЫЛАР. Сезне дә котлыйбыз, Сания Мансуровна!

САНИЯ МАНСУРОВНА. Яңа чирекне дә исән-имин, уңышлар белән тәмамларга язсын!

УКУЧЫЛАР. Рәхмәт, Сания Мансуровна! Сез дә авырмагыз, сезгә дә уңышлар!

САНИЯ МАНСУРОВНА. Балалар, «Йолдызлык» конкурсында бию белән катнашуыбызны белгәнсездер инде, әйеме?

УКУЧЫЛАР. Белдек, белдек, Сания Мансуровна!

САНИЯ МАНСУРОВНА. Яхшылап өйрәнергә кирәк! Чын мәгънәсендә мәктәп данын күрсәтүче бию булсын, яме!

ЭЛЬВИРА. Яхшы, Сания Мансуровна! Бүген без алты дәрестән соң калабыз.

САНИЯ МАНСУРОВНА. Барыгыз да кала аладыр бит?

УКУЧЫЛАР. Әйе, әйе.

*Укытучы чыгып китә, аның артыннан КАМИЛ чыга.*

КАРИНА. Хәзер карап торыгыз! Камил керәчәк тә, мин кала алмыйм, гафу итегез, үзем өйрәнеп бетәрмен, Айгөл өйрәтер дип әйтәчәк.

*КАМИЛ килеп керә.*

КАМИЛ. Иптәшләр, мин дәрестән соң калмыйм инде, ямегез. Үзем ничек тә өйрәнермен, калганын Айгөл өйрәтеп бетерер. Айгөл, син ризамы?

КАРИНА *(мыскыл итеп)*. Айгөл, син ризамы, имеш! ЗАГСта басып торамыни? Әйттем бит нәкъ шулай булачак дип!

АЗАТ. Ник каныктың син Камилгә, ә?

МӘРЬЯМ. Әтәч кебек очасың да кунасың. Ник шулай итәсең соң син, Карина?

ЭДУАРД. Юк, Карина дөрес әйтә. Тегесен өйрәнгәндә дә бер тапкыр да калмады. Әйтерсең, бик ашыгыч эше бар!

АЙГӨЛ. Борчылма, Камил, мин парда синең белән. Үзем өйрәнгәндә, синең рольне дә хәтердә калдырырмын. Бию барып чыккандыр ич бәйрәмдә, Эдуард?

ЭДУАРД. Чыкты инде...

АЙГӨЛ *(сүзен бүлеп)*. Шулай булгач, монда бернинди проблема да юк.

*Кыңгырау шалтырый.*

БУЛАТ. Киттек, безгә физика бит.

### Өченче күренеш

*Шул ук сыйныф бүлмәсе. Берәм-берәм укучылар керә.*

КАРИНА. Сәлам!

МӘРЬЯМ. Исәнмесез!

БУЛАТ. Исәнмесез!

ЭДУАРД. Привет барыгызга да!

КАРИНА. Кая, безнең тили-тили тесто, жених и невеста күренмиләрмени әле? *(Каринага берәү дә җавап бирми, ишетмәмешкә салышалар.)* Кая, ник теге агылый белән тагылый юкмыни әле?

БУЛАТ. Кемнәрне әйтәсең син, Карина?

КАРИНА. Белмәгәндәй кыланма инде, Айгөл белән Камилне әйтүем.

МӘРЬЯМ. Ник, кай яклары белән ошамыйлар алар сиңа, ә? Азат, ичмасам, син якла инде бераз туганыңны. Айгөл синең игезәк сыңарың бит!

БУЛАТ. Карина! Ник, дус булалар икән, моның кемгә нинди зыяны бар?

КАРИНА. Камилнең зек улы икәнен белсәң, бер дә Айгөлне аның белән дус итеп йөртмәс идең әле!

АЗАТ. Кем?

МӘРЬЯМ. Син ни сөйлисең, Карина?

КАРИНА. Белмәсәгез, белегез! Кеше үтергән өчен төрмәдә утыра аның әтисе! Музыкалкада бергә укыган подружкалар янында торалар алар. Шул подружкам әйтте.

*Барысы да аптырап калалар. Авыр тынлык.*

КАРИНА. Әле алай гына да түгел!

АЗАТ *(сүзен бүлдереп)*. Җитте, сөйләмә!

КАРИНА. Юк, белсеннәр! Әйтсәм әйтим, әнисе дә эчкече икән! Беркөн мәктәптән соң шул подружкама бара идем, бер хатын күрше домнан чүп чиләге тотып чыгып бара, аякларында чак басып тора үзе. Камил мәктәптән кайта иде, каршысына йөгереп барды да, башта чиләктәге чүпне илтеп ташлады, аннан әнисен култыклап алып, өйгә алып кереп китте.

ЭЛЬВИРА. Чынлапмы? Кит инде!

ЭДУАРД. Камил шул эчкече әнисен саклар өчен ашыгадыр инде өйгә, әйеме?

КАРИНА. Шулай булмыйча! Ул бит... *(сүзе бүленеп кала, класска АЙГӨЛ белән КАМИЛ керәләр)*.

КАМИЛ. Сәлам, дуслар!

БУЛАТ. Сәлам! *(Малайлар кул биреп күрешәләр)*.

ЭДУАРД. Привет, Айгөл!

ЭЛЬВИРА. Соңга калдыгыз бүген... *(Нидер әйтмәкче була.)*

АЙГӨЛ. Әйе, бүген Камилнең эшләре күп булды шул иртән.

*Кызлар ялт кына бер-берсенә карап алалар. Кыңгырау чылтырый. Укучылар урыннарына утырыша. Сыйныф җитәкчесе САНИЯ МАНСУРОВНА керә.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Укучылар! Сезнең хәзер биология дәресе булмый, Рузия Сәфәргалиевна авырып киткән. Без әдәбият дәресе уздырырбыз. Мин хәзер китапханәдән өстәмә уку китапларын гына барлыйм әле. Дежурлар, сез минем белән барырсыз, ә калганнар, тавышланмый гына утырып торыгыз. *(Чыгып китәләр).*

*Кемнеңдер кесә телефоны чылтырый. КАМИЛ уңайсызланып китә, каударланып, кесәсеннән телефонын тартып чыгара.*

КАМИЛ. Әйе, әни... *(Сүзен дә әйтеп бетерә алмый, күрше партада утыручы КАРИНА сикереп тора да, ачудан КАМИЛНЕҢ телефонын бәреп төшерә. Телефон челпәрәмә килеп ватыла. КАМИЛ башта нишләргә белми катып кала, аннан, инәлеп, "Әни-и-и" дип, телефонының ватык кисәкләрен җыеп, күз яшенә буылып, чыгып йөгерә.)*

*Аның артыннан КАМИЛНЕҢ сумкасын тиз генә җыеп, АЙГӨЛ дә чыгып чаба.*

МӘРЬЯМ. Нишлисең син, Карина, акылыңа кил!

КАРИНА. Ә нишләп әле, безгә мәктәптә дәрес вакытында телефоннан файдаланырга ярамый да, Камилгә ярыймы?

*Башта китап күтәргән дежурлар, алар артыннан САНИЯ МАНСУРОВНА килеп керәләр.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Балалар, Айгөл белән Камилгә нәрсә булды?

*Берәү дә дәшми.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Азат, Айгөлгә нәрсә булды?

*АЗАТ дәшми, нәфрәтләнеп КАРИНАГА карый.*

САНИЯ МАНСУРОВНА. Тыңлыйм, Карина.

КАРИНА. Сания Мансуровна! Туйдырды инде ул Камил! Дәрестән соң берәр нәрсәгә калсак, ул калмый, экскурсиягә, походка бара башласак, ул бармый. Телефоннан да мәктәптә кулланырга кушмыйсыз безгә, ә Камилгә сүз әйтмисез! Телефонын бәреп төшердем мин аның... ялгыш...

САНИЯ МАНСУРОВНА *(Нидер әйтмәкче була, туктала. Аның бик тә дулкынланганы сизелеп тора.)* Бик ялгышкансың син, Карина, бик ялгышкансың! Һәр ялтыраган әйбер алтын булмаган кебек, һәр ямьсез күренгән әйбер начар дигән сүз түгел әле...

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*КАМИЛЛӘР өе. АЙГӨЛ КАМИЛНЕҢ сеңлесе КАМИЛӘ белән рәсем ясый. КАМИЛ креслода утырган әнисенең аякларына күнегүләр ясата. Ишектә звонок. КАМИЛ белән АЙГӨЛ бер-берсенә карап алалар. КАМИЛ ишекне барып ача. Өйгә АЗАТ, ЭДУАРД, МӘРЬЯМ, БУЛАТ, КАРИНА керәләр. КАМИЛ белән АЙГӨЛ аптырап карап тора.*

КАРИНА. Камил, гафу ит, мә, мин сиңа телефон алып килдем *(тартма суза)*.

КАМИЛ. Кирәкми, Карина, мин Айгөлнең иске телефонын алып тордым.

КАРИНА. Ал инде, Камил, мин бит чын күңелдән. Ал дим. Гафу ит! *(КАМИЛ телефонны ала.)*

*Стенага тотынып кына КАМИЛНЕҢ әнисе чыга. Балалар аның көчкә генә атлаганын, әмма исерек түгел икәнлеген күреп, кыенсынып калалар.*

ЗӨБӘРҖӘТ. Улым, Камил, иптәшләрең килгәнмени? Әйдә, ник ишек төбендә тотасың аларны? Керегез, балалар, кыенсынмагыз. Өебез тар булса да, күңелебез киң безнең. Керегез, кер! Менә Айгөл дә бездә әле. Кызым Камиләгә дә күңелле Айгөл апасы булгач. Әйдәгез, керегез, утырыгыз.

КАРИНА *(өстәл өстендә бәләкәй генә чыршыга карап)*. Әле чыршыны да сүтмәгәнсез икән, Иске Яңа ел да үтте бит инде.

КАМИЛ. Ә, әйе шул, Камилә сүттерми бит.

КАМИЛӘ *(шул сүзне ишетеп алып)*. Юк, тимисез! Кыш бабай минем курчак сорап язган хатымны алып китте. Әниемнең аякларын дәваларга акча да сорадым мин. Озакламый алып килер. Бүләкне, акчаны кая куяр соң, чыршы булмаса? *(Бүлмәсенә йөгереп кереп китә.)*

КАРИНА *(хат вакыйгасын исенә төшереп уңайсызлана)*. Камилә балалар бакчасына йөрми мәллә?

ЗӨБӘРҖӘТ. Юк шул, йөрәгендә җитди авыру бар аның. Врачлар операциясез бетми диләр. Балалар бакчасында аны саклап бетереп булмый, шуңа куркабыз, уйламаганда гына йөрәк өянәге килә башлый аның. Андый чакта мин тиз генә Камилгә шалтыратам инде. Врач чакырта, беренче ярдәмне дә үзе күрсәтә белә хәзер.

КАРИНА. Ә ник операция ясатмыйсыз?

ЗӨБӘРҖӘТ. Ул бушка түгел шул, акчалы, аның кадәр акчабыз юк безнең.

КАМИЛ. Әни, әйттем бит инде, акча табам мин, сеңлемне терелтергә дип, эшкә керәм мин. Синең дә аякларыңны терелтәбез. Иң яхшы врачларны табам.

ЗӨБӘРҖӘТ. Әй, улым, яхшы сүзләреңә рәхмәт инде *(сиздерми генә күз яшьләрен сөртеп ала)*.

*БУЛАТ стенага элгән грамоталарны карый.*

БУЛАТ. Кара, малай, синең грамоталар нихәтле икән!

ЗӨБӘРҖӘТ. Камил Казанда яшәгәндә, бию белән шөгыльләнде. Әле өметләре зурдан иде. Әтисе белән уйламаган хәлләр килеп чыккач, тормышлар үзгәреп китте шул *(күз яшен сөртеп ала)*.

КАМИЛ. Әни, ярар инде.

МӘРЬЯМ. Апа, ә сезнең аягыгыз нишләде?

КАМИЛ. Юл аркылы чыкканда, машина бәрде аны.

КАРИНА. Машина? Ә кем? Машина номерын күреп калдыгызмы соң?

ЗӨБӘРҖӘТ. Күрдем, балам, беләм мин аны, суд булды бит.

КАМИЛ. Әни аны судта да гаепләмәде, ахырдан, үзем гаепле дип калдырды.

ЗӨБӘРҖӘТ. Соң, улым, әтиеңне уйладым мин, төрмәдә утыруның нинди газап икәнен үзем беләм бит, бер гаепсез килеш, төрмәдә газап чигә бит әтиең.

ЭДУАРД. Ә бу кешенең гаебе булган бит, ник хөкем итмәделәр соң?

ЗӨБӘРҖӘТ. Жәлләдем, балалар, гаиләсе, балалары авыр хәлдә кала дип уйладым.

КАРИНА. Менә хәзер әйтәсе иде аңа, булышсын, ул гаепле бит. Табарга кирәк ул кешене! Әйтегез, әйдә, без дә эзләшәбез.

КАМИЛ. Кирәкми, Карина.

КАРИНА. Табабыз аны, Камил, менә әйтте диярсең.

КАМИЛ. Карина, кабатлап әйтәм, кирәк түгел ул безгә!

КАРИНА. Табарга кирәк, гаебен танысын, булышсын! Ник карышасың соң?

КАМИЛ. Карина!.. *(Икеләнә.)*Ул... ул... ул — синең әтиең, Карина.

КАРИНА *(корт чаккандай сикереп куя)*. Нәрсә-ә-ә? ...Минем әти?.. Каян беләсең? Бу... бу дөрес түгел.

ЗӨБӘРҖӘТ. Әйе, дөрес, балам... Әмма Камилгә мин бу турыда берәүгә дә әйтмәвен үтендем. Сыйныф җитәкчегезгә исә безнең гаиләдәге вакыйгаларны башкаларга әйтмәвен сорадым.

*КАРИНА киемнәрен алып, чигенә-чигенә чыгып йөгерә.*

З Ө Б Ә Р Җ Ә Т. Әй, бала, бала! Әти-әнинең ялгышында баланың бер гаебе дә юк та бит!

*Бар да аптырап уңайсызланып калалар.*

### Бишенче күренеш

*КАМИЛЛӘР өе. АЙГӨЛ белән КАМИЛӘ кәгазьдән кисеп рәсем ябыштыралар. АЗАТ КАМИЛ белән ЕГЭ китабын тотканнар, мисал чишәләр, МӘРЬЯМ КАМИЛНЕҢ әнисе ЗӨБӘРҖӘТ янына утырып, бәйләү энәләре тоткан, бәйләргә өйрәнә.*
*«Исәнмесез!» дигән тавышка барысы да ишеккә борылалар.*
*Ишектә әтисе белән КАРИНА басып тора.*

М А Р С Е Л Ь. Исәнмесез! ...Сезнең... хәлегезне белмәвем өчен кичерегез мине... Бик зур гаепле мин сезнең алда!

З Ө Б Ә Җ Ә Т. Исәнмесез! ...Зыян юк... Исән калуыма шөкер итеп яшәп ятабыз.

М А Р С Е Л Ь. Сез миңа бер тапкыр да шалтыратмагач, мин бит сезнең белән бар да тәртиптә дип уйладым, ә үземнең шалтыратырга ничектер башыма да килмәде, гафу итегез мине, зинһар! Тезләнеп гафу үтенергә дә риза мин сезнең каршыда! *(Тезләнмәкче була.)*

З Ө Б Ә Р Җ Ә Т. Нишлисез! Кирәкми, торыгыз!

К А Р И Н А *(Камилне читкә алып китә, пакеттан курчак алып.)* Камил, менә бу курчакны сеңлең күрмәгәндә, тиз генә чыршы янына куй!

К А М И Л. Карина! Кирәкми инде, син нәрсә?! Үзем алам мин аңа курчакны!

К А Р И Н А. Вакытны сузма, зинһар, Камил, барыбер бирәм бит инде. Болай үзе теләгәнчә килеп чыга. Мин аны күрше бүлмәгә алып чыгып торам. *(КАМИЛӘНЕ чакырып ала.)* Камилә! Миңа үзеңнең рәсемнәреңне күрсәт әле!

*КАМИЛ тиз генә курчакны чыршы янына куя.*

М А Р С Е Л Ь. Зөбәрҗәт ханым! Сезнең кызыгызга да операция кирәк икәнлеген белдем. Мин яхшы врачларны беләм, түләрлек акчам да бар. Иртәгә үк үзем сезнең икегезне дә иң яхшы хастаханәгә алып барам. Иртән әзер булып торыгыз!

З Ө Б Ә Р Җ Ә Т *(гаҗәпләнеп һәп сөенеп)*. Ничек?! Чынлапмы?! Сез дөрес әйтәсезме?!

*Бүлмәдән КАМИЛӘ белән КАРИНА чыгалар.*
*КАМИЛӘ чыккан мәлгә туктап кала, курчакны күреп.*

К А М И Л Ә. Әнием! Абыем! Килгән, килгән бит Кыш бабай! Менә күрерсең, әнием, синең аякларыңны да тазартачак ул Кыш бабай!

*Барысы да, елмаешып, бер-берләренә карыйлар.*

К А Р И Н А. Ә монысы бездән бүләк сиңа, Камил! Тик бер шарт: алмыйм димисең! Бу — Кыш бабайдан бүләк! *(Камилгә тартмасы белән ноутбук бирә.)* Контактта теркәл һәм мине дә үзеңнең иң якын дусларың исемлегенә өстә, яме!

К А М И Л. Бик зур рәхмәт, Карина! Ә мин бит сине моңарчы да үземнең дошманым итеп санамадым!

*К А М И Л алга таба кулын суза, барысы да бер-бер артлы К А М И Л Н Е Ң учы өстенә кулларын салалар, иң ахырдан, йөгереп килеп, К А М И Л Ә дә кулын куйгач, бар да пырхылдап көлеп җибәрәләр.*

*Гыйззәтуллин Илсин Илсур улы*

# ТАПТАЛМАС, ЮГАЛМАС БЕЗНЕҢ ЭЗ

*(Бөек Ватан сугышы әсирләренә багышлана)*

*Катнашалар:*

ГАРӘФ, 22–23 яшьләр тирәсе. Карабаш авылында туып үскән. Киев чолганышыда әсирлеккә төшә. Кыю йөрәкле егет. «Идел-Урал легионы»нда Муса Җәлил, Гайнан Курмашлар белән аралаша.

ӘКРӘМӘ, 14–15 яшьләр тирәсе. Гарәфнең сөйгән кызы.

МУСА ҖӘЛИЛ *(Гумеров)*, татар шагыйре.

ГАЙНАН КОРМАШ, 23 яшьләр тирәсе. «Идел-Урал легионы»нда яшерен оешма җитәкчесе.

КӘРИМ, «Идел-Урал легионы»нда әсир.

АБДУЛЛА АЛИШ, Балалар язучысы. “Идел-Урал легионы”нда җәлилчеләр белән бер лагерьларда була.

ГОМӘР СӘЙФИЕВ, 22–23 яшьләр тирәсе. Карабаш авылында туып үскән. Өлкән лейтенант, политрук, Белоруссия фронтында әсирлеккә төшә. «Идел-Урал легионы»нда җәлилчеләр белән бер лагерьларда була.

ЗӘКИ ӘҺЛИУЛЛИН, 22–23 яшьләр тирәсе. Карабаш авылында туып үскән. Әсирлектән алып кайткан бер куен дәфтәрендәге шигырьләр арасында Абдулла Алишның «Очрашу» поэмасы да була.

САХАП, ашханәдә эшләүче. Карабаш авылында туып үскән. Әсир.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*ГАРӘФ төш күрә. Аның яшь чагы. Зәй буенда кечкә уенга яшьләр җыелган. Түгәрәк уен. Җырлыйлар, кара-каршы бииләр.*

Челтәр элдем читәнгә,
Челтер, челтер итәргә,
Без килмәдек буш китәргә,
Килдек алып китәргә.

Аллар итәрбез әле,
Гөлләр итәрбез әле

Киләчәктә илебезне,
Чәчәк итәрбез эле.

*Һәркем үзенең сайлап алган пары белән чыгып китә тора. Сәхнәдә ГАРӘФ белән сөйгән кызы Әкрәмә генә калалар. Сандугач сайравы яңгырап тора. Елга буенда су тавышлары ишетелә. Кинәт күк күкрәгән, әллә нинди шомлы тавышлар ишетелә. Егетнең сөйгәне юкка чыга.*

ГАРӘФ. Әкрәмә! Әкрәмә! *(Эзли, таба алмый.)*

*Казарма эче. Баракта әсирләр ГАРӘФНЕ уяталар.*

ӘСИРЛӘР. Дус, уян, уян әле!

ГАРӘФ. Ә? Нәрсә булды?

ӘСИРЛӘР. Кычкырасын бит. Хәлең ничек?

ГАРӘФ. Әй, егетләр, мин бит бүген туган якларда йөрдем. Сөйгәнемне, сөекле җан кисәгемне озата бардым бит.

БЕРЕНЧЕ ӘСИР: Ә нигә кычкырдың соң?

ИКЕНЧЕ ӘСИР. Кеше куркытып.

ӨЧЕНЧЕ ӘСИР. Сөеклең чибәрме?

ДҮРТЕНЧЕ ӘСИР. Исеме ничек?

ГАРӘФ. Югалттым мин уземнең Әкрәмәмне. Ул Зәйнең икенче ягына чыгып югалды. Шуны кычкырып эзләп йөрдем дә инде мин.

ГАРӘФ. Эзләдем, бәгырем, сине.

Кәккүк кычкыра сирәк кенә,

САГЫНУЫН СӨЙЛӘП КЕНӘ.

Килсәң иде, иркәм, яныма

КӨЛЕМСЕРӘП КЕНӘ.

*(Әсирләр кушыла)*

Эзләдем, бәгырем, сине,
Еллар буе тилмереп
Туймас, ахры, мәңге туймас
Күзләрем сине күреп.

БЕРЕНЧЕ ӘСИР. Минем дә сөйгәнемне төштә генә булса да күрәсем килә.

ИКЕНЧЕ ӘСИР. Минем дә.

ӨЧЕНЧЕ ӘСИР. Минем дә...

ГАРӘФ. Без бит Әкрәмә белән бер партада утырып укыдык. Аннары мин учкомда — председатель, ул — секретарь. Әкрәмә белән мәктәптә драмтүгәрәк

оештырып җибәрдек. Сценарийларны үзем язам, үзем уйныйм. Кушаматым — Кыргаяк. Сәхнәдән «Эшче», «Наемщик» арияларын җырларга гаҗәп ярата идем.

*Бер кеше килеп ГАРӘФНЕҢ каршысына баса.*

МУСА. Таныш булыйк, Гумеров булам. Мин дә Казаннан. Татар шагыйре.

ГАРӘФ. Дим Алишев, Карабаштан.

МУСА. Иркәм, тагын нинди җырлар беләсең?

ӘСИРЛӘР. Җырлый ул, бик күп җырлар белә.

БЕРЕНЧЕ ӘСИР. Берсен бетерә, икенчесен башлый.

МУСА. Минем «Висла» дип исемләнгән шигыремне берәр көйгә сала алмассыңмы?

*ГАРӘФ «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясе көенә җырлый, егетләр кушыла.*

Висла! Синең көчле агымыңны
Борып булса иде кирегә.
Дулкыныңа төреп бу гәүдәмне
Илтер идең туган Илемә

МУСА. Синең тавышың бик моңлы икән. Без сине капеллага алырбыз. Немецларга Казаннан филармония артисты, диярбез.

ГАРӘФ. Мин нишләргә тиеш булам соң?

МУСА. Без төрле лагерьларда концерт куеп йөриячәкбез. Легионга керергә димләп безне немец командованиесе җибәрә. Әмма бу турыда соңрак сөйләшербез.

ГАРӘФ. Булдыра алырмынмы икән?

МУСА. Булдырырга кирәк. Бүген мин «Шүрәле» әкиятенә сценарий язармын. Гайнан — вакыйганы сөйләп торучы, Кәрим утын кисүче, Гарәф, син Шүрәле булырсың.

*Төрле почмакларга төркем-төркем булып таралалар. Ничек уйналачак эпизодларны сойләшәләр. Барысы да сүзсез хәрәкәтләр ясыйлар.*
*АБДУЛЛА АЛИШ, ЗӘКИ ӘҺЛИУЛЛИН, ГОМӘР СӘЙФИЕВ, ашханәдә эшләүче САХАП сәхнәдә калалар.*

ЗӘКИ. Абдулла дус, миңа истәлеккә дип «Очрашу» шигырен күчереп алырга бирмәссең микән?

АБДУЛЛА АЛИШ. Бирәм, Зәки дус. Миннән бик күп әсирләр күчереп алды инде. Үзең кайсы яктан буласың соң, кордаш?

ЗӘКИ. Мин дә Карабаштан булам.

АБДУЛЛА. Нинди язмыш җилләре монда китерде?

ЗӘКИ. Бер лагерьда иптәшләр белән сөйләштек тә, качарга булдык. Көн саен стена астын казып, туфрагын чыгара тордык. Бик сак эшләдек, әлбәттә. Менә качу көне җитте. Ике иптәшебез казыган тишектән чыгып качты, мин сыймадым.

АБДУЛЛА. Шуннан, шуннан.

ЗӘКИ. Немецлар белделәр.Үтергәнче кыйнадылар. Калганын белмим.

САХАП. Ашханәдән чүп түгәргә чыгып киләм, күрәм, якташны сөйрәп киләләр. Зәки бит бу, мин әйтәм. Авылдаш. Мәетләр өстенә ыргыттылар да моны, китеп бардылар. Әкрен генә килдем дә карап торам: әле үлмәгән.Төнлә килеп, мәетләр арасыннан табып алдым. Сөйрәп кереп, ашханәнең идән астына салдым. Бер айдан аякка басарлык булды.

АБДУЛЛА. Сахап дус, ярый үзеңне тотмаганнар.

ГОМӘР СӘЙФИЕВ. Таныш булыйк, Абдулла дус, Гомәр Сәйфиев. Сугышка кадәр мәктәптә укытучы булып эшләдем. Минем бер шигырьне тыңлале. Сүзләре күңелгә килеп тора бит. Йөрәк яна, шагыйрь дус. Әсирлек ачысы яндыра йөрәкне!

Тапталмас, югалмас безнең эз
Караса — күрә алса изге күз.
Ул калыр, мәңгегә онтылмас,
Бернинди ул эзгә кер кунмас.

Җәлилнең-Курмашның эзе ул,
Аларның васыяте — сүзе ул.
Аларның сүзләрен көрәштә үтәдек,
Улларны-дусларны көрәшкә күтәрдек.

*Мансуров Алмаз Илдар улы*

# ИЗГЕЛЕК

*Катнашалар:*

МИҢНУЛЛА, 20–25 яшьлек урам сукбае.

СЕРГЕЙ, 30 яшьләр тирәсендәге урам сукбае, МИҢНУЛЛАНЫҢ дусты.

СӘВИЯ АПА, өлкән яшьтә. СӘЛИМӘНЕҢ, СЕРГЕЙНЫҢ әнисе.

СӘЛИМӘ, 20–25 яшьләрдә, ГАЛИЯНЕҢ иптәш кызы

ГАЛИЯ, 20–23 яшьләрдә.

АЙДАР, 25 яшьләрдәге егет, ГАЛИЯНЕҢ егете.

ШӘҮЛӘ, СӘВИЯ апаның намусы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Ярым караңгы сәхнәгә СӘВИЯ апа чыга. Кулындагы комганын читкә куя. Якын ук килеп, күзләрен кыса, дивардагы сәгатькә карый. Җитез, ләкин салмак хәрәкәтләр белән намазлыгын алып идәнгә җәя. Намазга баса.*

СӘВИЯ АПА. Бисмилләһи-ррахманир-рахим. Сөбхәнәкәл ләхүмә үә бихәмдикә вә тәбәрәкәсмүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә илаһә гайрук.

*СӘВИЯ АПА намазга оеп тора. Бераздан рокугка китә. Аннары сәҗдәгә китеп йөзен җиргә тидерә. Шул вакыт аның артында бер шәүлә пәйда була. Кеше чалымнарын абайлап булса да, аның кем икәнен әйтү мөмкин түгел. Шомлы, усал, яңгыравыклы тавыш белән шәүлә телгә килә.*

ШӘҮЛӘ. Бисмилла укып утырган буласыңмы? Һа-һа-һа.

*СӘВИЯ АПА сәҗдәдән тора. Аптырап, тавышны тыңлап утыра. Йөзендә «колагыма ишетеләме соң, әллә юләрләнәм инде» дигән төсле хис чагылып китә. Ул нишләргә белми.*

ШӘҮЛӘ. Беләм, акланасың килә. Изге, имеш! Ясалмаланып утырудан ни мәгънә? Күңелеңдә булмагач...

СӘВИЯ АПА. Бисмилләһи-ррахман-иррахим. Ходаем! Намазымны бүлдерергә килгән Иблистән үзең сакла...

ШӘҮЛӘ. Нәрсә укынып утырасың? Иблис түгел мин. Шайтан, җен дә түгел.

СӘВИЯ АПА. Кем генә булмасын, изге ният белән килмәгәнсең. Бәхет кенә көттереп йөри. Син көтмәгәндә килдең.

ШӘҮЛӘ. Кемлегемне чамаламыйсыңмы?

СӘВИЯ АПА. Юк.

ШӘҮЛӘ. Беләсең киләме?

СӘВИЯ АПА. Әйт...

ШӘҮЛӘ. Киңәшем шул: намусыңны тыңла. Намус бер ак җәймә. Җәймәгә эзләр саласың да, аннары үз язганнарыңны укый алмый интегәсең...

СӘВИЯ АПА. Моның белән ни әйтергә телисең? Намусымны? *(Намазлыктан ашыгып тора, шәүләгә таба омтыла.)*

ШӘҮЛӘ. Әйе... Намусыңны. *(Югала.)*

СӘВИЯ. Тукта! Тукта! *(Йөгереп барып диварга бәрелә, хәлсезләнеп дивар буенча шуып төшә.)*

### Икенче күренеш

*Таң ата. Шәһәр урамы. Кырыйда чүп савытлары. Икенче якта мәчет. Сәхнәдә МИҢНУЛЛА Ул үз алдына нидер сөйләнә-сөйләнә чүплектә казына. Шул вакытта аның янына СЕРГЕЙ керә. Күзләре шешенеп беткән, киемнәре ерткаланган.*

СЕРГЕЙ. Ни хәл, Миңнулла?

МИҢНУЛЛА. Ә, Сережа...

СЕРГЕЙ. Исәнләшмиләр дә берәүләр... Хәлне дә сорамыйлар...

МИҢНУЛЛА. Гаепле, гаепле! *(Ике кулын сузып Сергейга таба бара.)* Хәлләр ничек соң, Серёжа туган?

СЕРГЕЙ. И не спрашивай...

МИҢНУЛЛА. Кара, кара. Нәрсә ди?! Башны әйләндермә, паринь! Йә хәлне сорамыйсың, йә «не спрашивай»...

СЕРГЕЙ. Соң, всегда одинаковый инде? Тормыш бер көнне артка тибә, икенче көнне башка суга...

Миңнулла кулын селтәп, кабат чүп савытлары өстенә иелә. Сергей битендәге яраларын бер тын сыйпаштырып утыра.

СЕРГЕЙ. Ни, Миңнулла.

МИҢНУЛЛА. Нәрсә инде тагын?

СЕРГЕЙ. Менә карап-карап торам да сиңа... Вот скажи, нишләп синең битеңдә бер яра эзе дә юк, ә минеке теткәләнеп беткән?

МИҢНУЛЛА. Һы, кирәкмәгән җирдә буталырга яратасың бит.

СЕРГЕЙ. Шуннан?!

МИҢНУЛЛА. Шуннан шул, Ходай сине югалмасын дип һәрвакыт пичәтен сугып тора!

СЕРГЕЙ. Ә мин чынлап сораган булам тагы...

МИҢНУЛЛА. Ходай яраткан бәндәләрен генә сыный диләр... Бәхет тамгасыдыр ул!

СЕРГЕЙ. Йә, телеңә салынып торма әле, урам эте. Какое счастье? Бушлык монда. Ач мин, ач. Ә син счастье! Счастье!

М И Ң Н У Л Л А. Счастье димим, бәхет дим. *(Чүп савытлары артыннан ярты ипи ала. Үзалдына.)* Әйбер, ризык кадерен белмиләр шул хәзер кешеләр.

*(Сергейга.)* Әйдә, туган, шушыны ашыйк әле...

С Е Р Г Е Й. Фу-у, из мусорки чтоли?

М И Ң Н У Л Л А. Ипи бит ул! Ик-мәк! Икмәк кайда да икмәк, олылыгын югалтмый.

С Е Р Г Е Й. И то правда...

*Алар янәшә утырып, икмәкне сындыра-сындыра ашый башлыйлар. Шул вакыт азан тавышы яңгырый. Сәхнәдә кешеләр күренә. Аларның барысы да шат, бер-берсен җылы сәламлиләр, ике куллап күрешәләр. Бәхетле елмаялар. Соңыннан почмактагы мәчет ишегеннән эчкә кереп югалалар. Азан тавышын ишетүгә* М И Ң Н У Л Л А *кулын догага күтәрә, берничә тапкыр йөзен сыпырып ала.* С Е Р Г Е Й *аның хәрәкәтләрен игътибар белән карап тора.*

С Е Р Г Е Й. Изге кеше син, Миңнулла... Святой! Ни генә сорама, кайчан гына яныңа килмә, кире бормыйсың. Җылы сүзең, киңәшең белән ярдәм итәсең...

М И Ң Н У Л Л А. Серёжа, Серёжа... Дуслык кына бу. Изгелек дип атарга хакың юк. Бер язмыш кешеләре. Бөтенесе уртак, шатлыгы да, кайгысы да. Изгелекнең ни икәнен үзең дә аңламыйсың бит син...

С Е Р Г Е Й. Изгелек ул сиңа ни дә булса бирсәләр. Менә синең кебек, сорамыйча.

М И Ң Н У Л Л А. Ялгышасың... Син әниеңне, әтиеңне, һичьюгы Ходайны изге дияргә тиешсең!

С Е Р Г Е Й. Көлдермә! *(Урыныннан сикереп тора. Дулап.)* Нинди файда тигәне бар алардан? Әнкәйне хәтерләмим. Мин бик кечкенә вакытта ташлаган ул мине. Әтине белмим, үлгән диләр. Ә Ходай? Бармы соң ул Ходаең? Ник без шушы хәлдә, нигә чүп савытыннан алынган ризыкны ашап, кыйналып, туңып яшибез? Әгәр синең Ходаең булса. Ник күрми? Нигә ярдәм итми!

М И Ң Н У Л Л А *(Сергейның якасына ябыша. Көч белән тартып җиргә утырта)*. Аллага тел тидермә! *(Бераз тын торганнан соң.)* Җүләр син!!!

С Е Р Г Е Й. Гафу ит.

М И Ң Н У Л Л А. Кызганам мин сине, Серёжа. Язмышыңны кызганам. Ә мин әниемне оныта алмыйм. Төшләремә керә. Хәтирәләр бугаздан тотып ала да. Уянып китәм.

С Е Р Г Е Й *(аптырап, куркып кына)*. Кайда соң ул?

М И Ң Н У Л Л А. Кем?

С Е Р Г Е Й. Әниең.

М И Ң Н У Л Л А. Үлде.

С Е Р Г Е Й. Күптәнме?

М И Ң Н У Л Л А. Миңа җиде яшь вакытта. Ә син әниеңне каргыйсың. Бәлки, аның сине ташлыйсы да килмәгәндер. Ялгышлыктыр? Мәҗбүр иткәннәрдер?

С Е Р Г Е Й. Барыбер бу аны акламый.

М И Ң Н У Л Л А. Әй, җүләр… Ә мин инде гафу иттем. Бөтенесен дә. Ходайны да, әткәйне дә, язмышымны да… Мөмкинлек булса, хәзер әниемне ныгытып бер кысып кочаклар идем дә, күзләремне кысып-кысып, яратам сине, әнием, дияр идем. Синең хет өмет бар. Әниең исән-саудыр. Теләсәң, таба аласың. Ә минеке… Хыял гына.

*С Е Р Г Е Й  М И Ң Н У Л Л А Н Ы Ң соңгы сүзләрен читкә карап күз яшьләренә буылып тыңлап утыра. Ахырдан иптәшенә сиздермәскә тырышып күз яшьләрен сөрткәләп ала.*

С Е Р Г Е Й. Әйттем бит сине изге дип. Ә мин кем? Бер ерткыч, җансыз, хайван. *(Яңгыратып кычкырып җибәрә.)* Кит! *(Чыгып йөгерә. Миңнулла аның артыннан китәргә омтылыш ясый, булдыра алмый.)*

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Тукталыш. Иртәнге вакыт. М И Ң Н У Л Л А бөгәрләнеп җирдә йоклап ята. Ике кыз килә.*

С Ә Л И М Ә. Шуннан?

Г А Л И Я. Килде дә, артымнан кочаклап алды.

С Ә Л И М Ә. Йә инде… Сөйлә…

Г А Л И Я. Үзең беләсең, андый вакытта егетләр күп сөйләшеп тормыйлар.

С Ә Л И М Ә. Нишлиләр?

Г А Л И Я *(кинәт, Сәлимә сискәнеп куярлык итеп)*. Үбеп алалар! Үбештек без… Әй, сабый бала сыман кыланма санә. Әллә нинди галәмәт ишеткән кебек күзләреңне шакмакландырып утырма.

С Ә Л И М Ә. Егетләрнең кулымнан да тотып карганы юк бит…

Г А Л И Я. Әй, җаный-җаный. Син дә яратырсың, яратылырсың да.

С Ә Л И М Ә. Очрата алмасам? Ул, бәлки, дөньяда да юктыр. Парым дим.

Г А Л И Я. Юк сүз сөйләмә! Әһә, мәхәббәт исен сизәм. Якында гына. Син аны тиздән очратачаксың. Бик тиздән.

С Ә Л И М Ә. Тәк-тәк. Бәй, кияү монда икән бит. Кырмыска җаным, эшлисеңме? Эшлә-эшлә, гаилә тотуы бигрәкләр дә авыр шул.

*Кызлар тирә-якны яңгыратып көләләр.*

С Ә Л И М Ә. Кырмыска булмасын иде инде ул. Нинди генә булса да, адәм затыннан булсын.

ГАЛИЯ *(җирдә йоклап яткан Миңнулланы күреп ала, көлеп җибәрә)*. Әл-лә-лә. Таптым. Кияүең йоклап ята.

СӘЛИМӘ. Ә нәрсә? Кеше бит.

ГАЛИЯ. Улмы?!

СӘЛИМӘ. Җитте, кешнәмә. Айдарың да әллә кем түгел!

ГАЛИЯ. Фәрештәм ул минем.

СӘЛИМӘ. Белмим-белмим. Аркасында канатлары да күренми. Һавага да күтәрелми. Җирдән тәпи-тәпи йөри. Безнең кебек үк кара ипи ашый.

ГАЛИЯ. Анысы шулай...

СӘЛИМӘ. Нигә сөрсемең коелды. Үпкәләмә инде.

ГАЛИЯ. Юк... Дөрес сөйлисең. Айдар аю кебек ул. Лап-лап, лап-лап. Ә мәхәббәт! Очасың! Очасың!

СӘЛИМӘ. Бәхетле син, кызый...

ГАЛИЯ. Бәхетлеме мин? Сөйгән ярың сине үзеңнән артыграк күрсен, син дә аны кадерлә. Шундый кеше белән генә бул, дускай. Мәхәббәт эгоистлар янынннан кача ул.

СӘЛИМӘ. Серле син. Әллә ниләр сөйлисең.

ГАЛИЯ. Башыңны катырма, үз вакытың белән аңларсың әле. Ә хәзер йөгерик. Әнә, автобус китеп бара.

БЕРГӘ. Тукта! Тукта!

## Дүртенче күренеш

*МИҢНУЛЛА йокыдан уяна. Торып утыра. Игътибар белән тирә-ягын күзәтеп ала. Авыр сулап башын ия. Теләр-теләмәс, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, чүп савыты тирәсендә кайнаша башлый.*

МИҢНУЛЛА. Кайларда йөрисең икән, Серёжа туган. Исәнме соң син. Ник шул килеш җибәрдем, ник туктатмадым. Эх!

*Азан тавышы ишетелә. МИҢНУЛЛА ике кулы белән битен сыпыра. Шул вакытта сәхнәдә СӘВИЯ АПА күренә. Ул ашыкмыйча атлый, тукталып азан тавышына колак салып тыңлап тора.*

МИҢНУЛЛА *(тынлык урнашкач, авыр сулап куя)*. Ээээх...

СӘВИЯ АПА. Ник авыр сулыйсың, улым?

МИҢНУЛЛА. Күзләрегез начар күрә бугай, апа. Кем беләндер бутадыгыз.

СӘВИЯ АПА. Нишләп алай дисең?

МИҢНУЛЛА. Соң, эт хәлендә икәнемне күрмисеңме?!

СӘВИЯ АПА. Әй, улым... Җаннарыбыз сукбай, хисләребез хәер сорашып йөргән заманда яшибез... Үз хәлеңнән читенсенмә. Шушы таушалган тәнеңдә ихлас йөрәк бар.

МИҢНУЛЛА. Кирәкми, күңелемә кермә. Анда берни дә калмады инде. Бары җөй дә җәрәхәт.

СӘВИЯ АПА. Шулай да җаның тыныч түгел. Нидер борчый сине.

МИҢНУЛЛА. Бөтенесен дә сизәсең. Авыр вакытымда Ходай тарафыннан җибәрелгән изгеме син?

СӘВИЯ АПА. Хатын-кыз һәрвакыт изге була дип әйтә иде әбием. Бала табу, бала багудан да зуррак савап юк. Ә мин... Улымны ташлап калдырдым. Югалттым. *(Күз яшьләренә буыла, сулкылдап.)* Гөнаһлы мин.

Миңнулла нишләргә белми, Сәвия апа янына бара. Куркып кына кулларын иңнәренә сала.

МИҢНУЛЛА. Йә-йә, елама апа. Мин дә югалттым бит. Дустымны. Сережа исемле. Саксызлыгым аркасында югалттым.

СӘВИЯ АПА. Дөрес әйтәсең, улым, югалттык! Кеше үзе югалмый ул. Үлгәч тә мәңгелеккә күчә. Без генә югалтабыз... Игътибарлы булсакмы... Мәчеткә кереп хәер бир син. Дустыңның саулыгына дога кыл.

МИҢНУЛЛА. Кертмиләр шул, апа... Аллаһ йортын нәҗеслисең диләр. Бәлки алар хаклыдыр да!

СӘВИЯ АПА. Алладан, да диннән дә сәясәт ясаган заманда ни көтәргә инде... Әйдә, катышмыйк. Үзебез генә ихластан дога кылыйк.

*СӘВИЯ АПА белән МИҢНУЛЛА кулларын догага күтәрәләр. СӘВИЯ АПА күзләрен йомып, оеп дога укый башлый.*

СӘВИЯ АПА. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әлһәмдү лилләһи раббил галәмин. Әррәхманирахим мәлики йәүмиддин...

*Бәхәсләшә-бәхәсләшә АЙДАР белән ГАЛИЯ чыга. Тукталыш эскәмиясендә утырган МИҢНУЛЛАНЫ, СӘВИЯ апаны күрмиләр. Аларның тавышыннан МИҢНУЛЛА сискәнеп куя. Куркып читкә китә, бөрешеп утыра. Моны күреп СӘВИЯ АПА да сүзсез кала. Дога ярты юлда бүленә.*

ГАЛИЯ. Айдар, гел алай булмый инде. Көнләшәсең дә, көнләшәсең...

АЙДАР. Теләсә кемгә елмаеп йөри дә.

МИҢНУЛЛА *(үзе генә ишетерлек итеп)*. Тагын бүлдерделәр. Изге сүзләр чоры түгел шул. Этләр кебек өрергә генә торалар.

ГАЛИЯ. Соң, әйт алайса. Ни ул мәхәббәт!

АЙДАР. Ләззәт. Җәмгыять законы. Янында кемдер булырга тиеш. Шул гына.

ГАЛИЯ. Ә хисләр? Уртак хыяллар?

АЙДАР. Алары шагыйрьләр уйлап тапкан дураклык кына. Кешедән файда бар икән, парың була. Юк икән — башкасына барасың.

ГАЛИЯ. Үпкәләтергә телисеңме? *(Ике кулы белән йөзен каплап тукталышка таба йөгерә. Сәвияне күреп кисәк туктап кала.)* Исәнмесез, Сәвия апа. *(Читкә борыла, сиздермәскә тырышып күз яшьләрен сөртеп ала, аннары аның янына барып утыра.)* Ни хәлләрдә яшәп ятасыз?

СӘВИЯ АПА. Шөкер, акрын гына. Югалдың. Соңгы арада безгә дә килмисең.

ГАЛИЯ. Кәеф юк. Бер дә өйдән чыгасы килми.

*АЙДАР ашыкмыйча гына, ачулы кыяфәт белән ГАЛИЯ янына бара. Беркемгә дә игътибар итмичә аңа төбәлә. Кыз йөзен читкә бора.*

АЙДАР. Чистый надоел инде бу кызый. Җитте спектакль куярга.

ГАЛИЯ. Үзем дә күптән арыдым шул.

*МИҢНУЛЛА якынрак килә. Кызганып та, ниндидер наз белән дә ГАЛИЯГЩ карый. АЙДАР аны күреп ала. Кырын-кырын МИҢНУЛЛАГА карап алгалый.*

СӘВИЯ АПА. Ни булды, балакайлар? Алай әйткәләшергә кирәкми. Арадан кара мәче үтмичә тормый. Бер-береңне кичерә белергә генә кирәк.

ГАЛИЯ. Нишләсәң дә көнләшә бит.

СӘВИЯ АПА. Никахлы хатының түгел бит. Тәртипле кыз. Башкалар караса сөен генә. Дөрес сайлагансың.

ГАЛИЯ. Мин дә шулай дим. Мәхәббәт чын, ихлас, илаһи булырга тиеш. Бер-береңә яхшылык эшләргә, дөньяда нинди дә булса изгелек кылырга теләк булсын...

АЙДАР. На-до-е-ли инде. Җитте! Изгелек, хисләр, ярату! Алар белән чүплек башына чыгып утырасыңны көт тә тор. Акча кирәк бүген. Акча эшләргә кирәк! Акчаң булса, ирекле буласың!

*Аның кыланмышларыннан барысы да куркып калалар. ГАЛИЯ СӘВИЯ апасына елыша. АЙДАР кайда барып бәрелергә белмичә бөтерелә.*

АЙДАР. Изгелек дисез алайса. Эшлим хәзер изгелекне. *(МИҢНУЛЛАГА төртеп күрсәтә.)* Күрәсеңме, баядан бирле сиңа карап селәгәен агызып утыра. Хәзер әрәмтамакны җәннәткә җибәрәм. *(МИҢНУЛЛАГА.)* Кил монда!

*АЙДАР кесәсеннән пәке тартып чыгара. ГАЛИЯ эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, аның кулларына барып асылына. АЙДАР аны селтәп ата да, МИҢНУЛЛАГА ташлана. Пәке белән берничә тапкыр селтәнә, яралый. Башта АЙДАР, аннары ГАЛИЯ чыгып йөгерәләр.*

МИҢНУЛЛА. Кабәхәт!

С Ә В И Я А П А. Рәнҗемә улым, кичер Айдарны. Шайтан гына котырткан. Дөнья күптәннән шайтан кубызына бии. Үзенең язылмаган, ялган кануннары белән яши. Кичер балам, кичер, кичерә күр.

## Икенче пәрдә

### Беренче күренеш

*С Ә В И Я апаның өе. Эңгер-меңгер вакыты. Уртада өстәл. Стена буенда иске диван. Икенче якта карават. Караватт янәшәсеңдә сандык. Караватта М И Ң Н У Л Л А йоклап ята. С Ә В И Я апа намазлыкка тезләнгән, күзләрен йомып намазга оеган. Бүлмәдә тынлык, стенадагы сәгатьнең йөргән тавышы гына ишетелә. Кинәт карчыкның артында шәүлә пәйда була.*

Ш Ә Ү Л Ә. Акны каралтуы җиңел, караны агартып кара менә.

С Ә В И Я А П А *(күзләрен ача)*. Беләм, гөнаһларым кичерелми торган. Шуңа күрә Ходайдан бу турыда сорамыйм да. Гомеремнең соңгы көннәрен дөрес итеп яшисем генә килә.

Ш Ә Ү Л Ә. Һа-һа-һа. Дөреслекнең нәрсә икәнен белмәгән килешме? Хәтта гафу да сорамыйсың, Ходайның мәрхәмәтле булуыннан да шикләнәсең? Шулмы хакыйкать?

С Ә В И Я А П А. Ә дөреслекне кем белә? Һәр кеше үз кануны буенча гына яшәгәндә нишләргә. Нәрсә генә эшләсәң дә гаепләргә торалар. Намусыңа төкерәләр алар!

Ш Ә Ү Л Ә. Димәк, күңелеңдә хөсетлек, ялган, мәкер икәнен, синең белән шулар идарә иткәнен таныйсың?

С Ә В И Я А П А. Танымыйм! Шулай да вакытында намусым кушканча эшли алмадым?

Ш Ә Ү Л Ә. Куркыныч кеше син, Сәвия! Үтерүче үтерәм дип, кылган гамәленең дөреслегенә инанып эшли. Ә син? Җинаятьче дә, хөкемдәр да. Намус аны кулланмаганда гына чиста кала ала. Гомерең буе газапланачаксың әле син.

*Шәүлә юкка чыга. С Ә В И Я намазлыкка капланып үкси. Шул тавышка М И Ң Н У Л Л А уянып китә. Торып утыра. Башта тавышның кайдан килгәнен, нинди тавыш булуын аңламый. Бераздан С Ә В И Я Н Е күреп ала.*

М И Ң Н У Л Л А. Апа... Апа дим.

С Ә В И Я А П А. Әү, балам? *(Тора, чайкала-чайкала Миңнулла янына барып утыра.)*

М И Ң Н У Л Л А. Көн дә шул хәл, Сәвия апа. Газаплануыңны күрүе бигрәкләр дә кыен.

СӘВИЯ АПА. Баштарак үземә дә авыр иде. Хәзер ияләнәм инде. Намусым тынгылык бирми миңа. Намазга бассам да, тынычлап укый алмыйм. Башыма ят уйлар керә, намазым бозыла.

*Икесе дә тынып калалар. СӘВИЯ торып, өстәл өстендәге рамлы фотоны алып килә. Бер тын сыйпаштырып утыра.*

СӘВИЯ АПА. Күрәсеңме, Миңнулла. Улымның ике яшьлек чагы.

МИҢНУЛЛА. Синең улың да бармы? Бер дә күренгәне юк. Килеп йөрмиме?

СӘВИЯ АПА. Югалттым мин аны...

МИҢНУЛЛА. Кемне?

СӘВИЯ АПА. Улымны. Дөресрәге, тартып алдылар. Истәлек булып шушы бердәнбер фотосы калды. Хәзер ул үскәндер инде. Менә синең чама булгандыр. Бәлки, синнән бераз өлкәнрәктер.

МИҢНУЛЛА *(фотога карап)*. Кайларда йөрисең икән син. Эзләргә кирәк. Үзең әйтмешли, үзебез югалтабыз! Үзебез табарга да тиешбез!

СӘВИЯ АПА. Эзләмәдемме соң инде. Йөрмәгән җир калмады.

МИҢНУЛЛА. Һәм?

СӘВИЯ АПА. Эзсез югалган.

*Ишектән СӘЛИМӘ күренә. Кергән уңайдан утны кабыза.*

СӘЛИМӘ. Караңгыда утырмасагыз... Тагын еладыңмы, әни. Әни, әни! Үзеңне газаплап яшәү рәхәтме әллә.

СӘВИЯ АПА. Әй кызым, үзең ана булгач аңларсың әле.

СӘЛИМӘ. Әйдә, әни. Кайнар чәй эчеп ал. Ятып торырсың.

*СӘЛИМӘ СӘВИЯНЕ култыклап алып чыга башлый. Шул вакытта кыңгырау тавышы ишетелә.*

СӘЛИМӘ. Миңнулла бар, ача тор әле. Галиядер ул.

*МИҢНУЛЛА яшерен генә елмаеп куя. Ләкин озак та үтми аның йөзендә икеләнү, борчылу, дулкынану сизелә башлый. Ул тынычсыз рәвештә бүлмә буйлап йөренә. СӘЛИМӘЛӘРНЕҢ чыгып киткәнен күргәч, үзенә ишек ачарга кушылганын искә төшергәндәй, сәхнәдән чыгып китә.*

## Икенче күренеш

*Шул ук бүлмә. Тиз-тиз МИҢНУЛЛА килеп керә. Үзенә урын таба алмыйча ары сугыла, бире сугыла. Аптырагач, өстәл янына килеп баса. Артыннан йөгереп ГАЛИЯ керә.*

ГАЛИЯ *(көлеп)*. Артыгызга ут төрттеләрме әллә, Миңнулла әфәнде. Җен баласы күрдегезмени. Ишек ачтыгыз да, ялт, юкка да чыктыгыз.

МИҢНУЛЛА *(читкә борыла. Урындыкка утыра. Сер бирмәскә тырышып).* Ну, танымадым.

ГАЛИЯ. Танымаслык шул… Бишенче тапкыр гына күрешәбез бит.

МИҢНУЛЛА *(елмаеп).* Килгән саен үзгәреп килгәч.

ГАЛИЯ. Кай җирем үзгәргән.

МИҢНУЛЛА. Телегез тагын да озынайган дип әйтимме.

ГАЛИЯ. *(үпкәләми, көлеп кенә кабул итә).* Тел озын анысы. Бик күзәтүчән икәнсез.

МИҢНУЛЛА. Тагын…

ГАЛИЯ. Тагын ни?

МИҢНУЛЛА. Килгән саен гүзәлләнә барасыз.

ГАЛИЯ *(көлә-көлә бүлмә буйлап бөтерелә).* Ай-яй-яй. Сезнең дә телегез ачыла башлады. Ә телегез сандугачныкы.

*МИҢНУЛЛА көзге янына бара, телен чыгарып карый.*

ГАЛИЯ. Нишләвегез бу?

МИҢНУЛЛА. Сандугач теле нинди була икән, күргән нәрсәм түгел бит.

*ГАЛИЯ диван читенә барып утыра. МИҢНУЛЛА бераз көзге янында юана да, караватка барып ава. Бүлмәдә тынлык. ГАЛИЯ мендәрне курчак итеп бераз уйнап утыра. Аннары җитди тавыш белән МИҢНУЛЛАГА эндәшә.*

ГАЛИЯ. Миңнулла…

МИҢНУЛЛА. Ә-ә-әү?

ГАЛИЯ. Авызың дәү. Мин сиңа ошыйммы ул?

МИҢНУЛЛА. Бик фәлсәфи сорау бирәсез, Галия туташ.

ГАЛИЯ *(Миңнулланың янына барып утыра, күзләренә карый).* Һәр фәлсәфәнең нигезендә гадилек ята. Гади итеп әйт, йөрәгеңдәгене әйт.

МИҢНУЛЛА *(торып читкә китә).* Минем йөрәгем — урам сабакасы. Ошатырга да, яратырга да ярамый аңа. Яратудан бизгән дә инде ул.

ГАЛИЯ. Ә Ходай адәм балаларына яратырга, яратылырга кушкан. Үзең сөйгән, ихлас сөйгән кешең белән бергә булырга кушкан. Алланың теләгенә, боерыгына каршы барырсыңмы?

МИҢНУЛЛА. Аңламыйсың син. Яратам дип кенә… Урамга килен төшерә алмыйм инде. Рәхим итегез. Менә сезгә өч контейнерлы чүплек. Бөтен уңайлыклары үзендә.

ГАЛИЯ. Сөйгәнең аңласа, сине ничек бар шулай кабул итсә.

МИҢНУЛЛА. Әкиятләрдә генә була.

ГАЛИЯ. Ә син әкияткә ышан. Аңа таба адым яса, белгерт.

МИҢНУЛЛА *(Галиянең каршына килеп утыра. Кулыннан тота)*. Белгәч, бөтенләй күрергә теләмәсә...

ГАЛИЯ. Чын ихлас хисләр булса, бар да әйбәт булачак.

МИҢНУЛЛА. Син моңа ышанасыңмы?

ГАЛИЯ. Ышанам, Миңнулла, ышанам!

МИҢНУЛЛА. Алайса, яратам, Галия! Сине генә сөям. Теге көннән бирле сөям.

*ГАЛИЯ учын МИҢНУЛЛАНЫҢ кулыннан тартып ала, сикереп тора. Бер тын аңа карап торганнан соң чыгып йөгерә.*

МИҢНУЛЛА. Җүләр! *(Чыгып китә.)*

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Шул ук бүлмә. СӘВИЯ өстәл әзерли. Кулына гәҗит тотып, МИҢНУЛЛА керә. Ул тынычсыз. Гәҗитен диванга ташлый. Караватка барып утыра.*

СӘВИЯ АПА. Соңгы арада бер дә үзеңә урын таба алмыйсың.

МИҢНУЛЛА. Яраларым да төзәлде. Китәм мин, Сәвия апа.

СӘВИЯ АПА. Китәсең? Кая?

МИҢНУЛЛА. Урамга. Минем йортым — урам.

СӘВИЯ АПА. Әй, балакай-балакай. Сине куган кеше юк ла. Рәхәтләнеп яшә. Бергә күңеллерәк тә.

МИҢНУЛЛА. Рәхмәт, Сәвия апа. Кабул иттегез. Авыр вакытта ярдәм кулын суздыгыз. Артыгын тора алмыйм. Кешечә яши алмыйм икән инде. Джунглидагы кебек. Кыргый мин монда.

*Ишектә кыңгырау тавышы.*

СӘВИЯ АПА. Кем булыр икән бу? Бар балам ач әле.

*МИҢНУЛЛА ишек ачарга китә.*

СӘВИЯ АПА. Бәлешем ничек икән анда, карап керим әле.

*МИҢНУЛЛА белән СЕРГЕЙ күренәләр.*

МИҢНУЛЛА. Түрдән уз, Сережа туган!

СЕРГЕЙ. Так-то ничава күренәсең. Түгәрәкләнеп тә киткәнсең.

МИҢНУЛЛА. Китәм мин, Сережа!

СЕРГЕЙ *(өйдәге җиһазларны карап йөри)*. Кая?

МИҢНУЛЛА. Урамга кайтам.

СЕРГЕЙ *(йөгереп барып кочаклап ала)*. Родненький. Пора-пора. Сагынып беттем үзеңне.

МИҢНУЛЛА. Тик күңелсез бераз.

СЕРГЕЙ. Да, теге юлы килгәндә гашыйк булдым дигән идең. Влюбился алайса?

МИҢНУЛЛА. Әйе.

СЕРГЕЙ. Нишлисең соң?

МИҢНУЛЛА. Билгеле инде.

СЕРГЕЙ. Да, шансов никаких.

*СЕРГЕЙ өстәлдәге фотоны күреп ала. Кулына алып карый. Куеныннан тагын бер рәсем чыгарып чагыштырып тора.*

СЕРГЕЙ *(өстәлдәге сүрәтне Миңнуллага суза. Дулкынланып)*. Кем бу?

МИҢНУЛЛА. Әй, Сәвия апаның югалган улы.

СЕРГЕЙ. Улы?!

МИҢНУЛЛА. Әйе, ике яшьлек вакытта югалткан ул аны.

СЕРГЕЙ *(куеныннан алган фотоны сузып)*. Хәзер монысын кара.

МИҢНУЛЛА. Каян килде бу сиңа?

СЕРГЕЙ. Мин ул!

*МИҢНУЛЛА рәсемнәрне өстәлгә куя. СЕРГЕЙНЫ өстерәп диярлек, диванга утырта.*

МИҢНУЛЛА. Тынычланыйк әле туган. Сөйлә, кайдан алдың ул рәсемне.

СЕРГЕЙ. Нәрсәсен сөйлим. Миңа аны детдомда дали. Сохранил...

МИҢНУЛЛА *(шатланып)*. Сережа, сөен! Әниең табылды. Сәвия апа синең әниең булып чыга.

СЕРГЕЙ. Сәвия апа? Әнием?

*Поднос тотып СӘВИЯ чыга. СЕРГЕЙ белән МИҢНУЛЛА беренче тапкыр күргәндәй аңа текәләләр.*

СӘВИЯ АПА. Ни хәл, Сережа. Ник шаккаттыгыз? Әллә өстем буялганмы? *(Өстенә күз ташлап ала. Тәртиптә икәнен күргәч, яулыгын рәтләп бәйли.)* Йә, йә, сөйләшегез. *(Подностагы әйберләргә өстәлне бушатыр өчен, ике фотоны да кулына ала. Башта озак кына аңламыйча карап тора. Аннары гаҗәпләнеп)*. Кайдан алдыгыз моны?

МИҢНУЛЛА. Сергейга балалар йортында биргәннәр. Шулай бит Сережа?

СӘВИЯ. Димәк... Димәк син... Балам! *(Сергейның аякларына барып егыла)*.

СЕРГЕЙ *(гаҗәпләнеп, битараф)*. Әни?!

### Дүртенче күренеш

*Шул ук бүлмә. ГАЛИЯ, СӘЛИМӘ, СӘВИЯ бүлмәне бизиләр, табын әзерлиләр. ГАЛИЯ әле бер, әле икенче эшкә барып тотына. Акрын гына җыр көйли.*

ГАЛИЯ.

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар
Өзеп бирер кешең булмагач?
Нәрсә соң ул күктә янган кояш,
Үз кояшың балкып тормагач.

*(СӘВИЯ янына йөгереп бара)*. Апа, килер микән?

СӘВИЯ АПА. Әй, балам. Ходай насыйп итсә, килер. Серёжа күтәреп булса да алып киләм диде ич. Дустын тыңламыйча калмас.

ГАЛИЯ *(бүлмә буйлап бөтерелә. СӘЛИМӘГӘ барып ябыша. Кулларыннан тотып әйләндерә башлый)*. Бие, бие, Хәйбулла. Биегән кеше бай була!

СӘЛИМӘ. Ә-ә-ә-әй, җитте кызый. Егасың бит. Бәхетле син, кызый.

ГАЛИЯ. Әйе, бәхетле.

*Ишектә кыңгырау. ГАЛИЯ ачарга йөгерә. СӘЛИМӘ белән СӘВИЯ түземсезләнеп көтәләр. СЕРГЕЙ белән ГАЛИЯ керәләр.*

ГАЛИЯ *(шатланып)*. Нәрсә диде? Соңрак үзем киләм дидеме?

СЕРГЕЙ. Тапмадым мин аны.

БЕРГӘ. Ничек?

СЕРГЕЙ. Киткән ул, бөтенләйгә киткән.

*ГАЛИЯ елап, СӘВИЯНЕҢ иңнәренә барып сарыла.*

СЕРГЕЙ. Изге кеше иде ул Миңнулла. Тормышыбыздагы гаделсезлеккә түзә алмады.

СӘВИЯ АПА. Һәр кешенең үз юлы, балакайлар. Үзе китмәде, без җибәрдек. Тормышыбыз рәтләнсә, кайтыр ул.

ГАЛИЯ. Табам, барыбер табам. Ышандырам.

### Бишенче күренеш

*Буш сәхнә. МИҢНУЛЛА чыга. Элекеге сәләмә киемнәрен кигән. Ләкин баштагыңа караганда чистарак. Кырынган. Сәхнә уртасында туктап кала.*

МИҢНУЛЛА. Кешеләр! Китәм мин кешеләр! Мәңгелеккә китәм. Югалырсың диярсез. Югалмыйм. Сез югалтасыз мине. Битарафлыгыгыз ар-

касында, югалтасыз. Моннан соң игътибарлырак булсагыз иде. Мине генә югалтудан бер нидә үзгәрмәс. Минем кебек күпләрне югалта башласагыз. Туганлыкны, дуслыкны, мәхәббәтне, милләтне, динне, тарихны югалта башласагыз. Ни булыр? Туганнар, онытмагыз мине. Бәлки минем кебек берәү сезнең арагызда да бардыр. Зинһар, югалтмагыз аны. Ул миннән бәхетлерәк булса иде. *(МИҢНУЛЛА сәхнәдән чыгып югала.)*

### Алтынчы күренеш

*Буш сәхнә. МИҢНУЛЛА белән ГАЛИЯ ап-актан киенгәннәр. Бер-берсенең кочагына сыенып басып торалар. Җыр җырлыйлар.*

ГАЛИЯ.

Еллар буе мин бит сине көттем,
Бары сине генә эзләдем.
Юлларымда очрыйсыңны белдем,
Һич тә өметемне өзмәдем.

ГАЛИЯ белән МИҢНУЛЛА.

Гомерлеккә Яратырга диеп,
Аерылмаска диеп килешик.
Ай-йолдызлар гына шаһит булсын,
Гомерлеккә вәгъдә бирешик.

МИҢНУЛЛА.

Язмышыма чиксез рәхмәтле мин,
Йөрәгемә ялкын, ут аттың.
Бер карауга гашыйк иттең мине,
Бер күрүгә сине яраттым.

ГАЛИЯ белән МИҢНУЛЛА.

Гомерлеккә яратырга диеп,
Аерылмаска диеп килешик.
Ай-йолдызлар гына шаһит булсын,
Гомерлеккә вәгъдә бирешик.

*Палачёв Константин Сергеевич*

# ТИПИЧНЫЙ СЛУЧАЙ

*Действующие лица:*

АНАТОЛИЙ, старшеклассник.
МАМА, мама Анатолия.
РОМА, друг Анатолия.
МАША, одноклассница Анатолия.
УЧИТЕЛЬ МАТЕМАТИКИ, женщина лет пятидесяти.
ДИРЕКТОР, мужчина лет сорока.
КОММЕНТАТОРЫ 1, 2, 3, марионетки.

## Первое действие

*Дом, комната Анатолия. Поздний вечер, АНАТОЛИЙ отдыхает.*

*Телефонный звонок.*

АНАТОЛИЙ. Привет, чего звонишь в такое время?

РОМА. Привет. Да штуку такую узнал. Просто отвал всего!

АНАТОЛИЙ. Ну не тяни тогда, раз такие новости.

РОМА. В общем и целом, разработчики «Чародеев» пригласили для создания карт нового художника. И спорю, что ты не догадаешься, кто он.

АНАТОЛИЙ. Ну. Удиви меня.

РОМА. Он татарин! Прикинь! Это ж так круто, наш художник работает над игрой мирового уровня!

АНАТОЛИЙ. Вау, видимо, он и правда, очень хороший художник, раз его пригласили. А покажешь работы, которые он сделал?

РОМА. Я пока не углублялся в этот вопрос, но видел иллюстрацию к карте из нового выпуска «Чародеев». Я тебе уже отправил её фото. Посмотришь, как будет время. Кстати, я хотел еще спросить, ты на выходных свободен? Мы хотели с парнями собраться у меня, поиграть. Ты с нами?

АНАТОЛИЙ. Пока не знаю, ближе к пятнице напишу тебе. Просто есть вероятность, что меня заберут на дачу, а это, если я еще не рассказывал, на все выходные.

РОМА. А, ну понятно тогда. Ладно, я пошёл греть ужин. Надеюсь, на дачу тебя не заберут. Всё, давай, пока.

АНАТОЛИЙ. Приятного аппетита. Пока.

*Выключает телефон.*

АНАТОЛИЙ. Надо хоть посмотреть, что там Рома мне отправил. *(Смотрит фото.)* Нарисовано, конечно, неплохо. Но если б Рома не сказал, я б и не узнал, что автор — татарин. Мог бы и частичку татарской культуры привнести в свою работу что ли. Хотя, это же на заказ — не сказали, вот и не нарисовал.

МАМА. Толя! Ужин готов! Иди скорее, я кыстыбыев нажарила!

АНАТОЛИЙ. Иду!

## Второе действие

*Комната Анатолия. Он лежит на кровати.*

АНАТОЛИЙ. А что, если мне начать рисовать собственные карты в татарском стиле? Шурале там, Водяную. Татарская культура же так богата, а в мире о ней почти ничего не знают, если точнее, совсем ничего. Точно! Это же такая возможность прославиться! Если я смогу нарисовать героев тех же татарских сказок на картах «Чародеев» и покажу другим игрокам, все же обзавидуются. Может, кто-нибудь даже купит пару штук. Но чем рисовать? Я слышал, что художники используют для этого акрил, но он дорогой… Черт, а у меня денег — всего полторы тысячи со дня рождения, да десяток рублей на проезд. Просить у родителей не вариант — не хочу обременять своими проблемами, так еще и выпускной класс, не стоит им говорить о своём увлечении, они не будут этому рады. Не сейчас. Может, есть краски дешевле? Ладно, завтра посмотрю.

## Третье действие

МАМА. Толя! Кушать будешь?

АНАТОЛИЙ. Нет, мам, я в школе поел!

МАМА. Ты же говорил, что еда в столовой только собакам на корм годится.

АНАТОЛИЙ. Ну не нравятся мне школьные котлеты, но сегодня плов был, в этот раз даже тёплый.

МАМА. А это что у тебя там, на столе?

АНАТОЛИЙ. Краски. Акриловые.

МАМА. И зачем тебе? ИЗО же нет в одиннадцатом классе.

АНАТОЛИЙ. Да вот решил попробовать себя в высоком искусстве — живописи.

МАМА. Живописи? А в математике себя еще не пробовал? Почему тройка в электронном журнале стоит?

АНАТОЛИЙ. Ну, мам. Тройка и тройка. Чего привязалась? Ты же знаешь, я её тремя пятёрками закрою, и всё! Десять лет за год пятерки получал, и в этом получу.

МАМА. Ладно, не кипятись ты так. Я пошла в магазин, тебе что-нибудь купить?

АНАТОЛИЙ. Нет, спасибо. Разве что мороженого, тем более, такая жара на улице стоит.

МАМА. Хорошо, куплю. Обед в холодильник убрала. Захочешь есть — погреешь.

АНАТОЛИЙ. Хорошо.

МАМА. И не забудь мусор вынести.

АНАТОЛИЙ. Не забуду.

МАМА. И чего это пыль у тебя на рабочем столе? Протри его.

АНАТОЛИЙ. Ладно, протру.

МАМА. Ну, всё, я ушла. Пока.

АНАТОЛИЙ. Пока.

АНАТОЛИЙ. Лишь бы она потом не привязалась к моим рисункам. Ладно, надо хоть испробовать то, что я накупил на тысячу рублей. *(Рисует.)* И зачем я только купил этот дешевый и бесполезный акрил! Одна сплошная грязь, а не цвета! Да как можно было вообще подумать, что краски по сто пятьдесят рублей за баночку будут хорошо лежать!? Дурак я, дурак!

*Телефонный звонок.*

АНАТОЛИЙ. Алло! Рома!

РОМА. Да, привет. Слушай, не забыл про моё предложение? Уже пятница как-никак.

АНАТОЛИЙ. Слушай, нет, никак. Я просто тут решил заняться художественной самодеятельностью. И пока ничего не получается. Видимо, пролетел с красками сильно.

РОМА. Понимаю. А нахимичить с красками ничего не пробовал? Может, в интернете есть советы какие?

АНАТОЛИЙ. Думаешь, стоит? Так не хочется заниматься этим «зельеварением» по рецептам из интернета.

РОМА. Да я так, просто предложил. Как знаешь.

АНАТОЛИЙ. За совет спасибо, конечно, но я еще подумаю. Может, и правда займусь этим. А может, и нет.

РОМА. Ладно. Не буду тебя больше задерживать. Удачи тебе с красками.

АНАТОЛИЙ. Да, спасибо. Пока

РОМА. Пока.

АНАТОЛИЙ. Нахимичить… Может, правда есть дельные советы в Интернете?

## Четвертое действие

*Школа.*

УЧИТЕЛЬ МАТЕМАТИКИ. Ну-с, может, объясните мне, почему у вас такие плохие оценки за контрольную работу? Выпускной класс! И совершать такие ошибки! Вам не стыдно?

МАША. Вот достала, а? У меня художка до восьми вечера, еще репетитор, а она тут со своей контрольной.

АНАТОЛИЙ. Да-а, неприятно всё это. А репетитор не по русскому?

МАША. Нет, по математике. В русском я хоть что-то понимаю, а с математикой совсем беда.

УЧИТЕЛЬ МАТЕМАТИКИ. Кто там разговаривает!? Имейте уважение к учителю. Я им ошибки объясняю, а они шепчутся.

АНАТОЛИЙ. Маш, слушай. Ты же на художку ходишь. А ты какими красками пользуешься?

МАША. Да всякими, смотря, что рисовать. Есть гуашь, есть акварель там, масляные.

АНАТОЛИЙ. А акриловые есть?

МАША. Где-то были, но я ими пока особо не пользуюсь. А что такое?

АНАТОЛИЙ. Да вот хочу в высоком искусстве себя попробовать. Можешь одолжить мне цветов пять-шесть, попробовать?

МАША. Да они мне пока не нужны, могу все принести, если хочешь.

АНАТОЛИЙ. Если можно, то хочу.

МАША. Тогда я их завтра тебе принесу, отдам перед уроками.

АНАТОЛИЙ. Хо…

УЧИТЕЛЬ МАТЕМАТИКИ. Так, открываем тетради, записываем сегодняшнее число.

## Пятое действие

*На следующий день. Школа.*

МАША. Вот, все в пакете.

АНАТОЛИЙ. Так много, больше, чем я себе представлял.

МАША. На художке столько требовали, вот и пришлось купить.

АНАТОЛИЙ. Хорошие?

МАША. Ложатся хорошо и цвет не теряют, так что вполне себе.

АНАТОЛИЙ. То, что надо! Спасибо. Тебе когда их возвращать?

МАША. Да мы акрил прошли уже, и возвращаться пока не собираемся. Так что не торопись, распробуй: так порисуй, сяк порисуй. Я б тебя научила, но времени нет.

АНАТОЛИЙ. Ничего страшного, рисовать как-нибудь научусь. Просто красок не было.

## Шестое действие

*Комната АНАТОЛИЯ.*

АНАТОЛИЙ. Эврика! Получилось!

МАМА. Чего ты разорался так?

АНАТОЛИЙ. Я треугольник нарисовать смог.

МАМА. Треугольник и треугольник — три точки, да три палки, что тут рисовать-то?

АНАТОЛИЙ. Да ты не поняла, не фигура, а эчпочмак, пирожок который.

МАМА. Ну, и зачем тебе эчпочмаки рисовать? Лучше бы физику учил.

АНАТОЛИЙ. Не понимаешь ты ничего. Я, может, художник по натуре, а ты с физикой своей лезешь.

МАМА. Да у нас тут каждый третий — художник, еще и ты со своими треугольниками.

АНАТОЛИЙ. Вот именно, что с треугольниками. Много ли ты знаешь знаменитых художников, отражающих татарскую культуру в своих работах?

МАМА. Никого. Да и кому это интересно? Сейчас в галереях одни абстракции висят. Ничегошеньки не понятно, но всем нравится.

АНАТОЛИЙ. Вот именно, я буду первым. Как все знают «Черный квадрат» Малевича, так потом эти же люди будут говорить об «Эчпочмаке» Анатолия.

МАМА. Первым будет он. И вообще, мне кажется, что это какой-то заговор художников-недоучек, которые проникли в художественную элиту и выкинули работы талантливых людей из галерей.

АНАТОЛИЙ. Да ничего ты не понимаешь, мама, выйди лучше, не мешай моему творческому гению.

МАМА. Творческому гению.

АНАТОЛИЙ. Что бы еще такого нарисовать? Можно Шурале. Да, он же сказочный персонаж, а я художник, я так вижу. Надо рассказать об этом Роме.

*Телефонный звонок.*

РОМА. Алло.

АНАТОЛИЙ. Привет, Рома.

РОМА. О, Толик, привет. Как там у тебя с красками? Нашел чего в интернете по этой теме?

АНАТОЛИЙ. Да я даже не искал, у одноклассницы краски одолжил. Но я тебе не за этим звоню.

РОМА. Слушаю.

АНАТОЛИЙ. Я смог поменять иллюстрацию к одной из карты «Чародеев» на эчпочмак!

РОМА. Звучит интригующе, я бы глянул. Да что там глянул, если получилось реально круто, то я бы даже купил.

АНАТОЛИЙ. Да, я на следующую встречу принесу её. Но у меня к тебе есть вопрос. Если брать татарские мотивы для иллюстрации, то какие темы ты считаешь самыми интересными?

РОМА. Дай подумать… Наверно, сказки и эпоха татаро-монгольского нашествия. Это, как мне кажется, самое интересное в татарской культуре и истории.

АНАТОЛИЙ. Я примерно так же думал, просто хотел уточнить у потенциального клиента его мнение.

РОМА. Ты только всех подряд не слушай. Делай то, что нравится тебе, тогда ты сможешь делать это хорошо, и появятся поклонники.

АНАТОЛИЙ. Да-да, спасибо за совет. Я тогда начну делать наброски для новых работ. Напомни, когда мы собираемся в следующий раз?

РОМА. Всё так же, ближайшая суббота, в три часа дня.

АНАТОЛИЙ. Хорошо. Тогда, до встречи!

РОМА. Угу. Давай, пока.

АНАТОЛИЙ. Значит, Золотая Орда. Конница, разруха, грабежи, битвы русских воинов с татаро-монгольскими кочевниками. Что ж, у меня целое поле для деятельности, творчества, я бы даже сказал, степь.

## Седьмое действие

*Комната АНАТОЛИЯ.*

АНАТОЛИЙ. Думаю, получилось неплохо. Может, стоит поделиться в группе, чтобы люди оценили? Да. Так и сделаю.

*Выкладывает запись в группу.*

КОММЕНТАТОР 1. И зачем карты испортил?

КОММЕНТАТОР 2. Ты кисти в руках до этого держал когда-нибудь?

КОММЕНТАТОР 3. Что за мазня? Не понятно ничего.

АНАТОЛИЙ. Да тише вы, я ж в первый раз этим всем занялся.

КОММЕНТАТОР 2. Лучше бы в школу ходил, да уроки учил, а не этим всем занимался!

КОММЕНТАТОР 3. И что это за фигуры непонятные? Тебе десять лет или сколько?

КОММЕНТАТОР 1. Не лезь не в своё дело, коль руки кривые!

АНАТОЛИЙ. Да отстаньте вы! Надоели мне!

КОММЕНТАТОРЫ. Ха-ха-ха, ну и идиот!

*Анатолий выключает компьютер.*

АНАТОЛИЙ. Во, прицепились. Ну ладно, видимо, у меня действительно всё не очень хорошо получилось. Надо еще потренироваться.

## Восьмое действие

*Школа.*

АНАТОЛИЙ. Маш, привет.

МАША. Привет, Толя, как краски? Подошли?

АНАТОЛИЙ. Да, они просто идеальные для моей работы, только вот…

МАША. Только вот, что?

АНАТОЛИЙ. Только вот у меня с рисованием небольшие проблемы. Ну как небольшие, хорошие такие проблемы.

МАША. А с чем именно? Цвета не получаются или, может, с тенями проблема?

АНАТОЛИЙ. Да нет, цвета хорошо получаются. У меня беда с образами, не получается нарисовать то, что хочу. Вот рисую я коня, а получается собака сгорбленная. Или, к примеру, захотел я озеро нарисовать, кажется, будто просто синий круг.

МАША. Ничего, с опытом всё придёт, но не без знаний. Вот, держи, это мои старые записи по художке. Там есть некоторые объяснения и мои заметки. Думаю, это тебе пригодится.

АНАТОЛИЙ. Маш, ты ж моё спасение!

МАША. Ой, да ладно тебе. Я ж даже ничему тебя не научила.

АНАТОЛИЙ. Важно не то, что ты меня не научила, а то, что ты мне помогаешь. Я ценю твою поддержку, правда. Я не знаю никого, кто еще бы мог мне помочь с моей проблемой.

МАША. Забавный ты — сейчас художников, как грязи, а помочь могу лишь я одна.

АНАТОЛИЙ. Тем не менее, из всех помогаешь мне только ты. И я ценю это выше каких-либо знаний о живописи. Ведь, понимаешь, знаниями владеют многие, пользуются ими десятки, а вот помогают в их получении — единицы.

МАША. Пошли уже на урок, сегодня новая тема.

АНАТОЛИЙ. И с каких пор тебя так волнует математика?

МАША. С тех самых, когда не пройденный материал начала в два ночи учить, чтоб двойку утром не получить.

АНАТОЛИЙ. Ну, тогда да, стоит поторопиться.

## Девятое действие

*Комната Анатолия.*

АНАТОЛИЙ. Та-ак, почти готово… Сейчас мы подправим гриву… И… Готово.

*Телефонный звонок.*

АНАТОЛИЙ. Да.

РОМА. Алло. Я видел работы, которые ты выложил.

АНАТОЛИЙ. Да, это просто кошмар, я знаю. Я как раз сейчас переделал одну работу. Выглядит приятнее, но это лучше у тебя уточнить.

РОМА. Нет, я по поводу того, что стиль у тебя прикольный. Да, результат немного неаккуратный, но интересный.

АНАТОЛИЙ. Ты погоди, я тебе фото новой иллюстрации отправлю, оценишь.

РОМА. То есть, мне позже перезвонить?

АНАТОЛИЙ. Да, вечером можешь позвонить или написать. А я пока её в группу выложу, может, на этот раз людям понравится.

РОМА. Толь, не гонись ты за всеобщим признанием, найди своего зрителя и работай с ним. Пойми, что не всем на свете нравится татарская культура, как не всем на свете нравятся «Чародеи». Надо это просто принять, я так думаю.

АНАТОЛИЙ. Да, Ром, ты прав в этом, но со своими желаниями не поспоришь.

РОМА. Ты сам хозяин своих желаний, Толя, ты должен реализовывать себя так, как ты того хочешь, а не так, как это принято в нашем обществе.

АНАТОЛИЙ. Возможно, мне и правда стоит принять эту простую истину. Всем на свете я не понравлюсь. Тогда мне остаётся только одно — полюбить своё дело и свои работы, чтобы стать настоящим художником и найти свою публику.

РОМА. Вот это настрой. Ладно, мне конспект писать еще. Я вечером перезвоню.

АНАТОЛИЙ. Давай, до вечера тогда.

РОМА. До вечера.

АНАТОЛИЙ. Так, ладно. Я работал над этой картой очень долго, и теперь остаётся лишь одно — решиться выложить её на всеобщее обозрение. А вдруг опять. Вдруг они опять её не оценят? Не беда — сделаю новую. А если опять не понравится? Нравится-не нравится, какая разница, ты же даже не попробовал, так что бери себя в руки и отправляй эту фотографию! Да!

КОММЕНТАТОР 1. Посмотрите! Опять этот «художник», и опять со своей мазнёй.

КОММЕНТАТОР 3. Ручки еще не доросли, а он уже новые карты в пустую переводит.

КОММЕНТАТОР 2. Знаете, а мне нравится. Есть в этой работе что-то такое, необычное. Я раньше не видел таких коней на картах «Чародеев», и они мне нравятся. Пока не понимаю, чем именно, но чем-то зацепило.

АНАТОЛИЙ. Неужели, тебе правда нравится моя иллюстрация?

КОММЕНТАТОР 2. Да, и я был бы рад увидеть еще работы в этом стиле. Это же татарская культура и история, как я понял. Очень интересно смотрится в контексте нашей игры.

АНАТОЛИЙ. Спасибо большое! Я буду усердно стараться над качеством моих работ, и делать новые иллюстрации, пока не закончатся сюжеты татарской культуры.

МАМА. Толя! Звонили из школы, просили, чтоб ты завтра спустился к директору, ему нужно с тобой поговорить по поводу школьных олимпиад.

АНАТОЛИЙ. Опять? Я итак до этого столько лет ходил, нет, чтоб кого другого позвать.

МАМА. Ну, ты сходи, поговори, но мне кажется, что тебе всё-таки лучше заняться олимпиадами. Легче в ВУЗ поступишь, может, стипендию выше платить будут.

АНАТОЛИЙ. Стипендия это хорошо…

МАМА. Ну, вот и всё. Сходи, поговори, может, оценки тебе за это поправят.

АНАТОЛИЙ. Ладно, мама, схожу я. Кстати, что сегодня на ужин?

МАМА. А ты уже проголодался?

АНАТОЛИЙ. Да.

МАМА. Пойдём на кухню, я пельменей сварю.

## Десятое действие

*Школа, кабинет директора.*

ДИРЕКТОР. А, Анатолий. Проходи, присаживайся.

АНАТОЛИЙ. Здравствуйте.

ДИРЕКТОР. Думаю, не надо тебе объяснять, зачем я тебя пригласил.

АНАТОЛИЙ. Я догадываюсь, но хотелось бы услышать это от вас.

ДИРЕКТОР. Это по поводу олимпиады. По математике.

АНАТОЛИЙ *(себе под нос)*. Я и не сомневался.

ДИРЕКТОР. Ты же понимаешь, что это твой последний год в школе, дальше ВУЗ, поэтому это твой последний шанс выложиться на полную на этой олимпиаде.

АНАТОЛИЙ. По математике?

ДИРЕКТОР. Да, по математике. Поэтому я, от лица школы, прошу отказаться от остальной активности и углубиться в математику. От других предметов мы тебя, соответственно, освобождаем.

АНАТОЛИЙ. Как… отказаться?

ДИРЕКТОР. У тебя есть потенциал в этой сфере, а олимпиада — это прекрасный шанс зарекомендовать себя в лучшие ВУЗы страны. Но для этого придётся убрать всё лишнее, всё, что отвлекает.

АНАТОЛИЙ. Но…

ДИРЕКТОР. Давай, Анатолий, мы всей школой надеемся на тебя. Хорошо?

АНАТОЛИЙ. Хо-хорошо…

ДИРЕКТОР. Ну, всё, не буду тебя больше держать тут, тебе пора на урок. Но с завтрашнего дня ты усиленно начинаешь заниматься математикой.

АНАТОЛИЙ. До свидания.

ДИРЕКТОР. До свидания.

## Одиннадцатое действие

*Комната с потёртыми стенами. АНАТОЛИЙ с растрепанными волосами и густой, но короткой бородой сидит за рабочим столом, одежда его запачкана красками, в руке кисть. На столе стоит кружка для кофе, но в ней разведены краски. На стареньком ноутбуке изображение Су анасы. На фоне куклы-комментаторы что-то обсуждают, не скупясь на крепкие выражения.*

*В комнату заходит МАША, одетая в домашнюю футболку, на удивление чистую, и трико до пола. Она обнимает его за шею и звонко целует в колючую щёку. АНАТОЛИЙ откладывает кисть, показывает своё новое творение МАШЕ, она улыбается. Кладёт голову на его плечо, АНАТОЛИЙ берёт её ладони в свои.*

*Исмаилова Мадина Рафаилевна*

# КАК ПОДСКАЗЫВАЕТ СЕРДЦЕ!

*Действующие лица:*

АЛСУ РАИСОВНА, учитель

ИБРАГИМ, новый ученик.

МИЛЯУША, САЛАВАТ, АЙЗИЛЯ, ученики 4 «Б» класса.

АЛЬФИЯ, сестра ИБРАГИМА.

Действие происходит в татарской гимназии № 2 имени Мулланура Вахитова, в городе Набережные Челны.

## Первое действие

*В кабинет 4 «Б» класса входит высокий мальчик с большими карими глазами, длинными ресницами, кучерявыми волосами.*
*АЛСУ РАИСОВНА, классный руководитель, встречает новенького.*

АЛСУ РАИСОВНА. Дети, познакомьтесь, наш новый ученик, Ибрагим.

МИЛЯУША. Какой смешной! Его нам только не хватало!

АЛСУ РАИСОВНА. Миляуша, я вам ни раз уже говорила, что, во-первых, перебивать — это некрасиво и невежливо, а во-вторых, надо с уважением относиться к людям. Не делайте другим того, чего вы не желаете себе… Продолжим наше знакомство. Ибрагим, расскажите, пожалуйста, о себе. Нам очень интересно.

ИБРАГИМ. Здравствуйте, меня зовут Ибрагим. Родился я в деревне Хузеево, учился в соседнем поселке. Люблю свой дом, своих близких, природу своего родного края.

САЛАВАТ. А зачем ты сюда приехал, если в деревне тебе так нравится?

АЛСУ РАИСОВНА. Салават, Миляуше мы уже сделали замечание, пусть наш новенький ученик продолжит свой рассказ. Ибрагим, есть ли у вас любимые занятия?

ИБРАГИМ. Я люблю гулять со своей собакой по горам и по полям. Когда мне весело или грустно, я играю на курае.

ВСЕ. А что такое курай?

АЛСУ РАИСОВНА. Курай — это татарский народный инструмент, чем-то напоминает флейту. На следующей неделе в школе состоится праздник талантов. Ибрагим, не хотите ли поучаствовать, сыграть на концерте?

ИБРАГИМ. Да, конечно, с радостью!

АЙЗИЛЯ. Ибрагим, расскажи, пожалуйста, про своего питомца. У меня тоже есть небольшая собачка, ее зовут Алиса.

ИБРАГИМ. Мою собаку зовут Актырнак. Он очень добрый и верный. Папа нашел его щенком в поле, пожалел и принес домой. Теперь Актырнак — мой лучший друг.

АЙЗИЛЯ. А почему он лучший друг?

ИБРАГИМ. Актырнак ни раз помогал мне в беде. Как-то, когда мы гуляли, он преградил мне дорогу и не давал сделать ни шагу. Вдалеке я увидел огромную лису.

АЙЗИЛЯ. Интересно, какой молодец!

ИБРАГИМ. Во второй раз Актырнак вытащил меня из оврага зимой, тянул изо всех сил.

## Второе действие

*После уроков ИБРАГИМ возвращается домой.*

АЛЬФИЯ. Привет, Ибрагим! Как дела? Как в школе? Почему ты такой грустный?

ИБРАГИМ. Апам, все хорошо. Одноклассники и учительница мне понравились, школа тоже замечательная. Я рассказывал о себе, на концерте сыграю на курае. Мне грустно, так как скучаю по дому, папе и маме, по Актырнаку. Я не понимаю, почему мои одноклассники очень мало разговаривают на своем родном языке, не знают, что такое курай, кто-то даже посмеялся, что я из деревни.

АЛЬФИЯ. Ибрагим, все будет хорошо, ты привыкнешь к школе, одноклассники полюбят тебя, ведь ты очень добрый и отзывчивый мальчик. Ты своим примером можешь показать, что нужно помнить свой родной язык, знать свои праздники, песни, стихи. Все у тебя получится! Делай так, как подсказывает твое сердце.

## Третье действие

*На концерте ИБРАГИМ исполнил татарскую народную мелодию «Умырзая», что означает «Подснежник». Когда ИБРАГИМ начал играть, весь зал замер. Он исполнял с душой, музыка окутала все вокруг. Это было завораживающе.*

*После концерта дети собрались в классе и окружили ИБРАГИМА.*

АЙЗИЛЯ. Ибрагим, мне очень понравилось, как ты играл.

САЛАВАТ. Да, было здорово, Ибрагим! Ты сможешь научить меня тоже?

ИБРАГИМ. Спасибо, Айзиля. Да, Салават, с радостью покажу и научу.

АЛСУ РАИСОВНА. Мои дорогие ребята, спасибо за этот великолепный праздник! Отдельное спасибо хотела бы сказать Ибрагиму, твое исполнение было восхитительным. Все слушали, затаив дыхание. Я сама прослезилась, вспомнила свое детство, родные края, своих папу и маму, которых уже нет. Дорогие дети, учитесь, достигайте своих целей, познавайте новое. Не забывайте свой дом, свой край, свой добрый родной язык!

*Бәширова Нурия Илдус кызы*

# КӘРӘЗЛЕ-БАЛЛЫ ТОРМЫШ

Балалар өчен музыкаль пьеса

*Катнашалар:*

АЙРАТ, 5 сыйныф укучысы. “Р” хәрефен әйтә алмый, сакау.

МАРАТ, ӘНИСӘ, АЛСУ, Айратның сыйныфташлары.

СЕРЛЕ ТАВЫШ, 75 яшьлек авыл карты.

*Яз. Авыл урамы. Кошлар сайрый. Букчасын җирдән сөйрәп, телефонга текәлгән* АЙРАТ *җыр көйләп бара.*

Вайфай, диләл вай-фай диләл,
Менә сиңа гәләмәт.
Мәктәпкә балган чагында,
Соңга калам, әкәмәт!

АЙРАТНЫҢ *артыннан ук,* МАРАТ *посып кына килә дә, колак төбендә ачы итеп сызгырып җибәрә.*

АЙРАТ. Кулкыттың бит, җүләл-л-л... *(Тотлыгып соңгы сүзен әйләндереп әйтә алмый азаплана.)*

МАРАТ *(көлеп)*. Бигрәк куркак икәнсең, алай-болай запас ыштан да кирәк түгелме соң? Мә, биреп торам! Хи-хи-хи...

АЙРАТ. Баллы-юклы шаялулалыңны ташла әле син, блат. Минем бит монда эшем каты, понимаешь!

МАРАТ. Күрәм инде, күрәм. Шул телефоныңа кендегең белән береккәнсең. Күзләрең менә шулай икесе ике якка караган *(Айраттан көлеп күзләрен чалшайтып күрсәтә)*.

АЙРАТ. Кит моннан, итәгатьсез! Бик беләсең килсә, мин үскәч леспубликабызның, юк, юк илебезнең зул түләсе — Плезиденты буласы кеше!

МАРАТ *(көлемсерәп)*. Синме? кит булмаганны! Син малай, башта Президент сүзен дөрес итеп әйтергә өйрән, аннары сөйләшербез, яме.

АЙРАТ. Менә ышанмасаң минем голоскопка күз сал. Угезбозау йолдызлыгы астында туган кешеләл, зул шәхес булалал, дигәннәл.

МАРАТ. Чыннан да! *(Айрат горурлык хисе белән муенынндагы галстугын рәтли башлый.)* Карап, карап торам да, син чып-чын Үгезбозау!

АЙРАТ *еларга җитешә. Шул вакыт сыйнфташ кызлары да аларны куып тота.*

ӘНИСӘ. Айрат, нәрсә булды? Әллә чебен тешләдеме үзеңне? Бу турыда телефонда ни дигәннәр икән, тиз генә карап ал әле... *(Кызлар бер-берсенә төртеп, көлешәләр.)*

МАРАТ. Булачак Президентыбызның кәефе кырылды! Тиз арада бу проблеманы хәл итәргә кирәк, кызлар, булышасызмы миңа?

АЛСУ. Айрат, куй әле шул телефоныңны! Чистый, күңелемне болгата башлады бу телефоның, билләхи! Тәнәфестә дә, дәрес вакытында да шул... Чын әйтәм, болай дәвам итсә, син аңгыраеп бетәчәксең...

МАРАТ. Әйе, әйе. Нәкъ угезбозау кебек!

*АЙРАТ үпкәләп МАРАТНЫ куа башлый.*

АЛСУ. Әйдә бала-чагаланмагыз әле. Хәтерлисезме, укытучы апабыз Су буендагы чишмә йортында бөтен хыяллар да чынга аша, дип сөйләгән иде. Әйдәгез шунда барабыз! Айратны шушы телефон зәхмәтеннән коткарабыз!

МАРАТ. Ооо, бик яхшы фикер! Әйдәгез, "плизидент галиҗәнәпләле", рәхим итегез! *(Сыгыла-сыгыла Айратка юл бирә)*

АЙРАТ. Хәзел, ашыкмагыз! Бу тулыда интелнетта ни дигәннәл икән, калап-калыйм әле. Мин ылым-шылым әкияткә ышана толган кешеләлдән түгел, понимаешь! Тәк... *(Телефонына текәлә.)*

ӘНИСӘ. Әй, вундеркинд! Куй шул телефоныңны, киттек әйдә...

*Күңелле музыка башлана. АЙРАТ арттан мыгырдана-мыгырдана сөйрәлеп бара. Дуслары аны этә-төртә алып баралар.*

ӘНИСӘ.

Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә.
Укучылар дәрестән качкан,
Эх, бер җырлыйсым килә.

МАРАТ.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр икеләләр.
Айрат кебек «зур» түрәләр,
Илне кая илтәрләр?

*Серле тавышлар ишетелә башлый. Кисәк кенә козгын кычкырып җибәрә. АЙРАТ куркуыннан җиргә сузылып ята.*

А Л С У. Әстәгыфируллах! Нинди әкәмәт бу?

М А Р А Т. Күрмисеңмени, әфәндебезнең йөрәгенә сердце була язды. Беренче ярдәм күрсәтергә кирәк. Кая, Әнисә, әйдә, син уку алдынгысы, шуңа күрә бу эшне сиңа тапшырабыз. Рәхим ит!

*Ә Н И С Ә югалып кала. А Й Р А Т Н Ы Ң янына чүгәләп, сулавын тикшермәкче була. Колагын А Й Р А Т Н Ы Ң борын төбенә китерүгә, малай чәчрәп торып утыра.*

А Й Р А Т. Әй, нишлисең? Әллә үпмәкче буласың инде? *(Горурланып, галстугын рәтли башлый.)*

М А Р А Т. Каян белдең син аны, Айрат? Тучны үпмәкче иде шул... *(Эчен тотып кычкыра-кычкыра көлә башлый)*

Ә Н И С Ә. Ы-ы-ы, бик кирәгең бар иде, кишер яфрагы! Аңыңны җуеп егылдыңмы әллә дип торабыз, ярдәм итәсе идем.

А Й Р А Т. Юк-юк, белниемне дә җуймадым. Плосто, интелнетта кулкыныч әйбел күлсәң, сузылып ят та, үлгәнгә сабыш, дигәннәл. Менә бу теолияне тикшелә идем. Да, эшли икән! Менә сез ышандыгыз бит.

М А Р А Т. Ә-ә-ә, интернет әйткәч, дөрес әйтәдер инде. Спорить итеп булмас!

А Л С У. Күп сүз — чүп сүз, әйдәгез инде. Бер урында таптанып тормагыз, керик чишмә өенә.

*А Й Р А Т каушап кала. Бер адым алга атлый, икене артка. Шул арада ике кыз ике кулыннан култыклап алып керәләр. А Й Р А Т чытырдатып күзен йома. Кергәч, селкенергә дә куркып, урынында тораташ булып ката.*

А Л С У. Карагыз әле, нинди матурлык!

Ә Н И С Ә. Чыннан да! Ничә еллар шушы авылда яшәп, кергән юк иде. Бигрәк матур монда.

*Кызлар, кулларын юып, су эчәләр.*

М А Р А Т. Әй, Президент галиҗәнәпләре, кил син дә якынрак, теләкләреңне теләп, чишмә суыннан авыз ит, кем белә бит, бәлки синнән дә берәр ну-у-рмалный кеше чыгар.

А Й Р А Т. Каланґы бит монда! Сез нәлсә күләсез соң?

М А Р А Т. Әй, Аллаһ бәндәсе, ач күзеңне, дөнья бу. *(Марат Айратның кабыргасына китереп төртә. Тегесе чәчрәп китә.)*

А Й Р А Т. Күзне йомганны онытканмын икән бит, ниче бывает...

*А Л С У белән Ә Н И С Ә чишмә артыннан таушалып беткән иске түбәтәй күтәреп чыгалар.*

Ә Н И С Ә. Егетләр, егетләр, карагыз! Без нинди хәзинә таптык!

А Й Р А Т. Әй, нинди клад булсын ди бу, бу динозавллалдан калган белән шапкадыл инде.

М А Р А Т. *(кызларга күз кысып)* Айрат, бу бит чыннан да серле түбәтәй. Ул кешенең киләчәге турында барысын да сөйләп бирә, диләр. Әйдәгез, тикшереп карыйк.

*Ә Н И С Ә түбәтәйне башына киеп, күзен йома. Кисәк кенә җил исә, серле тавыш пәйдә була.*

СЕРЛЕ ТАВЫШ: Мин чыннан да серле түбәтәй! *(Балалар курка төшәләр. Бер-берсе артына сыешып тыңлауларын дәвам итәләр).* Син, сеңлем, күрәм, бик тырыш, җитез кыз икәнсең. Киләчәгең бик якты, укуыңда да зур уңышларга ирешерсең. Моның өчен нибары тырышып, белем алуыңны дәвам ит.

*М А Р А Т тиз генә түбәтәйне үзе алып кия.*

С Е Р Л Е Т А В Ы Ш. Ә син, энем, бик батыр, тапкыр сүзле! Кая барсаң да, юлыңда яхшы кешеләр генә очрап торыр, зур түрә булырсың *(Җөмләсен тәмамларга да өлгерми, Айрат Маратның башыннан түбәтәйне йолкып үзенә кия.)*

А Й Р А Т. Туктагыз, зул түлә мин булам! Яле, минем киләчәкне дә әйт әле…

С Е Р Л Е Т А В Ы Ш. Ә син, энем, күрүемчә, кәрәзле-баллы тормыш белән яшисең. Кулыңнан бу такта кисәге бөтенләй төшми икән. Димәк, синең уңышларың шушы аппаратыңнан ары узмаячак. *(Айрат бер телефонына, бер дусларына карап аптырап басып тора.)*

А Й Р А Т. Ә плезидент? *(Борынын тарта.)*

С Е Р Л Е Т А В Ы Ш. Зур түрә дәрәҗәсенә ирешәм дисәң, тырышып укырга кирәк. Яшьтәшләрең белән күзгә-күз карашып аралашырга кирәк.

А Л С У. Ә миңа? Минем дә беләсем килә. Мин җырчы буламмы? *(Түбәтәйне А Й Р А Т Т А Н колагы белән йолкып ала.)*

А Й Р А Т. Син нәлсә?! Колагымны өзәсең бит *(Ике колагын ышкып, мөгери башлый.)*

А Л С У. Әле күп шыңшып торсаң, точны өзеп алам да, кулыңа тоттырам, билләхи.

С Е Р Л Е Т А В Ы Ш. Сеңелем, җырчы булуын-булырсың, чит төбәкләрдә дә танылырсың, әмма башка кешеләргә карата ихтирам һәм хөрмәт кебек төшенчәләрнең барлыгын онытма. Бары шул чакта гына син кешелеклелек сыйфатларын саклап кала алырсың.

*Балалар бер-берсенә карашалар. Шулчак кабат козгын кычкырган тавыш ишетелә. А Й Р А Т куркуыннан телефонын сүндереп кесәсенә шудыра.*

МАРАТ. Рәхмәт сиңа, серле тавыш. Без синең киңәшләреңне истә тотарбыз!

АЛСУ. Һәрчак гадел булырбыз!

ӘНИСӘ. Бер-беребезне хөрмәт итеп яшәрбез!

АЙРАТ. Ә миңа Президент булу өчен телефонымны читкә куеп укырга туры килер!

АЛСУ. Тукта әле, тукта! Айрат, син "Р" хәрефен әйтә башладың түгелме соң?!

МАРАТ. Кая әле, кая... Кабатла, Пр-р-резидент!

АЙРАТ. Пр-р-резидент! Чынлап та, "Р-р-р"... Менә могҗиза! *(Җырлап җибәрә.)*

Карга әйтә кар-кар,
Нәни чеби бар-бар.
Берсен генә алыр идем,
Сакчылары бар-р, бар-р-р...

ӘНИСӘ. Артык көчәнмә Айрат, я тәһарәтеңне бозарсың *(Кызлар көлешеп алалар.)*

МАРАТ. Иң мөһиме, "Р-р-р" хәрефеңне онытма!

ӘНИСӘ *(алга йөгереп килә дә, кычкырып җибәрә)*. Кызлар, егетләр! Без бит математика дәресенә соңга калабыз!

БЕРГӘ: Киттек!

*Күңелле музыка башлана.*

Интернетсыз яшәп булмый,
Бүгенге тормышларда.
Президент булам дисәң,
Укы син тырышыплар да!

Укуда да син сынатма,
Тормышта да югалма.
Дусларыңны да онытма,
Туры юлдан тайпылма!

УКУЧЫЛАР ЙӨГЕРЕП ЧЫГАЛАР. Чишмә буенда ял итәргә дип күләгәгә кергән бер авыл карты, түбәтәен баш очына элеп, сәхнә түренә уза.

КАРТ. Балаларның самимилеге — зур бәхет! Алар бит үзләре могҗиза тудырып, үзләре үк шуңа ышанучы беркатлы сабыйлар! Безнең дәвер узган,

киләчәгебез балаларыбыз кулында. Шуңа күрә дә, киңәшләребезне, үгет-нәсихәтләребезне тыңласалар иде. Шулай булса, киләчәгебез ышанычлы кулларда булыр. *(Төенчеген аркасына асып, талгын көйгә карт күздән югала.)*

*Әхмәтҗанова Алинә Наил кызы*

# КАЗАН КЫЗЫ ГӨЛИЯ

*Катнашалар:*

ГӨЛИЯ, авыл кызы, 9 нчы сыйныф укучысы.

НУРИЯ, Гөлиянең әнисе.

ФИРГАТЬ, ГӨЛИЯНЕҢ әтисе.

ГӨЛБИКӘ, ГӨЛИЯНЕҢ әбисе.

САША, ГӨЛИЯНЕҢ кияве.

ГАРИФУЛЛА, күрше.

## I пәрдә

### Беренче күренеш

*Өйгә атылып ГӨЛИЯ керә, әнисен эзли. Өй буйлап чабып йөри. Бүлмәдән ГӨЛБИКӘ әби чыга.*

ГӨЛИЯ. Әби, әби! Әни кайда?

ГӨЛБИКӘ. Йә, нәрсә булды? Тынычлан! Әниеңнең эше бар әле. Миңа гына әйт.

ГӨЛИЯ *(көчкә тынычланып)*. Тыныч мин. Чык әле, чык ишегалдына!

ГӨЛБИКӘ. Монда да бик уңайлы әле. Әллә аю биетәләрме?

ГӨЛИЯ. Юк ла. Бозау таналаган! Әй, тьфу, тана бозаулаган.

ГӨЛБИКӘ. Әлләме?! Кайчан?

ГӨЛИЯ. Бүгендер инде, кичә бозавы күренми иде.

ГӨЛБИКӘ. Анысын син миңа әйтмә инде, әниеңә әйт! Нурия! Ну-ри-ия-я!!! Гомергә өйдә утырмас шушы! Кая китеп югалды микән инде? Нурия дим!

ГӨЛИЯ. Әби, әби, утырып кына тор! Мин аны үзем эзләп керәм!

*ГӨЛИЯ әнисен эзләп чыгып китә. Әбисе шунда утырып кала.*

ГӨЛБИКӘ. Әй, шушы кызны! Үзе нинди кечкенә, үзе чикерткә кебек тагын гел сикереп йөрүдән башы чыкмый. Рәтле-ниле сүзе дә юк үзенең. Авызын ачып сүз әйтә башласа, ботка ясап бетерә. Үзе тагын быел имтиханнарын биргәч, табиб булам ди. Әй нәрсә чыгар бу кыздан! Казанга китмәкче була! Авылда калса

ни булган инде! Акча юк, дип белә микән? Әнә күрше Саниянең кызы фермада сыер савучы булып эшли, аена биш мең ала...

*ГӨЛИЯ яңадан чабып керә. Әбисенең сүзләрен ишетеп ала.*

ГӨЛИЯ. Әби, син әле мондамыни? Тагын мине күрше Алисә белән чагыштырасыңмы? Ул бит укый алмаганга фермага керде.

ГӨЛБИКӘ. Ә менә безнең вакытта...

ГӨЛИЯ. Бә-бә-бә! Лә-лә-лә! Сезнең вакытта, безнең вакытта... Тәмам туйдым! Кайчан имтиханнарымны бирәм дә, укырга китәм инде? Ә Казанда-а-а...

*Әйтеп бетерергә өлгерми, әнисе килеп керә.*

НУРИЯ. Әй, Казан кызы! Төш бирегә! Бар, тавыкларыңны ашат! Һе, Казанда, имеш! Казан турында уйлаганчы, бәрәңге бакчасы турында уйла син!

ГӨЛИЯ. Ярар! Шул тавыкларыгыз белән!

*Кич җитә. ГАИЛӘ өйдә җыела, тик әтисе кайтып җитмәгән була.*

ГӨЛИЯ. Әни, әти кайтмадымыни әле?

НУРИЯ. Юк шул әле. Озакламас кайтыр инде. Нишлисең әтиең белән?

ГӨЛИЯ *(тәрәзәгә карап)*. Юк, болай гына. Әнә бит ул! Кайткан бит!

НУРИЯ. Ярар, кайтса кайта инде. Миңа нишләргә кушасың?

ГӨЛИЯ. Юк, юк. берни дә түгел. Сезнең белән сөйләшеп торганчы, имтиханнарыма әзерләним әле.

НУРИЯ. Бар-бар.

*Үз бүлмәсенә кереп китә. Озак узмый, әнисе аны аш бүлмәсенә чакыра.*

НУРИЯ. Гөлия! Гөлия, дим!

ГӨЛИЯ. Угол АВС равен 54° булгач... Йә Аллам, минсез тора да алмыйлар инде! Нәрсә булды микән инде тагын? Әйе-е, ә-ә-әү!?

НУРИЯ. Килеп кит әле! Сөйләшәсе сүз бар!

ГӨЛИЯ. Хәзер. *(Егыла яза.)*

НУРИЯ. Нишләдең инде тагын? Әзрәк карап йөр инде! Күзең үз урынындадыр бит!

ГӨЛИЯ. Булгалый торган хәл.

НУРИЯ. Синең белән бигрәк еш.

ГӨЛИЯ. Ярый, нәрсә турында сөйләшәсе идегез сез? Тыңлыйм.

НУРИЯ. Кызым, тугызны бетергәч, китәм дисең инде, име? Ә кая китмәкче буласың? Табибкамы? Без уйладык-уйладык та, сиңа ул һөнәр килешми диган фикергә килдек.

ГӨЛИЯ. Нәрсә?! Ничек?! Табиб булу минем иң зур хыялым бит!

НУРИЯ. Беләбез, кызым, тик синең бу характерың белән…

ГӨЛИЯ. Аңлашылды барысы да. Гафу итегез, тик бу юлы мин үземнең хыялым артымнан барачакмын! Һәм миңа беркем дә киртә була алмас!

ФИРГАТЬ. Кара аны, син үзең бу юлны сайладың. Әгәр килеп чыкмаса берни дә, безне гаепләмә! Килештекме?

ГӨЛИЯ. Килештек. *(Ачу белән бүлмәсенә кереп китә.)*

НУРИЯ. Карале, син аның белән артык кыланып ташламадыңмы?

ФИРГАТЬ. Юк ла. Барысы да яхшы булыр, менә күрерсең!

## Икенче күренеш

*ГӨЛИЯ көзге кырыенда боргалана.*

НУРИЯ. Йә, кызым, имтиханнарыңны ничек бирдең, әйдә сөйлә инде.

ГӨЛИЯ. Әни, минем барысыннан да «отлично» билгеләре генә.

НУРИЯ. И-и-и, кызым, булдыргансың. Туктале, кая җыендың соң син болай?

ГӨЛИЯ. Дусларым белән очрашып, дискәтүккә бармакчы идек.

НУРИЯ. Ярар, алайса. Бар. Озак йөрмә.

ГӨЛИЯ. Ярар.

*Йөгерә-йөгерә чыгып китә. ФИРГАТ керә.*

НУРИЯ. Карале, без чыннан да дөрес эшләдек микән? Артыгын кыланып ташламадык микән?

ФИРГАТЬ. Тынычлан инде, барысы да яхшы булыр дидем бит.

*Көтмәгәндә әбиләре килеп чыга.*

ГӨЛБИКӘ. Нәрсә булды монда? Нишләп җыелып торасыз? Теге күрше Гарифулла кергән, хатынга алам ди мине.

НУРИЯ. Әни, хыялланып йөрмә инде. Бар, кереп ят.

ГӨЛБИКӘ. Бабагыз булса… Күрсәтә иде ул сезгә “бар, кереп ят”ыгызны!

НУРИЯ. Әни-и-и…

ГӨЛБИКӘ. Ярар, кирәгем чыгар әле!

НУРИЯ. Үпкәләмә инде!

ГӨЛБИКӘ. Үпкә ашат башта!

НУРИЯ. Әгәр шаярмый калса, әни булмас…

ГӨЛИБИКӘ *(кире борылып)*. Кызым, чәй генә ясап кертерсең әле. Рәхмәт.

Н У Р И Я. Ярый, әни. *(Гөлбикә әби бүлмәгә кереп китә.)* Уф, я Аллам… үтерә бу. Шунда чыккан килеш эчеп кереп китсә инде… *(Фиргатьнең дә, чәй ясап, икенче бүлмәгә кереп китүен күреп ала).* Тукта, син нишлисең? Шунда гына утырып эч инде! Ой, Аллам. Кил әле монда!

*Г Ө Л Б И К Ә әбигә чәен кертеп бирә.*

Н У Р И Я. Менә, әни, чәең. Әстәгафирулла, нәрсә бу?

Г Ө Л Б И К Ә. Кая Гарифулла?

Н У Р И Я. Өендә. Хәзер килә, ди.

Г Ө Л Б И К Ә. Чәеңне кайнарлый тор, алайса.

Н У Р И Я. Ярар, киттем.

Г Ө Л Б И К Ә. Бар-бар. Рәхмәт.

Н У Р И Я. Ярый, кирәк әйбер булса, чакырырсың.

Г Ө Л Б И К Ә. Нинди чакырырсың? Киявең булсын Әхмәт диген.

Н У Р И Я. Әни! Нинди кияу ди инде бу яшьтә?!

Г Ө Л Б И К Ә. Ә син әйт!

Н У Р И Я. Киявең булсың Әхмәт! Күңелең булдымы?

Г Ө Л Б И К Ә. Булды, миңа Гарифулла да ярый иде!

Н У Р И Я. Һич ярап булмас сиңа! *(Чыгып китә.)* Тыңла әле, нишләтик соң бу Гөлияне? Китсенме соң әллә шул Казанына?

Ф И Р Г А Т Ь. Барсын. Дөнья күрсен. Без менә авылдан чыгып китә алмадык. Ул, ичмасам, шәһәр күрсен.

*Яңадан Г Ө Л Б И К Ә әби чыгып җитә.*

Г Ө Л Б И К Ә. Кая әле Гарифулла? Күренмиме?

Н У Р И Я. Әстәгы… юк әле, юк… Бар йоклап ал, әни… Арыгансыңдыр.

## II пәрдә

### Беренче күренеш

*Г Ө Л И Я Казанда колледжны, университетны тәмамлап чыга.*
*Хәзер аспирантурада укый. Г Ө Л И Я Сашаны беренче мәртәбә авылына алып кайта.*

Н У Р И Я. О-о-о, кемне күрәм, кайттыңмы, кызым?

Г Ө Л И Я. Әйе, әни. Иртәгә китәрмен дә бугай инде.

Н У Р И Я. Ничек алай инде ул? Ю-у-ук, җибәрәмме соң сине, берәр мунча кертмичә! Тагын нәрсә?!

Г Ө Л И Я. Минем Себер якларына барып кайтасы бар эш буенча.

Н У Р И Я. Әйе шул. Хәзер бит инде син безнең Казан кызы. Әйдә, әйдәгез, өйгә керик, монда басып тормыйк.

*Капкадан Ф И Р Г А Т Ь чыга Г Ө Л И Я Н Е кочаклап ала, күзе белән кияүләрен эзләвен дәвам итә.*

Ф И Р Г А Т Ь. Менә би-и-ит, бигрәк тиз кайтып җиттегез сез! Кияү кая соң безнең?

С А Ш А. Здоро… ой, исәнмесез, бабай.

Ф И Р Г А Т Ь. Исәнме-е. Ничек кайтып җиттегез?

С А Ш А. Дорогаларыгыз начар. Ә болай все нормально. Рәхмәт! Гулечка сезне гел мактап тора инде. Августларга, то есть бер айдан свадьба мәҗлесе ясарга уйлыйбыз.

Г Ө Л И Я. Әйе, киләсездер бит?

Н У Р И Я. Әлбәттә инде, кызым.

С А Ш А. Бабай, рыбалкага бармыйбызмы?

Ф И Р Г А Т Ь. Барырбыз, барырбыз.

*Әнисе кызын читкә алып китеп, көлеп кенә сөли башлый.*

Н У Р И Я. Бу Сашаңнан тәки кеше ясап җибәрәсе булыр әле. Үзе ни татар, ни рус түгел.

Г Ө Л И Я. Татар ул әни, керәшен татары.

Н У Р И Я. Беләм анысын. Шуңа күрә әйтәм дә. Шәһәр татарлары.

Г Ө Л И Я. Әни инде.

## Икенче күренеш

Г Ө Л И Я. Әни, кайттыңдамыни инде эштән?

Н У Р И Я. Әйе инде, ә син ник шулай иртәләдең әле?

Г Ө Л И Я. Теге элекке сукмаклар буйлап чишмәләрне урап мендем. Авыл бер дә үзгәрмәгән икән. Биш елда ничек бар шулай калган. Су да алып мендем.

Н У Р И Я. Бигрәкләр дә уңган инде үзең.

*Г Ө Л Б И К Ә әби торып чыга.*

Г Ө Л Б И К Ә. Кем бу, Нурия?

Г Ө Л И Я. Әби, әллә танымыйсың инде?

Г Ө Л Б И К Ә. Әби?! Минем бит Гөлия кызым гына бар, ә син кем тагын? Син минем Гөлиям түгел. Минем Гөлиям зур врач. Ә син нindидер жулик… Бездә нишләп йөри…

Н У Р И Я. Әни, тынычлан. Гөлия ул, Гөлия.

Г Ө Л Б И К Ә. Әлләме? Кызым минем, сабыем, ничек үскән!

*Кияү уяна.*

С А Ш А. Хәерле иртәләр!

Н У Р И Я. Менә бит кияү дә уянган! Йә, ничек, кияү, йоклап булдымы?

С А Ш А. Әйе, но иртә белән где-то алтыларда анда сыерларны кудылар кая-дыр. Нәрсә иде ул?

Н У Р И Я. Ә-ә-ә. Көтү киткәндер.

С А Ш А. Разве көтүне шулай куалар?

Н У Р И Я. Әйе инде. Ярар, ияләшерсең әле!

С А Ш А. Әби, мин елгага төшеп меним әле!

Н У Р И Я. Бар, улым, бар!

*Өйгә* ***ФИРГАТЬ*** *кайтып керә.*

Ф И Р Г А Т Ь. Менә бит безнең кызыбыз да уянган. Кечкенә кире кызыбыз!

Г Ө Л И Я. Кайвакыт кирелек кешене бәхетле дә итә бит!

*Гарипова Ләйсән Наил кызы*

# ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ

*Катнашалар:*

ФӘЙЗУЛЛА, 65 яшьләрдә, гаилә башлыгы.

МӘРЬЯМ, 60 яшьләрендә, ФӘЙЗУЛЛАНЫН хатыны.

МИҢЗИФА, киленнәре, 30 яшьләрендә, колхозчы.

ХАФИЗ, МИҢЗИФАНЫҢ ире, яңа кайткан солдат.

ЗАРИФ, аларның улы, 7–8 яшьләрендә.

МАРИЯ, 60 яшьләрендә, күрше хатыны.

ӘСМАБИКӘ, хезмәтчесенә кияүгә чыгып, авылдан куылмыйчы калган кулак кызы. Ире, ФӘЙЗУЛЛАНЫң туганы.

ЛЮБА, колхозчы кыз.

ВӘЛИ, колхозчы егет.

КАДЫЙР БАБАЙ, колхоз активисты.

*Вакыйга, 1945 елның июль ае, печән өстендә, Казан арты авылларының берсендә бара.*

## Беренче күренеш

*Гади генә, пөхтә итеп, авылча бизәлгән өй эче. ФӘЙЗУЛЛА карт сәкегә утырган, гармун тарта. Янында ЗАРИФ уйнап йөри. Гармун уйнавыннан туктап, башын ия. Аннан соң, кинәт кенә башын горур күтәреп, үз алдына сөйләнә башлый.*

ФӘЙЗУЛЛА. Их, яшь чагым булса! Гармунга кушылып, үзем дә җырлап җибәрер идем әле. Йөрәкнең дәрте, беләкнең егәре бетеп бара ла… Их, сугыш әфәте, сугыш хәсрәте! Шул гына гаепле барсына да. Тиз генә картлыкка бирешер идеммени әле мин?! Әйе-е, ике улымны озаттым бит сугышка. Бер-бер артлы! Иң олысы Габделхаким — Мәскәү астындагы сугышта батырларча һәлак булды. Икенче улым — төпчегемнең өч ай хәбәре юк. “Тиздән җиңәбез!” — дип язган хаты килде дә, шуннан бирле бер хәбәр юк. Исәнме-юкмы, берни белмибез.

*Гармунны яратып сыпырып куя.*

ЗАРИФ. Бабай, бабай, әти кайчан кайтыр икән ул, ә? Немесләрне атып бетерделәр бит инде.

ФӘЙЗУЛЛА. Кайтыр, балам, кайтыр, Алла боерса. Озакламас инде, кайтыр төсле тоела күңелемә...

ЗАРИФ. Бабай, бер җыр җырлыйм әле үзеңә.

Кара тавык күкәй сала
Кәрҗинкәсен тутырып.
Минем әти кайтыр әле
Машинага утырып.

ФӘЙЗУЛЛА. Менә булдырдың улым, менә рәхмәт! *(Җилкәсеннән сөеп.)* Кара инде бу баланы, күз тимәсен, сөбханалла, булдыра бит! Нәкъ үзем инде менә. Их, атасы да югары очта гармун уйнап, җыр сузып җибәрсә, түбән очтагылар ишетеп җыела торган иде бит. Лачын шул ул минем улым! Менә, гармунын да күз карасы кебек сакладым. *(Бик кадерләп төреп, шкаф өстенә куя.)*

ЗАРИФ. Бабай, беләсеңме, күрше Рәшит шундый мактанчык, ачуны китерә кайчакта.

ФӘЙЗУЛЛА. Нәрсә ди соң ул, улым?

ЗАРИФ. Минем әти капитан.

УТНЫ-СУНЫ КҮП КИЧКӘН.

Нимесләрне куа-куа

Берлинга барып җиткән, дип җырлап йөри. Нинди капитан булсын ди ул! Сержант кына бит аның әтисе. Менә минем әти командир! Мин бит мактанмыйм. *(Пауза.)* Бабай, әйдә, яшелчә бакчасына чыгып, әкрен генә чүп утап керик.

ФӘЙЗУЛЛА. Әйдә, әйдә, улым. *(БАБАЙ белән ЗАРИФ чыкканда, МӘРЬЯМ. урамнан керә.)*

МӘРЬЯМ. Кая киттегез?

ЗАРИФ. Әбием без бабай белән яшелчә бакчасына чыгып чүп утап алабыз.

МӘРЬЯМ. Ярар. Фәйзулла, син үзеңне начар хис итсәң өйгә кер яме.

ФӘЙЗУЛЛА. Ярар, хатын.

МӘРЬЯМ *(Арыган, сусаган самовардан су эчә)*. Бабай быел биреште, картайды. Алдагы елларда әле колхоз эшеннән кайтып керми иде. Быел хәле юк, озак йөри алмый. Каты чирләп, урын өстенә генә аумасын иде инде. Килен дә өйгә кайтып керә алмый. Бик арый. Аңа бераз булышыйм дип барган идем инде болынга. Кая, көндезге ашка ни дә булса хәстәрләргә кирәк. Килен, кайтып, хәлегезне белеп китәм дигән иде. Тарткан борчак оны бар иде бераз, умач уаргамы соң инде?

*ӘСМАБИКӘ керә. Төенчек тоткан. Бөтен өй эчен, нәрсәдер эзләгәндәй, күзе белән айкый.*

ӘСМАБИКӘ. Исәнме, туганкаем! *(Ясалма кайгыртучанлык күрсәтеп.)* Менә, хәлегезне белергә кердем. Ничекләр итеп, көн күреп ятасыз икән, дип борчылам. Карале, туганым, менә сезгә аз гына бәрәңге алып килдем. Бер утырып ашарга булса да ярар. Янә дә килеп, ярты пот арыш оным бар. Шуны сиңа сатыйм дигән идем. Чит кешегә *(як-ягына каранып)* җибәргәнче, үземнең туганыма булсын, диюем.

МӘРЬЯМ. Ай, Аллам! Рәхмәт инде килен, бәрәңгең өчен. Онынны да алыр идем, акчам юк бит, бер тиен дә. Нәрсә белән түлим соң инде?!

ӘСМАБИКӘ. Әнә бит, колагыңда алтын алкалар. Туганымнан кыйммәт сорамам. Шул да җитә. *(Шкаф өстендә торган гармунга күрсәтә.)* Менә, бу гармунны алыр идем, сатмыйсыз инде сез аны. Минем дә уйнаучым юк. Рәхимҗан көне-төне колхоз складында. Үзе кладовик, үзе каравылчы. Ярый, китим, туганым. Атабызга көндезге ашны илтим.

МӘРЬЯМ. Карале, Әсмәбикә килен, ник син печәндә түгел?

ӘСМАБИКӘ. Ә-ә! *(Кеткелдәп.)* Чакырып та карадылар, ачуланып та карадылар, бармадым. Инде туйдылар ахрысы. Хәзер ни килгән, ни дәшкән кеше юк. Ярар инде *(үпкәләгән сыман)* мин бит әллә кем түгел, үпкәләмимим, килмәсәләр. Һа-һа-һа. Я, Мәрьям апа, ризамы, килештекме?

МӘРЬЯМ. Нишлим соң инде! Әле бит киленем, оныгым бар! Без кайгыртмасак, кем кайгыртыр инде аларны!

ӘСМАБИКӘ. Дөрес, туганым. Балалар берәр кич кенә булса да тамаклары туеп йокларга ятарлар иде. Ярый, сау бул, тиздән әйләнермен.

*ӘСМАБИКӘ китә.*

МӘРЬЯМ *(алкаларын барлап)*. Әнкәемнең бертуган апасы, бердәнбер кыз туганым дип, истәлеккә биргән иде бу алкаларны әнкәйгә. Иң газиз кешеләремнең төсе итеп сакладым аларны. *(Күз яшен сөртеп ала.)* Авыр булса да, салып бирергә туры килә инде. Балаларны ач тотып булмый бит!

*Күрше хатыны МАРИЯ керә.*

МАРИЯ: Здравствуй, Марьямушка! Тёзка моя! Как живёшь, чем занята?

МӘРЬЯМ. Ә-ә-ә! Әйдә, әйдә заходи, ты свуй чаловек, родной!

МАРИЯ: Ты что, плакала? Что случилось? Может новость какая плохая?

МӘРЬЯМ. Юк-юк, Аллага шөкер. Ни хороший, ни плохой новость юк. Менә Әсмабикә пришла. Муку нимнужко даст, менә бу серёжканы отдаю. Бик жалко инде, память мамина. Вот и плакала.

МАРИЯ: Ах, кулацкое отродье! Вот родня! На чужих слезах разбогатеть хочет! Даром ей это не пройдёт! Ай, да ладно, ну её, ко всем чертям. Марьямушка,

вот тебе молоко, катык принесла. Пол хлеба горячего ржаного бабаю. Он ведь любит мою выпечку. Вечерком, муку немножко принесу. С голоду не умрём. Не отдавай серёжки. Как нибудь переживём.

МӘРЬЯМ. Әй, Марьюшка, родная. Син бит роднее, чем Әсмабикә. Твой Степан ушёл на войну и мой Хафиз ушёл. Алар там вместе ружьё держат, а мы тут дружно живём, Аллага шөкер! У меня нет у тебя есть, у тебя нет — у меня есть. Спасибо инде большой вам.

МАРИЯ *(Тәрәзәдән МИҢЗИФАНЫҢ йөгергәнен күрә).* Вот там сноха ваша бежит домой, хворост тащит.

МӘРЬЯМ. Әй, мескенкәем, тилмерә инде, устаёт. Как мужик косит сено, да ещё домой то дрова принесёт, то крапиву, то дикий лук-юка соберёт, пустыми руками не приходит. Әле сама ходила на сенокос, помогать ей. Бабай не может, болеет.

*МИҢЗИФА ашыгып килеп керә.*

МИҢЗИФА. Әнкәй, хәлең ничек? Исәнме, Маша түти! Как здоровье?

МАРИЯ. Терпимо, дочка, спасибо! С вами вместе как ни будь переживём, победим горюшко. Лишь бы здоровье было.

МИҢЗИФА. Да, әйе, Маша түти, война кончилась, мужья, сыновья приедут, Алла боерса.

МАРИЯ. Обязательно вернутся, ждём их возвращения.

*МӘРЬЯМ табын әзерли, килене булыша.*

МӘРЬЯМ. Әйдәгез, табынга якынрак утырыгыз. Ашым әзер. Хәзер бабайны да, улымны да дәшәм. *(Чыгып, кире керәләр. Өстәл янына утыралар, сөйләшеп аш ашыйлар.)*

ЗАРИФ. Әбекәй, без бабай белән сөйләшә-сөйләшә, ярты яшелчә бакчасының чүбен утап бетердек. Калганын иртәгә, бетерербез инде.

МӘРЬЯМ. Менә нинди дәү үсте безнең улыбыз. *(ЗАРИФНЫ яратып ала.)*

МИҢЗИФА. Рәхмәт балам! Хезмәт сөеп үс!

МАРИЯ. Отец приедет, не узнает сына. Каким молодцом растёт. Не сглазить бы.

МИҢЗИФА. Әнкәй, борчак кузагы тула башлаган. Җае килсә, бераз гына алып кайтырмын дип торам.

МӘРЬЯМ. Һай, балакаем, берүк сак була күр. Күрсәләр, ирең кайтыр, үзеңне алып китәрләр, харап булырсың.

МИҢЗИФА. Әй, әнкәй, җаным, шушы балага бераз сый булсын диюем инде. Ашау бигрәк такыр бит.

МАРИЯ. Зифа, дочка, ты слышала, нет? В соседнем колхозе охранник поля застрелил женщину прошлой ночью. Она тоже пошла за горохом, детей хотела накормить зеленым горохом, погибла. Четверо детей остались сиротами. Военное время, законы суровые. Будь осторожна!

МИҢЗИФА. Ярый, әткәй, әнкәй, китим. Рәхмәт сезгә. Исән-имин булыгыз! Спасибо, Маша түти. Аллага тапшырдым. Сау булыгыз!

*МИҢЗИФА чыгып китә.*

ФӘЙЗУЛЛА. Армый эшлә, кызым! Ходай түземлек бирсен үзенә. Бүген иртәдән бирле күңелем каядыр ашкына. Әллә төпчегебездән берәр хәбәр килә микән? Әллә үзе үк кайтып киләме? Әнә, бит, югары оч Кәримулла шыпырт кына кайтып утырды. Белмәссең, дөнья бу!

МАРИЯ. Я тоже пойду. Муж, наверное, потерял меня. Спасибо за обед. У моей тёзки всегда всё вкусно. Рахмет. Сами к нам заходите!

*МАРИЯ чыгып китә.*

ЗАРИФ. Әбием, рәхмәт! Ашың бигрәк тәмле иде. Әбекәй, бабай мин малайлар белән су коеныргa төшим әле.

МӘРЬЯМ. Улым, сак бул! Суга кинәт кенә кермә. Озак булма.

ЗАРИФ. Рәхмәт, әбекәй! Рәхмәт бабакай!

*ФӘЙЗУЛЛА белән МӘРЬЯМ, ЗАРИФ дога кылалар.*
*ЗАРИФ чыгып китә. МӘРЬЯМ табын җыя.*

ФӘЙЗУЛЛА. Йөрәк чыгымлап тора. Бераз ятып алам әле. Салкын чоланда хәл алыйм әле.

МӘРЬЯМ. Бар, бар. Рәхәтләнеп ял ит.

*Кашыяклар җыеп юарга китә. Йортта тып-тын.*

## Икенче күренеш

*Басу. Кипкән печәнне чүмәләләргә салганнар. Басу кырыннан елга сузылып китә. Кемдер киемнәрен кага, кемдер бит-кулын юа, яшь-үсмерләр елгага су коеныргa җыеналар. Егет-кызлар бер-берсенә су сибешеп, шаярышалар, көлешәләр.*

ВӘЛИ *(усал)*. Люба, Люба дим!

ЛЮБА. Нарся киряк?

ВӘЛИ. Мукрый стал, как курица. Давай суши мне рубашку.

ЛЮБА. Хазер, побежала.

ВӘЛИ. Ярар, ярар, я пошутил. Киттек су купаться.

ЛЮБА. Что? Что?

ВӘЛИ *(ЛЮБА янына килеп хәрәкәт белән күрсәтә)*. Су коенырга, купаться инде. Вут так.

ЛЮБА. Я тебе покажу, как надомной издеватся! *(Шаяртып сугып ала.)*

ВӘЛИ. Нәрсә өчен?

ЛЮБА. Плохой ты, с пути сошёл.

ВӘЛИ. Как сошёл? Менә бит, рядом стоим, вместе.

*ВӘЛИ кызны кочмакчы була, кыз читкә тайпылып китә. ВӘЛИ егыла. Яшьләр көлешәләр. Шул чак ЗАРИФ йөгереп керә.*

ЗАРИФ. Авылга солдат кайткан, монда килә!

ЛЮБА. Кем булыр бу? Таягы да бар.

ВӘЛИ. Аягы имгәнгән ахрысы.

КАДЫЙР БАБАЙ. Имгәнсә төзәлер. Бөтенләй кисеп ташламасыннар гына. Ходай сакласын.

*Халык шаулап ала.*

ЗАРИФ. Әнкәй, безнең әти таякка таянырлык карт түгел бит әле ул, әйеме?

МИҢЗИФА. Балакаем, сугыш һәркемне тигезли ул. Яшьне картайта, картны яшәрергә мәҗбүр итә. *(Солдат килгән якка карый, Хафиз түгелме дип карый.)*

МИҢЗИФА. Хафиз бит бу! Хафиз! Исән! Ходаем!

*ЗАРИФ белән шул якка йөгереп китәләр. Кире керәләр.*

ХАФИЗ. Алтыннарым, сезне күрер көнем дә бар икән. Улым, газизем, нинди егет булып җиткәнсең бит! *(Аларны икесен кочаклый.)*

*Халык үз эшләрен ташлап аларны чорнап ала. Берсен-берсе уздырып сораулар яудыралар.*

ХАЛЫК. Саматымны күрмәдеңме? Нәҗибемне очратмадыңмы? Үзең генә кайттыңмы?

ХАФИЗ. Исән-саулармы, авылдашлар? Туганнар, мин үзем генә кайттым. Кызганыч, авылдашларны очратмадым.

КАДЫЙР БАБАЙ. Туктагыз әле, туганнар! Сорауларыгызны соңарак бирерсез. Солдатны да ялыктырмыйк, ял итсен. Әтисе-әнисе белән күрешсен.

ХАФИЗ. Рәхмәт, Кадыйр бабай! Мин госпитальдә җитәрлек ял иттем. Әһ, рәхәтләнеп, бер селтәнеп печән чабар идем дә... Ичмасам, туйганчы яңа чапкан

печән исен исним, туган җиремнең һавасын сулыйм әле. Бик сагындым мин сезне, авылдашларым!

## Өченче күренеш

*ФӘЙЗУЛЛА өйе. МӘРЬЯМ өстәл янында утырып уйга чумган. Шул чак әкрен генә ишек ачыла. Бусагада солдат пәйдә була. Әкрен генә, бик тә назлы итеп, «Әнкәй!» — дип дәшкән тавышка МӘРЬЯМ борылып, бик гаҗәпләнеп карап тора. Ул тормакчы була, ләкин кире утыра, хәле киткән кебек була. Әкрен генә, «Улым!» — дип кенә дәшә ала. Солдат таягына таянып, аксаклап үзе эчкә үтә, әнисен кочып ала. ХАФИЗ артыннан МИҢЗИФА, ЗАРИФ та керәләр.*

МӘРЬЯМ. Аллага шөкер, исәнлектә күрешергә насыйп булган. Ничек кайтып җиттең, улым? *(Хафиз әнисен кочаклый.)*

*Тавыш ишетеп, ФӘЙЗУЛЛА кереп аларга кушыла.*

ФӘЙЗУЛЛА. Ай, Аллам! Менә бит, юкка гына күңелем җилкенмәгән икән. Лачыным белән күрешергә булган бит! *(Кочакланышалар.)* Улым, ник хәбәр итмәдең? Станциягә ат җибәрер идек. Әйдә, утыр улым.

*Аягына ишарә ясый. ЗАРИФ, МИҢЗИФА да өстәл янына утыралар.*

ХАФИЗ. Әнкәй, әткәй, мин Берлинда госпитальдә яттым. Шәһәргә керүгә, минага эләктек. Иптәшләрем һәлак булдылар. Чуаш егете Егор белән икәү генә исән калдык. Безне табып алып госпитальгә илткәннәр. Үзегез ничек яшисез? Сәламәтлекләрегез ничек?

МӘРЬЯМ. Безнең хәлләр түзәрлек әле, улым. Аягың бөтенме соң, улым? Иелеп аягың капшап ала.

ХАФИЗ. Аягым бөтен анысы. Өч тапкыр операция ясадылар. Докторлар тырыштылар, аягымны кисмәделәр, ходайга шөкер, җансыз булса да, үземнеке.

ФӘЙЗУЛЛА. Әйдә, улым, бит-кулыңны юып ал да, ашап-эчеп алгач, ял итәрсең.

ХАФИЗ. Әткәй, госпитальдә ятканда печән өсте төшемә кереп йөдәтте. Яңа чапкан печән исен туйганчы иснәр идем.

ФӘЙЗУЛЛА. Бик әйбәт булыр улым. Әнә Сәмигулла ат белән халыкка су ташый. Ашчыларга азык-төлек илтә. Аны каравыллап торырбыз. Барырсың син дә болынга. Әйдә, менә катык, сөттән авыз ит! Күрше Мария кертте. Үзебезнең сыерны бетерергә туры килде инде… Күршеләребез туганнан артык, ходайга шөкер, ташламыйлар. Төрле-төрле халык яшәсә дә, авылыбыз тату, бер гаилә булып яшибез.

ХАФИЗ. Әнкәй, минем гармун исәнме соң?

М Ә Р Ь Я М. Әйе, улым, бик кадерләп сакладык. *(Шкаф өстеннән алып бирә.)* Менә ул.

*Х А Ф И З кадерләп кенә гармунын кулына ала.*

Х А Ф И З. Минем гармуным. Ничекләр мин сине сагындым.

*Уйный башлый. Гармун тавышына авыл халкы Ф Ә Й З У Л Л А өенә җыела. Бер якта хатын-кызлар, өлкәннәр, икенче якта яшьләр утыра.*

З А Р И Ф. Әти, уйна әле безнең көйне, бер җыр җырлап күрсәтим әле.
Ленин бабай васыять әйткән:
«Укырга һәм укырга!»
Сталин әйткән: «Нимесләрне Җиңгәнче сугышырга!»
Х А Ф И З : Әй, улым, кайда өйрәндең бу җырны?

*Х А Ф И З гармун тотып уртага баса.*

Дөрес бу! Иптәш Сталин нәкъ шулай дигән иде бит. Их! Без күргәнне сезгә күрергә язмасын, балам! Ягез әле, авылдашлар, гел хәсрәтләнеп кенә тормыйк әле. Бирешмик әле авырлыкларга, кайгыларга. Җырлап, биеп, күңелләрне күтәрик әле бергәләп. Киләчәк безнең кулда, яшик әле, көрәшик, исәннәр өчен тормыш дәвам итә!

*Күмәк бию көен уйный. Кайберәүләр авылдашлар гармун көенә кушылып биилләр. Алар биегәндә сәхнә пәрдәсе ябыла.*

*Хәбибуллина Илвина Илнур кызы*

# АВЫЛЫМДА КАЗ ӨМӘСЕ

*Катнашалар:*

ГӨЛНИСА АПА, йортның хуҗасы.
НАЗЛЫГӨЛ, кече кызы.
АЙЗИРӘК, олы кызы.
ЛИЛИЯ, ГӨЛНАЗ, тагын берничә кыз, авыл кызлары.
ИЛДАР, РАМИЛ, АЙДАР, тагын берничә егет, авыл егетләре.

*Вакыйга авыл йортында бара.*

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Авыл йортының эче. Түрдә чигелгән тышлыклар кигертелгән мендәрләр, көзгегә чигелгән сөлгеләр эленгән. Ярымтүгәрәкләп урындыклар тезелгән.*

ГӨЛНИСА АПА. Хәзер кызлар килеп җитәр. Син, Назлыгөл кызым, мин әйткән барлык кызларга да эндәшкән идеңме кичә?

НАЗЛЫГӨЛ. Әйе, әни. Барысы да киләбез дип калдылар.

*Ишек шакыйлар, кызлар тавышлары ишетелә.*

КЫЗЛАР. Керергә ярыймы? Без килеп җиттек.

ЛИЛИЯ. Йортыгызга бәрәкәт иңсен, өстәлләрегез мул булсын.

ГӨЛНИСА АПА. Рәхмәт, рәхмәт. Керегез әйдә. Түрдән узыгыз.

*ГӨЛНИСА АПА, НАЗЛЫГӨЛ, АЙЗИРӘК кунакларны каршы алалар.*

*Кызлар әкрен генә урындыкларга тезелешеп утыралар. Аларга йолкырга казлар кертеп бирәләр. Кызлар «Каз канаты» җырын җырлап каз йолкыйлар.*

ГӨЛНИСА АПА. Карап торам да, бигрәк җитез эшлисез, инде эшегез дә бетеп килә түгелме соң?

*Шулвакыт ишек шакыйлар. Кыз киемнәре киенеп ике егет килеп керә.*

ЕГЕТЛӘР. Исәнмесез, без кунак кызларына ярдәмгә килдек, ярдәм кирәкме?

А Й З И Р Ә К. Сез кемнәргә килдегез соң?

*Егетләр ни дип җавап бирергә белмиләр. Кызлар сизеп алалар. Үзара тиз генә җыелып сөйләшәләр.*

Бу кунак егетләрен йонга батырыйк, гореф-гадәтләр буенча барыбызга бәхет китерсен.

*Егетләрне йонга батыра башлыйлар, егетләр чыгып качалар.*

ГӨЛНАЗ: Хәзер, кызлар, җыештырыйк та, казларны су буена алып төшеп юыйк.

А Й З И Р Ә К. Ә син, Назлыгөл, каурыйларны ал. Су юлына сибәрсең, изге теләкләр теләрсең.

*Җыештырып, казларны көянтәгә асып, «Каз канаты» җыры барганда алып чыгып китәләр. Тышкы якта кызларның сөйләшкәне, көлешкәннәре ишетелә.*

Н А З Л Ы Г Ө Л. Каурый сибәм су юлына. Ишле булсын казыбыз.

## Икенче күренеш

*Шул ук авыл йортының эче. Түрдә чигелгән тышлыклар кигертелгән мендәрләр, көзгегә чигелгән сөлгеләр эленгән. Бер почмакта сандык. Көлешеп — шаярышып кызлар килеп керәләр.*

А Й З И Р Ә К. Менә, кызлар, эш тә бетте. Киенhr-ясаныйк, егетләр килер.

Г Ө Л Н А З. Кайсы күлмәгеңне киясең син, Айзирәк?

А Й З И Р Ә К. Менә боларны киярргә дип әзерләдем.

*(Көзге янында бизәнгән кызларның барысы да «бигрәк матур», «Ай-яй», дип Айзирәкне әйләндереп алалар. Шулвакыт ерактан «Эх сез матур кызлар» җыры ишетелә.)*

А Й Г Ө Л. Кызлар, егетләр килә. Тизрәк әзерләник.

Л И Л И Я. Ә без егетләргә каз канаты сатабызмы соң?

Б Е Р Г Ә. Әйе, әйе, алай булмаса күңелсез булыр.

А Й З И Р Ә К. Һәркайсыгыз канат алыгыз, канат сатканда җебеп тормыйк. Һөнәрен күрсәтмичә, өйгә кертмик. Шулай булса, күңеллерәк булыр. *(Кызлар ашыга-ашыга канатларны алалар.)*

*Ишек шакыйлар.*

Е Г Е Т Л Ә Р. Кунаклар килде, хуҗалар кайда микән?

Л И Л И Я.
Канат сатабыз, канат!
Яхшысын сайлап, карап.
Әйдә, егет, канат ал,
Бер алтының чыгарып сал.

И Л Д А Р. Кыйммәт икән бер алтын
Канат үзегездә калсын.

*Кызлар тиз генә җыелышып, нидер сөйләшәләр.*

Г Ө Л Г Е Н Ә. Алтыннарыгыз булмаса, һөнәрләрегез бардыр. Безгә бик тә ошаса, кертәбез сезне бәйрәмгә.

*Егетләр үзара сөйләшеп алалар.*
*Бертавыштан «без риза» дип җавап бирәләр. Такмаклар башлана.*

Р А М И Л. Их тамаша, тамаша,
Матур кызларны күреп безнең күзләр камаша.

*Кызлар битләрен яулык белән каплыйлар.*

И Л Д А Р. Барысы да шундый уңган,
Барысы да шундый булган.
Йөзләре кояш кебек,
Торалар нурлар сибеп.

А Й Д А Р. Бик моңсу миңа, нигә?
Уйларымда син генә...
Нишлим, сөймәсәң, сөймә,
Мин бик сөям сине генә.

И Л Д А Р. Ничек, ошадымы безнең такмаклар, кызлар.
А Й З И Р Ә К. Ярый инде бу юлга кертеп торыйк, әйеме, кызлар.
*(Кызлар «Әйдәгез. Әйдә» диешәләр. Егетләр түргә керәләр)*
А Й Д А Р. Бүген зур өмә ясагансыз, кызлар. Казларыгыз әйбәт булдымы соң?
Г Ө Л Г Е Н Ә. Быел казлар бик уңган, бик симез.
Р А М И Л. Бәхетегез дә булсын тигез.

*«Каз канаты» җыры башкарыла. Кызлар каз канатлары белән бииләр.*

Л И Л И Я. Әхәзер әйдәгез «Йөзек салышлы» уйныйбыз. Барыгыз да беләсезме тәртибен?
Б Е Р Г Ә. Беләбез, беләбез.
Л И Л И Я. Йөзекне үзем салам.
Зәй, Зәй, Зәйнәбем,

Атны кайда бәйләдең?
Алмагачка бәйләдем.
Алма төште шап итеп
Зәйнәп чыкты ялт итеп.

*Кемдә йөзек шул сикереп чыга. Чыга алмаса, җәза бирелә.*

Л И Л И Я. Илдар чыга алмады, нинди җәза бирәбез?

*«Әтәч булып кычкырсын» дигән тавышлар ишетелә. И Л Д А Р әтәч булып кычкыра. Уен шулай дәвам итә.*

Г Ө Л Н А З. Ә хәзер тапкырлыкны белер өчен «Табышмак» уены уйнап алыйк.
Б Е Р Г Ә. Әйдәгез, әйдә.
Р А М И Л. Әйдәгез бу юлы мин башлыйм.
Авызы ачык, төбе тишек,
Эче тулы халык. Нәрсә ул?

*Төрле җаваплар яңгырый.*

Җавапларыгыз дөрес түгел, биреләсезме?

Б Е Р Г Ә. Әйе, авыр бу. Бирелəбез
Р А М И Л. Бу — авыз һәм тешләр була.
А Й З И Р Ә К. Ә хәзер әйдәгез мин әйтеп карыйм.
Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый.
Кемдер «Карлыгач» дип кычкыра.
Әйе, дөрес, карлыгач.

А Й Д А Р. Кызлар, кичләр бик күңелле үтте. Без дә кайтып китәрбез инде.
Алай итәргә кирәк,
Болай итәргә кирәк.
Хуҗаларга рәхмәт әйтеп?
Кайтып китәргә кирәк.

*Егетләр җырлый-җырлый чыгып китәләр.*

А Й З И Р Ә К. Егетләрсез күңелсез булса да, моңсуланып утырмыйк. Бәлеш ашыйк, чәй эчик.

*Җырлый-җырлый кереп китәләр.*

